**БУ САНДА**

## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Ф.К. Сәгъдиева, Р.Т. Сәфәров.* Поэтик текстта сугыш концептының ассоциатив-мәгънәви чагылышы (Ф. Кәрим лирикасы мисалында) . . . . . . . . . . . . . . . . 5

*Д.Б. Рамазанова.* Телебездә шумер теле белән уртак сүзләр . . . . 9

*М.З. Зәкиев.* Татар терминнары ясалу һәм аларны төркемләү . . . . 20

*Ш.Н. Асылгәрәев.* Татар теленең алфавиты һәм орфографиясе турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32


## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Д.Ф. Заһидуллина.* Г. Әпсәләмов прозасы: көчле кеше фәлсәфәсе аша романтизмга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42

*Ф.Ф. Хәсәнова.* Ренат Харис иҗатында Муса Җәлил образы . . . . 51

*Р.Ф. Харрасова.* Әдәбият тарихының академик басмасына куелган таләпләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55

*Ә.М. Шәрипов.* Мәңгелеккә таулар белән каламын... (Әдхәт Синугылның тууына 80 ел) . . . . . . . . . . . . . . 60

*Л.Ш. Гарипова.* Язучы Мөхәммәтгариф Бурнашев: тормыш юлы һәм иҗаты турында . . . . . . . . . . . . . . . . 65


## КОНКУРСКА

*Г.И. Каюмова.* Ризван Хәмид драмаларында конфликт һәм характерлар гәүдәләнеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70


## ХАЛЫК ИҖАТЫ

*И.Г. Закирова.* Татар халык дастаннары . . . . . . . . . . . . 85


## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*З.Г. Гарипова.* Мөһаҗирлектәге татарларның милли-мәдәни тормышы (1905–1907 еллар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106


## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*И.К. Заһидуллин.* Хәсәнгата Габәши хатирәсе . . . . . . . . . . 122


## МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Ф.Ә. Ганиев.* Татарның үз дәүләте каршында ни гаебе бар? . . . 146

## ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН

*Л.М. Шкляева.* XX–XXI гасырларда Урта Идел буе авылларында яшәүче татарлар йортының тышкы бизәлешендә кошлар образы (2013 елгы экспедиция нәтиҗәләре буенча) . . . . . . . . . . . . . . . 150

## СӘНГАТЬ

*С.Н. Новикова.* Харис Якуповның фронт графикасы . . . . . . . 156

*З.Н. Сәйдәшева.* Фәрит Яруллин – композитор һәм сугышчы . . . 160

## ЯҢА КИТАПЛАР

Сальникова А.А., Галиуллина Д.М. Татарская «Алифба»: национальный букварь в мультикультурном пространстве (конец XIX – начало XX вв.) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

Арсланов М.Г. Татар театры. Энциклопедик сүзлек-белешмә 172

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

УДК 811.512.145'373

***Ф.К. Сәгъдиева, Р.Т. Сәфәров***

# ПОЭТИК ТЕКСТТА *СУГЫШ* КОНЦЕПТЫНЫҢ АССОЦИАТИВ-МӘГЪНӘВИ ЧАГЫЛЫШЫ (Ф. Кәрим лирикасы мисалында)

Предметом рассмотрения в данной статье является смысловое содержание концепта «сугыш» (война), воссоздаваемое на основе лексической экспликации в лирике Ф. Карима. В качестве объекта исследования послужили поэтические произведения автора. Главным фактором, повлиявшим на объект исследования, является то, что в поэтических текстах наиболее широко представлен материал для выявления указанного концепта как фрагмента авторской картины мира. В художественных текстах его содержание обогащается определенными концептуальными смыслами.

**Ключевые слова:** поэтическая речь, концепт, понятие, лексема, татарский язык.

Кешенең танып белү тәҗрибәсен чагылдыра торган төшенчә буларак, концепт телнең катлаулы һәм киң тармаклы бер категориясен тәшкил итә.

Матур әдәбиятта концепт, телнең лексик-семантик системасындагы парадигматик, синтагматик һәм деривацион бәйләнешләр кебек, номинатив берәмлекләрнең тексттагы парадигматик һәм синтагматик бәйләнешләре ярдәмендә вербальләшә. Ассоциатив компонентларның семантик яктан мотивлашуын ачыклау өчен, концептның төп-үзәк структурасына мөрәҗәгать итү сорала.

Концепт мәгънәсенең нигез структурасын ачыклар өчен татар теленең сүзлекләренә мөрәҗәгать итик. Биредә тикшерелә торган концептның төп лексемасы – *сугыш*. Лексикографик чыганакларда *сугыш* сүзенә шактый киң синонимик рәт тәкъдим ителгән: *орыш – яу – җәң – мөхарәбә – мөкатәлә – кыргын – тукыш* һ.б. Бу берәмлекләрнең күпчелеге, хәзерге татар теле күзлегеннән караганда, искергән дип санала.

*Сугыш* сүзенең борынгы төрки чыганакларда теркәлмәве игътибарга лаек. Бу аның шактый соң барлыкка килүе белән бәйле. Төрки телләр арасында нәкъ шул мәгънәдә әлеге лексема, кагыйдә буларак, кыпчык төркемендә очрый. Чагыш.: татар. *сугыш [суғыш]*, башк. *һуғыш*, нуг., каз., к.-калп. *соғыс,* алт. диал. (ойрот.) *соғуш,* уйг. диал. *соқуш*.

Бу лексема *согыш* формасында татар теленнән күрше мари һәм удмурт телләренә алынган.

Сүзнең чыгышы тикшеренүчеләрдә бәхәс уятмый: *сугыш* исем фигыле *соқ-* «сугу, бәрү, тукмау» гомумтөрки тамырына кайтып кала торган *сугыш-//согыш-* фигыленең уртаклык юнәлешеннән ясалган.

Татар телендә *сугыш* сүзенең киң деривациясе *(сугышу, сугышчы, сугышчан, сугышчанлык)*

әлеге концептның татар тел дөнья картинасы өчен шактый әһәмиятле икәнлеген исбатлый. *Сугыш* лексемасының аңлатмаларын анализлау аның семантикасының нигезен ачыкларга мөмкинлек бирә. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *сугыш* берәмлеге түбәндәгечә аңлатылган: 1) кыйнаш; 2) дәүләтләр һәм иҗтимагый сыйныфлар арасында оештырылган кораллы кыйнаш, көрәш, шул көрәшнең бер бәрелеше.

Материалыбыз күрсәткәнчә, Ф. Кәрим иҗатында *сугыш* төшенчәсе *Ватан сугышы, туган ил өчен сугыш* сүтезмәләре дәрәҗәсендә конкретлаштырыла. Бу планда шагыйрь, телне уникаль сиземләве сәбәпле, уй-фикерләрен реализацияләү өчен, актив рәвештә сүзләрнең ассоциативсемантик потенциалыннан файдалана. Мәсәлән, ватанны яклау кирәклеген күзаллау *ана, бала, нәсел, туган ил* кебек төшенчәләрдә чагылыш таба:

Синең өчен, шушы балам өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм.
[Кәрим, б. 644]

Текстның мәгънә парадигмасы актуальләштерелгән мәгънәләрдән оешкан лексик берәмлекләрнең берләшүеннән гыйбарәт.

Ф. Кәримнең шигырьләрендә сугыш төрле аспектларда күрсәтелгән. Нәкъ менә шулар аша автор дөнья картинасының фрагментларын сурәтләүгә ирешә алган. Бу сурәтләү текстларның мәгънәви семантик структурасының мөһим компонентларыннан берсе булган *сугыш* концептының эчтәлегендә дә чагылыш тапкан.

Ф. Кәримдә *сугыш* ут һәм ялкын белән ассоцияциялә һәм *сугыш уты, сугыш ялкыны, утка керү, үлем уты* кебек фразеологик берәмлекләр белән бирелә.

*Сугыш* концепты фрагментының мәгънәви структурасында парадигматик актуализациянең түбәндәге семантик аспектлары аеруча ачык күрсәтелгән:

I. *Үзебезнеке – чит* бинар оппозициясендәге сугышта катнашучы зат. *Үзебезнеке – чит* оппозициясенең парадигматик реализациясе төрле денотатив эчтәлекле лексемалар һәм фразеологизмнар ярдәмендә тормышка ашырыла. *Үзебезнеке* семасы *сугышчы, солдат, рядовой, партизан егет, иптәш, батыр, без, үч алучы, күз алмам, газиз аналар* һ.б.ш. сүз берәмлекләрендә чагыла. *Чит* семасы *фриц, фашист, мәлгунь, дошман, вандаллар* сүзләрендә, *кеше үтерүче, утка салучы* һ.б.ш. сүтезмәләрдә актуальләштерелә.

Мисаллардан күренгәнчә, поэтик тел текстында концептның парадигматик актуализацияләре милләткә бәйле булуны да билдерә ала. Әйтик, немец – *дошман*, ягъни *чит* мәгънәсендә. Мәсәлән: *немецтан үч алмый кайтмас өчен* ... [Кәрим, б. 50].

II. Вакыйга урыны. Вакыйга урыны түбәндәге лексик-фразеологик берәмлекләрдә чагыла: *фронт, окоп, сугыш кыры, сугыш мәйданы* һ. б. ш. Мәсәлән:

Көзнең күк томанлы таңында
Мин фронтка килдем тагын да.
[Кәрим, б. 119]

Кайбер очракларда вакыйга урыны конкрет географик урыннар белән билгеләнә: *Белоруссия,*

*Пруссия, Балтыйк диңгезе, Припять ярларында* һ.б.ш.

III. Сугыш коралы. Сугыш коралы *мылтык, кылыч, хәнҗәр, гранат, бомба, приклад, «Катюша»* һ.б. шуның кебек лексемалар белән бирелә. Мәсәлән: *Безнең «Катюша»ның утында «Юлбарыс»ы яна немецның...* [Кәрим, б. 53].

IV. Сугышчының киеме. Сугышчының киеме түбәндәге тел берәмлекләре белән белдерелә: *шинель, шинелемнең йомшак итәген, соры шинелем, шинельле кыз.*

Бер яктан, синтагматик контекст парадигматикада актуальләштерелгән мәгънәләрен кабатлый, икенче яктан, концептка авторның сугышчыны тасвирлаган сыйфатлар өстәлә. Бу планда шагыйрьнең, сыйфатлау лексикасын куллануы белән беррәттән (мәсәлән, *дәһшәтле сугыш, дәһшәтле кылыч*), сугышны күзалларга ярдәм итә торган чагыштыру, метафора, эпитет кебек элементлары булган тулы синтагмалар куллануы да зур әһәмияткә ия: *иң дәһшәтле утка керәм* [Кәрим, б. 76], *кырмыска кебек тынгысыз* [Кәрим, б. 174], *бәхет бакчаларын корытучы* [Кәрим, б. 98], *...совет солдатының йөрәгендә шаулап бара һөҗүм ташкыны* [Кәрим, б. 157], *котырган эт канлы фрицларны* [Кәрим, б. 156], *Совет җирендә һәрбер фашистның Чикләнер шулай кара язмышы* [Кәрим, б. 51].

Тикшерелә торган концептны төзүдә катнашкан лексемаларны анализлау *сугыш, яшәү* һәм *үлем* концептларының тыгыз элемтәдә булганлыкларын күрсәтә. Ф. Кәримдә *сугыш* концептының компонентлары булып яшәү һәм үлем турындагы тел берәмлекләре кулланыла. *Яшәү – үлем* бинар оппозициясендә авторның интерпретациясе *ватан, ил, гомер, үлем* һ.б.ш. кебек төшенчәләр белән бәйле. *Яшәү* төшенчәсе *гомер, хәят, тормыш, яшәү, юл* кебек лексемалар ярдәмендә бирелә. Яшәүне бер юл дип күзаллау *үткән юлымда* [Кәрим, б. 76] гыйбарәсендә чагылыш таба. Кыска гомер ялкын булып янарга тиеш: *кайгырам мин, гаять кыска гомер ялкынланып янсын иде дип* [Кәрим, б. 155].

*Үлем* төшенчәсе *үлем* (исем) һәм *үлсәм* (фигыль) лексемалары ярдәмендә бирелә. Ф. Кәримдә ватан өчен үлү җир йөзендә тормышның дәвам ителүе турында күзаллау белән бәйле. Үлемнән соң тормышның дәвамы исә – балалар:

Мин сугышка керсәм,
                    дошманымның
Йөрәгенә төзәп атамын;
Үзем үлсәм, балаларым кала
Минем гомерем булып, Ватаным.
[Кәрим, б. 76]

Шагыйрьнең үлемне күзаллавы шулай ук ватан турында уйлау һәм озын гомер белән ассоциацияләнә. Әгәр үлем турында уйламасаң, ватан турында уйласаң, гомерең дә озын була:

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла,
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.
[Кәрим, б. 107]

Югарыда әйтелгәннәрдән аңлашылганча, кеше аңында үлем мәңгелек булса да, ягъни адәм баласы үлеменнән соң кабат терелә

алмаса да, Ф. Кәримнең туган ил өчен үлем турындагы күзаллавы уңай компонентлардан тора.

Ватан өчен гадел сугыш, ахыр чиктә, дошманны җиңү белән тамамланырга тиеш. Дошманны җиңү турындагы күзаллау *җиңү, җиңеп кайтырбыз, җиңеп кайткач, җиңү шатлыгы, җиңү байрагы, җиңү җыры* һ.б. шуның кебек тел берәмлекләре белән билгеләнә.

Шулай итеп *сугыш* концепты Ф. Кәрим иҗатында шактый киң һәм күпкырлы күрсәтелгән. Концептның эчтәлеген билгеле концептуаль мәгънәләргә баету автор буларак шагыйрьнең дөнья картинасы фрагментын тәшкил итә. Тел анализы күрсәткәнчә, Фатих Кәрим иҗатында тикшерелә торган концепт төрле лексик чаралар ярдәмендә репрезентацияләнә.

**Әдәбият**

*Кәрим Ф.* Әсәрләр: 3 томда / Ф. Кәрим. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. Т. 1. Шигырьләр. 318 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

***Сәгъдиева Фәүзия Кәбир кызы,*** *филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре;*

***Сәфәров Ринат Таһир улы,*** *филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***Д.Б. Рамазанова***

# ТЕЛЕБЕЗДӘ ШУМЕР ТЕЛЕ БЕЛӘН УРТАК СҮЗЛӘР

Статья является продолжением серии публикаций об истории формирования татарского словарного фонда. В ней даются сведения об одной из тюркских групп (шумерах) прототюркского периода: об их истории существования (V–I тысячелетие до н.э.), антропологии и языке. Опираясь на труды этрускологов и шумерологов (О. Сулейменов, Ф.Р. Латыпов и т.д.), приводятся основные лексико-тематические группы лексем шумерского языка, параллели которых обнаруживаются и в современном татарском языке.

**Ключевые слова:** прототюркский период, шумерский язык, общая лексика для татарского и шумерского языков.

Шумерлар – хәзергә билгеле булган иң борынгы төркиләр, дип саналалар. Алар турында иң бай мәгълүмат академик М.З. Зәкиев хезмәтләрендә чагылган. Үзенең бер-бер артлы чыгып килә торган китапларында ул шумерлар турында, аларның тарихы, рухи һәм матди мәдәнияте, теле турында бай материал туплый һәм укучыларга җиткерә [Зәкиев, 2008, б. 128–132; 131; 153–156]. Бу мәкалә аның тикшеренүләренә таянып әзерләнде.

М.З. Зәкиев шумерларны, хаклы рәвештә, Алгы Азиядәге төрки ареал дип саный һәм аның карашлары Ф.Р. Латыйпов фикерләренә якын. Шумер, аккад, Ассирия һәм Урарту чыганаклары белән танышу Алгы Азиянең борынгы тарихын җентекләп өйрәнергә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, Азәрбайҗан галиме Фиридун Агасыоглу, әлеге чыганакларны өйрәнеп, безнең эрага кадәр IV–III меңьеллыкларда Тигр елгасының югары агымында төрки телле субарлар яшәгән, дип нәтиҗә ясый, көньякка таба команнар, дулу, турук, кашгай һәм башка кабиләләр яшәгәннәр, дип күрсәтә (Фиридун Агасыоглу, 2000, б. 41). Алгы Азиядә борынгы төрки ареаллар булуы андагы борынгы топонимнар белән дә дәлилләнә: Тавр, Кавказ атамалары – тау ирләре, Ак Кыя, Оксай – саф сулы дигән мәгънәләрне белдерә (Пьянков, 1997, б. 283–284).

Урта, Алгы Азиядә төркиләрнең безнең эрага кадәр күп мең еллар элек яшәвен Библиядә дә (Ветхий Завет, б.э.к. III–II гасыр), Коръәндә дә (б.э. VII гасыры) раслый торган мәгълүматлар бар. Аларда А. Македонскийның Кече, Алгы, Урта Азиядә төркиләр белән сугышуы турында мәгълүматлар теркәлеп калган [Ахунов, 2003, б. 11–16].

Аккад чыганаклары хәбәр итүенчә, Багдадтан көньякта кангарлар, ә төньяктарак субарлар яшәгән. Шумерлар үзләрен кангар (Геродотта: ангареон) дип йөрткәннәр, аларны аккадлар шумер дип атаган, субарлар белән шумерлар бер телдә сөйләшкәнгә

күрә, аккадлар әлеге ике төркемне дә шумерлар дип атаганнар. Шумерларны аккадлар ассимиляциялəгəннәр. М.З. Зәкиев, аларның бер өлеше Урта Азиягә, хорезмлылар арасына күчеп утырган булуы мөмкин, дип фараз итә.

Шумерлар, борынгы халык буларак, күп кенә регионнарга таралганнар һәм аларның этнонимнары төрле вариантларда (субар / суар / сувар / сумер / шумер / савир / самар / сибир) кулланылган. Бу вариантлылык төрки телләргә хас фонетик закончалыклар белән раслана [Зәкиев, 2008, б. 131–132].

Антропология фәне мәгълүматларына караганда, шумерлар европеид расаның Балкан-Кавказ җирле төркеменә керә [Большая..., с. 518].

Шумерлар б.э.к. IV–III меңьеллыкларда Тигр һәм Евфрат елгалары арасында беренче дәүләт төзегәннәр, чөй язуын уйлап чыгарганнар.

Борынгы халыкларны өйрәнгәндә тел материалларының, язма чыганакларның әһәмияте бик зур. Шумерларның чөй язулы күп санлы язма истәлекләре 15 мең балчык плитәләрдә сакланган, алар XIX гасырда Иранда Басра шәһәреннән ерак түгел генә табылалар [Большая..., с. 518].

Шумер теле б.э.к. II меңъеллыкта ассимиляцияләнеп беткән һәм семит телләренә нигез салган аккад теле өчен субстрат катлам булып калган, дип исәпләнелә. Әлеге язма чыганаклар авырлык белән генә укылсалар да, алар да шумерларның югары мәдәниятле, язма әдәбиятле, математика һ.б. фәннәрне белүләре, алга киткән халык икәнлеге турында бай мәгълүмат бар.

Башка халыклар арасында йотылсалар да, алар уйлап тапкан чөй язуын аккадлар, эламлылар, урартулар һ.б. кабул итәләр һәм камилләштерәләр. Аларның чөй язуы әкренләп укыла башлый, әлеге чыганакларда күп санлы төрки сүзләр булуы ачыклана: Ф. Хоммель шумер телендә 200 төрки сүз таба [Хоммель Ф., 1915], И.М. Дьяконов исә әлеге телдә һинд-европа телләре сүзләрен эзли һәм ниндидер «изолированный» тел дигән ялгыш нәтиҗәгә килә [Дьяконов, с. 107]. И.М. Дьяконов китабында О. Сулейменов 60 төрки сүз таба [Сулейменов, с. 230–242], төрек галиме Осман Нәдим Туна шумер-төрки охшашлыкларын өйрәнә, 168 уртак сүз күрсәтә, фонетик һәм грамматик охшашлыкларны ул, кардәшлек нәтиҗәсендә түгел, бәлки бик озак дәверләр тыгыз мөнәсәбәттә булудан, дип бәяли [Туна, 49; Зәкиев, б. 156].

О.Н. Тунаның эзләнү-тикшеренүләрендә телләрнең (бу очракта төрки телнең) яшәү гомере мәсьәләләре дә кузгатыла һәм галим аны, 11 мең ел була, дип билгели, ә аның язуда беркетелүен 8000–8500 ел элек башланган дигән нәтиҗә чыгара [шунда ук].

Билгеле булганча, телләрнең гомер озынлыгын өйрәнеп тикшерүче галимнәр әлеге санны 13–15 мең ел дип күрсәтәләр. Мондый тикшеренүләрнең методикасы хәзерге көндә шактый нык камилләшкән, ләкин агглютинатив (мәсәлән, төрки) телләрнең яшәү чоры күпкә артык булырга тиеш. Безнең эрага кадәр язылган

чыганаклардагы төрки сүзләрнең зур өлеше аңлаешлы булулары да шул турыда сөйли. Тикшеренүләрдән ачыкланганча, баба болгар чоры материалларында безгә аңлаешлы гадәти төрки тел чагылуы мәгълүм, бу – төрки телләрнең гомере аеруча озын булган, дип фаразларга мөмкинлек бирә. Татар-монгол янәшәлекләре монгол яуларыннан бик күпкә алда, татар-монгол телләре әле аерылмаган дәвергә үк тоташадыр, дигән фикер туа.

Шумерлар, чыннан да, төрки халыкларның этник тамырлары булырга мөмкин. Тик алар күрше халыклар (мәсәлән, аккадлар) белән үзара бәйләнештә яшәп, ниндидер, хәзергә билгесез сәбәпләр аркасында йотылганнар. Ф.Р. Латыйпов шумерларның кайбер кабиләләре көнбатышка таба хәрәкәт итеп, башка халыклар белән аралашып, йотылган булуларын да фараз итә. Аларның этрусклар белән бәйләнешләрен дә ачыклау мөһимлеген искәртә.

Лексик уртаклыкларга килгәндә, шумерлар белән уртак сүзләр төрле авторларда, төрле хезмәтләрдә табыла. Мәсәлән, Италиянең күренекле тел белгече Альфред Тромбетти 20 нче елларда чыккан хезмәтендә шумерча бәйләвеч сүзенең янәшәлекләрен баск, якут, ительмен, бареа һ.б. телләрдә дә бар, дип күрсәткән [Нафиков, б. 54]. Шумерча kingi(n) (укылышы – киңи) – тигезлек дигән сүз һәм Ш. Нафиков аны, башкорт телендәге киң сүзенә тамырдаш булуы мөмкин, дип күрсәтә; һикал (сарай) сүзен гарәп теленә, аннан һәйкәл формасында башкорт һәм шулай ук татар телләренә күчкән [Нафиков, б. 54], дип фараз итә, ballu – җир асты дөньясы демоны [Нафиков, б. 51].

Шумер чөй язулы истәлекләрдә dingir (тәңре) сүзе дә сакланып калган.

Ш. Нафиков ностратик сүзләрнең кайберләренә аерым туктала һәм әлеге сүзләрнең мәгънә функцияләре, таралыш ареаллары буенча яңа мәгълүматлар да өсти [Нафиков, б. 43–49, 56–57; 75, 84 һ.б.].

Р.Г. Әхмәтьянов түбәндәге сүзләрне шумер теленнән дип саный: *кеш, килү* (<ge-), *китән, колмак, сөмбел(ә), утын (ут), чебен, ышык* [Әхмәтьянов] һ.б.

Ф.Р. Латыйпов (борынгы язуларны уку белән шөгыльләнүче һәм этруск теле белгече) хәзерге *тәңре* сүзе шумерларда Tin-gir («Бог Тин» – тишина, гармония, умиротворенность) дип языла торган булган, дип күрсәтә [Латыпов, 2012, б. 188].

Төрле галимнәр тарафыннан шумерларныкы дип карала торган сүзләрнең кайберләренә тукталып үтү урынлы булыр.

Кешенең эшчәнлеге: *бәйләвеч, килү* (<ge), *китән, утын, ака* – игенчелек белән шөгыльләнүче [Әхмәтьянов, б. 208].

Табигать: *киңи* (тигезлек),

Йорт-җир: *һикал* (сарай), *ышык*.

Мәдәни: *dingir* (тәңре).

Хайваннар дөньясы: *кеш, чебен, gu, gud* – үгез [Трубачев, с. 8–9] > һинд-европа guou > славяннарда *говядо* һ.б. [Мусаев, с. 55].

Үсемлекләр: *колмак, сөмбел(ә).*

Ф.Р. Латыйпов этруск һәм шумер телләренең сүзлек составын, фонетик һәм морфологик уртаклыкларын өйрәнү барышында аларның төрки (шул исәптән Казан татарлары) телләр белән уртаклыгын күрсәтеп бара [Латыпов, 2009, с. 13–16]. Алар арасында түбәндәге сүзләр бар: *pin* (иске шумер) һәм *apin* (яңа шумер) – сабан; *en* – иң, аеруча, киң; *tab* > *dah* (берләштерү, кушу, өстәү – тат. *tagun* – тагын, өстәмә; *uru* – сөрү; *adub* – очу; *ruš* (ярсу) – төрк. *arus* – тат. арыслан; *šum* – шумер: ашыгыч – төрк. *ašy* – ашыгу; *ĭeš* – еш; -*še* – төрк. *yzba* – рус. изба, дом с крышей; *héllu* – шатлык, *kelü* – төрк. көлү; *šag* – урта, *üz* – төрк. үзәк; *ana-gim* – шумер, этруск. *nac* – рус. как, төрк. *näk* – ник, ничек (чагышт.: мишәр. нәк, тат. әд. ник), *urt* – рус. Бог поверхности земли – *jir* – җир; *igi* шумер – күзләр, *baqa* төрки, болг. күзләр; *ni* шумер – аны; *hu* – кош, *quš* – төрк. кош.; *du* шумер – аяк, төрк *adaq* – аяк, төрк *aĭaq* – аяк; шумер – *dug* – яхшы, төрк. *edugu* – яхшы, төрк. *izge* – яхшы, изге; *dumu-kis, ki-sikil* – бала, кыз бала, ярдәмгә мохтаҗ, төрк. *adas* – ярдәмче, дус; *kyz* – кыз; *dug* – әйтелгән, *ait* – төрк. әйтү; *sig* – сугу, төрк. *suk* сугу, *čukeč* – чүкеч; *tur* – алып килү, алып бару, *kitĕrü,* төрк. – китерү, алып килү; *e* – бу, шул, чув. *qu* – бу, икән, шулай итеп; *pada* – сайланма, сайлап алынган; каз., төрк. *aiber* – әйбер; *ara* – йөрү, төрк, *bar* – бар; *sar* – язу, төрк. *syr* – риска, syz – сызу, язу; *sör* – сөрү; *apsu* – югалу; төрк. *up* – югалу, *inzir* – бүлгән. төрк. *syndyr* – сындыру; *appa* – ипи, төрк. *äpi, ipi* – ипи; *ug* – үле, төрк. *ülük* – мәет; *aš* – бер; *kalag-a* – көчле; *alt* – югары; *lipiš* – йөрәк; *lu* – кеше; *hul* – усаллык, ачу; *šu* – кул. *tu* – туу, *si* – салу, тутыру (бөртеклеләр турында; (cun. – *Д.Р.*); *amma* – ана, *adda* – ата; *a-hi* – абый, *se* – кыз туган, *abba* – карт (чагышт.: тат. диал. *абушка* – карт); *silim* – исәнлек; *eša* – эсселек; *apsu* – упкын, *ud* – ут; *uš* – кырый, оч; *kur* – кыр; *kag* – якты, ачык; *ag-ag* – агач.

Тагын шунысы әһәмиятле, Ф.Р. Латыйпов шумер телендәге грамматик күрсәткечләрне дә тикшереп чыга һәм аларның бер өлешенең төрки телләр белән уртаклыгын күрсәтә [Латыпов, с. 20], алмашлыклар һәм бәйлекләр өлкәләрендәге уртак моментларны анализлый [Латыпов, с. 23]. Мәсәлән, шумер телендә *me* – мин, *ze* – син һ.б. алмашлыклар кулланылышта булган.

Саннар буенча да кызыклы мәгълүматлар китерелә: *eš* – өч, *y/un* – ун, *geš* – йөз һ.б.

Ф.Р. Латыйпов шумер телен борынгы төркиләрнең башка төркемнәренең теле белән чагыштырып өйрәнүне дәвам итә. Мәсәлән, 2013 елда чыккан хезмәтендә шумер-этруск-казан татарлары телләрен чагыштырып түбәндәге таблицаны тәкъдим итә [Латыпов, 2013, с. 52].

*Таблица 1*

Шумеро – этрусско – казанско-тюркские
лексические соответствия

| Шумер. | Этрусск. | Казан.-тюрк. |
|---|---|---|
| amma «мать» | anei | ännä (детское)<br>äneĭ (взрослое) |
| adda «отец» | atei | ättä (детское)<br>äteĭ (взрослое) |
| a-hi «старший брат» | axa | aγa |
| šeš «прирост в семье» | ziz «прирост объема» | šeš «опухоль, прирост» |
| appe «хлеб» | ipe | äpi, ipi |
| pin, apin «плуг» | sapin | saban |
| awîl «община» | awl | avyl |
| an «небо, верх» | an «верх»<br>ananc «взывание к небу» | önan- «молиться» |
| ut «свет, огонь» | uθ | ut |
| edeh «рвнина, степь» | eθen «ровный пол» | idän «пол» |
| sag «голова» | sax «размышлять» | sag- «мыслить», «вспоминать в мыслях» |
| hu | cus | qus |
| e | ei, eu | eĭ |
| eša | ese | esse |
| ten | tunt | tuŋ |
| hellu | celu «смех» | kelü «смех» |
| ma-al | pul- | bul- |
| tu | tu-, tuθ- | tu-, tud- |
| dah | θacen «дополнительно» | tagyn «еще» |
| tur | et(u)r- | kiter- |
| ara | var- | bar- |
| ana-gim | nac | näk’ |
| šum | isum | ašyg- «спешить» |
| sig | zuc- | sug- |

Шумер теле лексикасының татар теле лексикасы белән уртаклыгын чагыштырып караганда, О. Сулейменовның фикерләре дә бик әһәмиятле. Әлеге ике телнең уртаклыгын ул, генетик түгел, бәлки билгеле бер чорда тыгыз аралашу нәтиҗәсендә барлыкка килгән туганлык, дип атый һәм күрсәтелгән уртаклыкны мәдәни характердагы туганлык дип билгели. Автор бу мәдәни туганлыкны 1) бик борынгы һәм 2) соңгырак чорда формалашкан туганлык, дип, ике чорга бүлеп карый. Беренче чорда, телләр яңа туып, формалашып килгәндә, күбрәк гомум атамалар (кеше, табигать, мәдәният, мәсәлән, саннар һ.б.) кабул ителә. Ә соңгырак чордагы багланышлар әлеге телләр азмы-күпме формалашкан, сүзлек фонды шактый тулыланган шартларда бара һәм сүзләр алышу процессы да билгеле бер күләмдә чикләнгән була, һәм бу күренешләр алынган лексемаларның шактый ныклы сайланышына китерә. О. Сулейменов күрсәтүенчә, әлеге (соңгы) чорда культ лексикасы (мәсәлән, күбесенчә Алла белән, дин белән бәйле сүзләр) кабул ителә [Сулейменов, с. 228–229]. Соңгы елларда төрки телләрнең лексикасын өйрәнү бик интенсив рәвештә алып барылды. Нәтиҗәләр соңгы чор төрки телләргә мәдәният, фәлсәфә һәм эстетика кебек өлкәләр белән бәйле лексика, кыскасы, аеруча актуаль тармакларга карый торган мәдәни сүзләр яки алынмалар ешрак кабул ителүен раслый.

О. Сулейменов төрки һәм шумер телләре өчен уртак булган, кеше һәм Алла белән бәйләнешле лексиканың чагыштырма таблицасын төзегән. Түбәндә шуннан алынган материаллар тәкъдим ителә.

**Туганлык атамалары**: шумер: *Ада* (ата) ~ төрки *ата (aga)* – эти (гомумтөрки); шумер: *Ама* (ана) ~ *ама, аба, апа, ана* – ана (гомумтөрки). Шумер: *Амар* (бала, бозау, аккад телендә *мар* – ул ~ мара, мала, бала – бала, *ни-мара* (чагышт.: нәбәрә. *–Д.Р.*) – онык, *ще-бара* – онык баласы. Шумер *думу* – бала, нәсел дәвамчысы ~*Тума* – бала, нәсел дәвамчысы, буын (гомумтөрки); шумер. *Бильга* – төп баба, эпик каһарманның исемендә очрый: *Бильгамеш* (аккад халкы вариантында – Гильгамыш) ~ *Бильга* – акыл иясе (бор.-төрк.). Ясалышы: *биль* – бел; билим, *билик* – белем, акыл иясе, фән; *бильган* – белгән, акыл иясе. Бу сүз титулларда очрый, борынгы төрки текстларда эпик баба исемнәре белән килә: Бильга Бек – акыл иясе бәк, Бильга каган – акыл иясе каган, каган һ.б.

**Кеше, нәсел һ.б. атамалар:** Шумер: *Ту* (тудыру) ~ гомумтөрки *туу, тугу, туву, туру* – тудыру; *ту* (*туг, тув, тур*) – ту-, тудыр. Шумер: *Туд* – рус. родить ~ *тудъ* (тугдъ, тувдъ, тирдъ). Шумер: *тум* ~ *туъм* – туу, нәселне зурайту (гомумтөрки). Шумер: т*ир (тил, ти*) – гомер ~ тирик (тири) – тере (гомумтөрки), *турук* – тере, туру – яшәү, тур – яшә. Шумер: *Кир-сикил* (кыз, туташ) ~ *силик кыз* (кыз, гыйффәтле кыз). Шумер: *сикил* – чиста, *силик* ~ *силик* – чиста (бор.-төрки, төрек). *Сулук* – чиста. Шумер: *Гиг* – караңгы, кара, үлем ~ *гүйүк* (*күйүк*) – корым, караңгы; кайгы, күңелсезлек (гомумтөрк.).

Шумер: *угу (уг)* – нәсел ~ *ӱгӱш* – нәсел (гомумтөрк.), *уг* – нәсел, гаилә, ана (алт.). Шумер: *уг-кен* – җыелыш (сүзгә-сүз: киң нәсел ~ кен-ес (кенеш) – киңәшмә, җыелыш (гомумтөрк.), сүзмә сүз: киң акыл. Диал. *кен уй* (каз., кырг. һ.б. телләрдә). Кытай телендә дә чагылган: *кей-уй* – зур җыелыш, митинг (кей – зур, уй – җыелыш, төркем, өер һ.б.). Шумер: *Ме* – мин ~ мен (бен, бин, мән, бән) – мин. Шумер: *зе* – син ~ сен (сән, син) – син. монг. *би, си* – мин, син. Шумер: *Ане (ене)* – күрсәтү алмашлыгы. – ул, шул ~ әне (әнә, анау) – шул, ул.

Автор, шумер-төрки параллельләренең төрки телгә хас вариантлары еш кына *н* авазына тәмамланалар, дип нәтиҗә ясый һәм сүз азагында *н* барлыкка килү соңгы чорга хас дигән фаразны белдерә. Кайбер алтай телләрендә (мәсәлән, монгол телендә *би – мин)* алмашлыкларның азакларында *н* барлыкка килергә өлгермәгән [Сулейменов, 1975, с. 236].

**Соматизмнар.** Шумер: *шу* – кул ~ *уш (ус, ууш, уус)* – уч (гомумтөрки). Шумер: *шу-таг-ти* – эләктерде ~ *уш-та-ды* – эләктерде, тотты, тотып тора. Шумер: *кар* – урлау ~ *карма (карпа)* – талау (бор.-төрк.) *кар кул*, эләктер сүзеннән. Бор.-төрк. *кар, кары* – кулның бер өлеше, *карш* – карыш, бармаклар арасына тигез булган озынлык үлчәү берәмлеге. Шумер: *гештук* – колак ~ *ештук* – тыңлаучы. Шумер: *Емек* – тел ~ *емек (емук)* – тел, *Е* – ашау, *емек* – ашау коралы, *ему* – имчәк имү, *емук* – суыра торган әйбер, корал, әгъза.

**Эш һәм хәрәкәт атамалары.** Шумер: *Ру* – төзү, кыйнау ~ *уру,* төзү, кыйнау (гомумтөрк.). Шумер: *Сиг* – удар ~ с*ӱк (сӧк, шок, чок)* – сук (гомумтөрк.). Шумер: *Таг* – тагу, тоташтыру ~ *так (таг)* – так, када, как, тоташтыр (гомумтөрк.). Шумер: *Сир (сур)* – туку ~ *серӱк (серӱ)* – туку станогы, *сермак* – тукыма (бор.-төрк.). Димәк, *сер* – тукы, казакъ. *сыр* – тек, *сыр, сырмак* – сырма, сырган ковер. Шумер: *Ед* – үтү, чыгу ~ *ӱт (ӧт, ид, ед, ет, ат)* – бар, үт, күч (гомумтөрк.). Протезалашкан формалары: *кет, геть, кит* – кит (гомумтөрк). Шумер: *Гин* – бар ~ *кель (киль, гель)* – кил. Шумер: *Заг-гин* – якынаю ~ *җакын (йакин, закин)* – якын. Шумер: *Гу* – тавыш, аваз ~ *кӱ* – аваз, тавыш, көй (гомумтөрк.). Шумер: *Гулше* – шат, күңелле ~ *кӱлиш, гӱлӱш* – көлү, шатлык (гомумтөрк.); *кулу, гулу* – көлү, тавыш бирү, аваз чыгару. Шумер: *Гештука* – тыңлаучы ~ *ештуган (естуган, естиген)* – тыңлаучы (гомумтөрк.), е*ш (ес)* – аң, ис, ешит (есит) – тыңла. ешту (есту) – тыңлау.

**Корал** һ.б. Шумер: *Тир* (тил, ти) – ук ~ *тирик.* ~ корал, ядрә, ук (сагайча). Башка телләрдә *тир* тамырыннан очлы, чәнчү, тишеп чыгу, тырнау һ.б. мәгънәләрдәге күп кенә сүз оялары ясала. Шумер *ши (зи), Ти (ди)* – тормыш, күңел, рух ~ *щи (чи, джи, зи)* – суффикс, кешене белдерә (гомумтөрки). Шумер: *Ерен* – рядовой сугышчы, эшче ~ *ерен (әрән, ерән)* – рядовой сугышчы, иярүче, адепт; сугышчы, ир кеше (борынгы төрки, төрек, уйгыр һ.б.); *ер* – кем артыннан булса да ияр. *Ерен* – иярүче, ияргән. Шумер:

*Ере (ер)* – кол, алдагы сүзнең үсеш дәвамы ~ *ер* – сугышчы, ир кеше, каһарман (гомумтюрки). Шумер: *Шуба (сипа)* – көтүче ~ *шупан (чубан, чобан, чабан)* (гомумтөрки) – көтүче, чабан.

**Йорт, өй һ.б. атамалар.** Шумер: *аб* – ишек ~ *ав (аб, ев, еб, ӱй)* – өй (гомумтөрки). Шумер *еш* – өй ~ ешик (есик) ишек (гомумтөрки). Шумер. *Ру* – төзү, торгызу, сугу ~ Уру – төзү, торгызу, төзү; сугу (гомумтөрк.). *Урук* –крепость, кала, җыен ~ урук – төзелгән; кала, каладагы халык, кавем.

**Табигать.** Шумер: *Сакар* – тузан, ком ~ чакыр – ком, вакташлар (төрек.). *Чака* – песок (чыгтай.). *Чак йар* – вак балчык, ватылган балчык, вакланган балчык. Шумер. *Тибира* – бакырлык (бакыр чыга торган җир) ~ *тебир (тебер, тибир, дебьр, тäбир, дäбир, темур, темир, томор, тӧмур, томуз)* – тимер; бенгаль телендә «томор» - бакыр. Шумер: *Забар, дабир* – бакыр, бронза ~ шул ук тибира. Шумер. *Узук* – озын, биек ~ узун – озон (гомумтөрк.), узак – озын (казакъ, тат., башк.). Шумер: *Туш (шуш)* – төшү, утыру ~ *тӱш (тӱс)* – төшү (гомумтөрк.). Шумер: *Уд* – кояш, көн ~ *ӱт (ӱд, ӧд)* – өйлә вакыты, төш вакыты, вакыт (бор.-төрк.). Шумер: *Уд – ут ~ Үт (уд, от, од)* – ут (гомумтөрк.). Шумер: *Удун – учак ~ Утун (удун, отун, одун, отын)* – утын, ягулык (гомумтөрк.). *Отдан* – светильник – шәм (уйгыр); (чаг. Шәмдәл. – *Д.Р.*). Шумер: *Уду* – кояш алласы, изге ~ *Удук (ыдук)* – изге (бор.-төрк.). Шумер: *Дингир (демер)* – Алла, күк (йөзе) ~ *Тенгир (тегри, дäнгир, тенир, тäнир)* – Алла, күк йөзе (гомумтөрк.), чув. тенгир – диңгез. Шумер: *Тингир, тигир* – елга исеме ~ башка төрки телләрдә *тенгиз (тениз, дениз, дангиз)* – диңгез, зур елга. Күк/дингиз мәгънәләрнең күчү мөмкинлеге төрле телләрдән табылган мисаллар белән раслана. Чувашларда *р* белән гомумтөрки *з* авазларының чиратлашуы системалы характерда. Шумер: *Нам* – язмыш (сүзгә сүз *на-ме* – «бу нәрсә» дигән сүз) ~ *На-ма* – бу нәрсә(гомумтөрки). Шумер: *Дуб* – балчык таблица, документ ~ *Туп* – яндырылган кирпеч (төрек).

Шумер: *Еден* – дала ~ *еден* – юртада: идән (казакъ); *адан* – юртаның төбе, асты, нигезе (чыгтай). Шумер: *Ерен* – кедр (омонимы *ерен* – рядовой сугышчы, эшче) ~ *ерен* – карама, өрәңге (уйгыр), аның омонимы *ерен* – рядовой сугышчы, иярүче (ерен – яран). *Ер* – ияр, йөре. *Ер* – эре, агып тор, иярүче. *Ерен* – эрегән, сусыл һ.б.

Казакъ телендә *ермен* – әремнең бер төре, уйгыр телендә *емен* – шул ук мәгънәдә (*Р* авазының әйтелмәве *й* сонорына күчү белән дә бәйле булырга мөмкин икәнен дә исәпкә алырга кирәк. – *Д.Р.*). Казакълар да шулай ук татарлар да *емен* сүзен *имән* мәгънәсендә үзләштергәннәр. Төрекләрдә кедр атамасы шул тамырдан, ләкин башка кушымчалар белән ясалган: *ерс, ерз.* Шумер: *Кур* – тау ~ *кур* – төзе (гомумтөрк.). *Ур* сүзенең варианты. *Кыр* – тау сырты (гомумтөрк.). *Кура (кора)* – дала, стена белән тотып алынган урын. *Кӱр (кӧр)* – кабер өеме (гар. *гур? – Д.Р.*). Шумер: *Кир* – җир ~ *кир* – былчырак, кер, балчык

(гомумтөрк.). *Йир (йер, йар, җер, дҗер, зер, дьер)* – җир.

**Хайваннар, үсемлекләр.** Шумер: *Амар* – бозау, терлек (хайван) баласы; аккад телендә *мар* – ул бала ~ *мара* – хайван баласының бала булып исәпләнә торган чоры, вакыт (төр.); *мараа (марка)* – сарык бәрәне (гомумтөрк.); *пару* – бозау (чув.) (< баран. – *Д.Р.*). Шумер: *Амар-ан* – изге хайван: күк йөзе бозавы ~ *маран (марал, бара)* – чуар болан; изге хайван (Алтай-Себер ареалы). Шумер: *Уду* – бәрән, кояш алласы, изге ~ *удук (ыдук)* – изге (бор.-төрки). Шумер: *Гуд* – үгез ~ *Уд* – үгез, мөгезле терлек (бор.-төрк.), *гудаа* – үгез болан (тофалар.) Шумер: *Кункал* – курдюклы сарык ~ *конкал* – болан баласы (тофалар); төньяк халыклары сарык белән бәйле атамаларны боланнар классына күчергәннәр булса кирәк; *кон* – курдюк (казакъ, уйгыр һ.б.) + *калн* – юан, зур. Шумер: *Узуг (узу, уз)* – су кошы ~ *йўзўк* – су кошлары (гомумтөрк.) < йўрўк. Шумер. *Гаш* – *кош* ~ *куш (кус)* – кош, су кошы (гомумтөрк.). Кушма сүзләрдә «гаш», «гай». Мәсәлән: *карлыгаш* – *карлыгач* (каралы кош); *торгай* – туры (гнедой) кош, *карга* – карга (кара кош). Боларны тагын *каз (газ)* сүзе (гомумтөрк.) белән чагыштырырга мөмкин. Шумер: *Гиш* – агач, *иш* формасында аккад теленнән кергән ~ *егиш (егис, ӓгӓш* – культуралы үсемлек, кыяклы ашлыклар (казакъ, уйгыр)), *ег* – утырт, чәч, күм. Җимеш агачлары төп культурага әйләнгәч: *егиш (ӓгиш)* – җимеш агачы. Алга таба бу сүзнең мәгънәсе түбәндәгечә конкретлаша: 1) *Агаш, агач, ыгач* – агач (көнбатыш төрки ареал), кушма сүзләрдә *гаш, гач, гай*. Балкар, ногай телләрендә *агач* – урман. 2) *Ыйаш, йыш, йыс* – урман (Себер ареалы). 3) *Чыш, чис* – урман (Алтай).

**Тирә-як, әйләнә-тирә** (пространство). Шумер: *Шаб* – урта ~ *шаб (чап, саба)* – өз (чабып) (гомумтөрк.), *чабар* – урта (уйгыр). Шумер: *шаг* – урта ~ *шак (чак, сак)* – урталай яр; тигез өлеш, вак-төяк (чагышт.: диал. уланшак – бала-чага. – *Д.Р.*) (гомумтөрк.). Шумер: *Заг* – як, ян ~ *жак (йак, джаг, зак)* – як, ян (гомумтөрк.).

**Аллалар.** Шумер: *Аш* – сызык, берәмлек ~ *аш (еш, ес, иш)* – кис, тел. Протезалашкан формалары: *кеш (кас, кес, кис)* – кис, сыз. *Пеш (пас, пиш, пис)* – кис, сыз. (гомумтөрки *пыч* тамыры. – *Д.Р.*). Шумер. *Иши* – көл, тузан, ком бөртеге. Аккад теленә *иш* – кечкенә, иң кечкенә, атом дип кабул ителгән ~ *Иш (еш)* – иң кечкенә, атом (гомумтөрк.); *киши (кичи)* – кече, кечкенә (гомумтөрк.); *пиши (бичи, биши)* – кечкенә (диал. печтек). Шумер: *Дили* – сызык, берәмлек ~ *тилик (тили, дилик, дили)* – сызык, юл (полоса), телем (гомумтөрк.). *Тиль (диль)* – сыз, тырна (царапай); телгәлә сүзеннән ясалган. Шумер: *Деш* – нокта, берәмлек ~ *Тешик (дешик, тесик)* – нокта, тишек (гомумтөрк.). *Теш (деш)* (тиш, нокта яса) дигән сүздән. *Уш* – *өч* ~ *ўш (ўч, ўс, ис)* – өч (гомумтөрк.).

Шумер: *У– ун* ~ *ун (он)* – ун (гомумтөрк.). Шумер: *Уш-у* – утыз ~ *ўш-ун* – утыз (Алтайда, Себер ареалында сакланган). Шумер: *Ан* – күк, йолдыз ~ *Ан (ай)* – ай (гомумтөрк.). Бу та-

мыр *анык* (чиста, якты, ачык) сүзенең тамырында да сакланган. Шумер: *Ен* – иң югары ~ *ен* – иң югары (предельный), иң, әйләнә. Шумер: *Кен – киң ~ кен* – киң (гомумтөрк.). Шумер: *Кена (кина)* – чын, чынбарлык, чынлап ~ кин – чын, чынбарлык, чынлап. *Шин (Чин)* – шулай ук. *Син (сен)* – ышан [Сулейменов, 1975, с. 239–242].

Билгеле булганча, телдә кайчандыр бер иҗекле сүзләр кулланылган, күп вакытлар үткәч әлеге тамыр сүзләрнең башта морфологик, тора-бара синтаксик дериватлары формалаша. Мәсәлән: *баш → баштак → баш баштак, буй → буйлы → үзбуйлы* һ.б.; еш кына дериватлар тамыр сүзнең синонимнары булып торалар. Хәзерге телдәге *суыну, бетерү* һ.б. сүзләрнең диалектларда *суу, бетү* формалары әле дә сакланып килә. Менә бу күзлектән караганда, борынгы чыганакларны өйрәнү шулай ук кызыклы нәтиҗәләр бирә. Мәсәлән, шумер телендә кайбер сүзләрнең тамыр формалары кулланылган: шумер: *у* – үсемлек (борынгы телдә – *ут*); этруск *ута* – үлән, үсемлек; *утар* – чәчелгән җир; *уθ* – ут, якты, этруск *уд* – шулай ук, татарча *ут* – свет, огонь; шумер: *ка (авыз)*, этруск *савус* – бушлык; *капу* – капка; *ис* – ишетү, этруск *ише* – ишетү; шумер: *ту* – туу, этруск *туд* – тудыру; *ме* – мин; *зе* – син; *е* – ашау (тат. диал. йийү), *се* – сеңел, *еш* – ишек һ.б.

Югарыда Ф.Р. Латыйпов буенча китерелгән таблицадагы кайбер сүзләр хәзерге татар телендә алынмалар рәтендә йөри: *силим* – рус. здравие, татар. *сәламәт* (гарәп алынмасы булып санала); *изба* – йорт (рус алынмасы санала); *эвен* (русча овин), *есерү* – рәсем ясау, *срен* – рәсем, сүрәт – рәсем (гарәп алынмасы санала) һ.б. Димәк, бу сүзләр безнең баба телебездән үк билгеле борынгы уртаклыгыбыз булырга мөмкин.

Ф.Р. Латыйпов шумер һәм этруск телләренең төрки телләр белән уртаклыгын тикшергәндә Казан төркиләре (татар) теле белән янәшәлекләрне аерым карый.

Борынгы язма чыганакларның телен уку, өйрәнү хәзерге телнең тарихын, сүзләрнең килеп чыгышын ачыкларга ярдәм итә. Мәсәлән, шумерларның *тир* (тил, ти) сүзе гомер мәгънәсендә дип күрсәтелә, хәзерге телдәге *тере / терек, тереклек* сүзләренең тамыр варианты. Шумер: *уг/угу* – нәсел, гомумтөрки *үгүш* – нәсел, *үг* тамыры исә татар телендә үксез, үги сүзләрендә генә сакланып калган.

Семантик үсеш-үзгәреш ягыннан да кызыклы мисаллар китерергә мөмкин: шумер: *Еден* – дала, тигезлек → тирмә идәне – тат. идән; шумер: *Кункал* – куй сарыгы – конкал (тофалар) – болан баласы. Шумер: *Гаш* – кош, димәк, хәзерге карлыгач (каралы кош), сандугач (санду(?) + кош) сүзләренең этимологиясен ачыклау өчен төрле версияләр бар.

Компонентлары синонимнардан торган парлы сүзләргә дә мисаллар күбәя бара: тат.әд. *тимер-томыр* (шумер: Томор – металл исеме) һ.б., ягъни әлеге парлы сүзнең компонентлары үзара синонимнар булып торалар. Шулай

итеп, шумер теле буенча табылган һәм төрки телләргә тамырлары белән охшашлык, мәгънә уртаклыгы күрсәтә торган шактый бай лексика теркәлгән. Бу исә О. Сулейменовның, шумер теленең төрки телләр белән уртаклыгы генетик тугандашлык ягына тарта кебек, дигән фикерен раслый булса кирәк.

**Әдәбият**


*Ахунов А.М.* Исламизация Волжско-Камского региона (VII–X вв.). Казань: Отечество, 2003. 215 с.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең кыскача тарихи этимологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда. I т.: А–Л. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 543 б.

Большая советская энциклопедия. Издание III. Т. 29. М.: Советская энциклопедия, 1978. 640 с.

*Дьяконов И.М.* Языки древней Передней Азии. М., 1967.

*Зәкиев М.З.* Татар халкы тарихы: этник тамырлары һәм киләчәге. Казан, 2008. 544 б.

*Латыпов Ф.Р.* Факты шумерского языка как основного предтюркского субстрата, участвовавшего в формировании пратюркских языков Древнего Ближнего Востока. Уфа: Полиграфиздат, 2009. 68 с.

*Латыпов Ф.Р.* Лечебные заклинания и термины в этрусском языке // Проблемы изучения и преподавания тюркской филологии: история, современность, перспективы (сб. Материалов научно-практической конференции с международным участием (СГПА им. Зайнаб Биишевой, Стерлитамак, 24–26 мая 2012 г.). Стерлитамак, 2012. С. 187 –189

*Латыпов Ф.Р.* Тюрки – наследники древних контактеров с космическими пришельцами (предположение о космической этимологии макроэтнонима тюрк). – Уфа: Полиграфдизайн, 2013. 60 с.

*Мусаев К.М.* Лексика тюркских языков в сравнительном освещении (западнокыпчакская группа). М.: Наука, 1975. 358 с.

*Нафиков Ш.* Тамыры уғата боронғо башҡорт: һайланма яҙмалар. I т. Өфө, 2009. 413 б.

*Пьянков И.В.* Средняя Азия в античной географической традиции: источниковедческий анализ. М., 1997.

*Сулейменов О.* Аз и Я. Книга благонамеренного читателя. Алма-ата: Изд-во «Жазумы», 1975. 304 с.

*Трубачев О.Н.* Происхождение названий домашних животных в славянских языках. – М., 1960.

*Туна О.Н.* Osman Nedim Funa. Sümer ve Türk Dillernin Tasini ildisi ile Türk Dili’nin Yaşl Meselesi. – Ankara, 1990.

*Фиридун Агасыоглу.* Азер халгы (сечмә јазылалар). Баку, 2000.

*Хоммель Фр.* Hommel Fr. Zweiundert sumerotürkische Worttdleihenden. Münhen, 1915.



***Рамазанова Дария Бәйрәм кызы,*** *филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145'373

*М.З. Зәкиев*

# ТАТАР ТЕРМИННАРЫ ЯСАЛУ ҺӘМ АЛАРНЫ ТӨРКЕМЛӘҮ

В статье речь идет о способах образования и классификации татарских терминов. В качестве терминов, выражающих специальные понятия, выступают слова и словосочетания. В основе образования терминов лежат способы образования слов и словосочетаний. Вместе с тем к способам образования терминов относят также терминологизацию, т.е. переход общеупотребительных слов в термины, и ретерминологизацию, т.е. перенос готовых терминов из одной дисциплины в другую с полным или частичным переосмыслением. Различаются теоретические термины, профессионализмы и номенклатуры. Терминология постоянно обогащается и за счет заимствования и калькирования, а также сокращения словосочетаний (аббревиатуры).

**Ключевые слова**: специальные понятия, термины-слова, термины-словосочетания, терминологизация, ретерминологизация, детерминологизация, профессионализмы, номенклатура.

Термин ул кайсы да булса бер фән яки эшчәнлек өлкәсендәге махсус төшенчәне белдерә торган сүз яки сүзтезмә. Махсус төшенчәләрне төрле шартлы билгеләр, символлар, формулалар да белдерәләр. Ләкин болары терминнар составына керми. Күп фәннәрдә һәм кеше эшчәнлегендә махсус төшенчәләр йөзәр меңнәр белән исәпләнәләр, аларны тел чаралары белән белдерү өчен бер генә телдә сүзләр җитми, шуңа күрә аларның күбрәк өлеше сүзтезмәләр белән белдерелә. Җөмләләр белән бирелә торган махсус төшенчәләр дә бар: *җир тетрәү* ‘землетрясение’, *кояш тотылу* ‘затмение солнца’. Болары да термин-сүзтезмә рәтеннән карала.

Шулай итеп телнең сүзлек составында **гадәти сүзләрдән** аерылып тора торган **термин-сүзләр** дә урын алган. **Термин-сүзтезмәләр** белән янәшә **гадәти сүзтезмәләрне** дә күрсәтәләр. Шулай итеп гадәти сүзләргә – термин-сүзләр, гадәти сүзтезмәләргә термин-сүзтезмәләр каршы куела.

Термин-сүзләрне, термин-сүзтезмәләрне гомумиләштереп *номенклатура* дип тә атыйлар. Ләкин бу сүзнең, терминнарны җыеп атау мәгънәсе белән бергә, югары оешмалар тарафыннан билгеләнгән хезмәткәрләрне атавын да онытмаска кирәк.

Терминнарны җентекләп өйрәнгән (терминолог) В.П. Даниленко махсус төшенчәләрне белдерүче сүзләрне һәм сүзтезмәләрне телдән тыш чаралардан аерып карауга әһәмият бирә. Телдән тыш чараларга ул төрле билгеләрне, график символларны, саннарны кертә. Аларны төрле фәннәрдә (математикада, физикада, химиядә һ.б.) өйрәнүне фән өчен әһәмиятле дип искәртә [Даниленко, 1971, с. 8].

Реаль чынбарлыкта телдән тыш чаралар (символлар, форму-

лалар, диаграммалар, саннар) үзләре генә кулланыла алмыйлар, аларны аңлату, төшендерү, аларның кулланылыш даирәләрен күрсәтү өчен тел-сөйләм кирәк була. Бер генә фәнне дә телсез-сөйләмсез үстереп, яшь буынга биреп булмый. Кайбер төгәл фән галимнәре, мәсәлән, математик теоремаларны аңлатканда, сөйләмнән башка да эш итеп була, дигән фикердә торалар. Болай уйлау ялгыш. Шуны истән чыгармаска кирәк, формулалар, төрле билгеләр белән бирелә торган теорияләрне аңлаткан хезмәтләр кайсы да булса бер телдә язылалар, аларны шул телдән башка телләргә тәрҗемә итәргә дә мөмкин була [Зорин..., 1971, с. 69].

Термин-сүзләр составлары буенча 5 төрле булалар: 1) тамыр термин-сүзләр: *көн* ‘день’, *ел* ‘год’; 2) ясалма сүзләр: *язучы* ‘писатель’, *кешелек* ‘человечество’; 3) кушма сүзләр: *төньяк* ‘север’; 4) парлы сүзләр: *ата-ана* ‘родители’; 5) кушма-кыскартылма сүзләр – аббревиатуралар: *АКШ* ‘США’, *ТФА* ‘АНТ’ (Академия наук Татарстана).

Бу мәкаләдә минә шул биш төрле термин-сүзләрнең ясалу ысулларын яктырту бурычы куелды.

*Термин* сүзе латинча *terminus* – ‘чик’ сүзеннән алынган. Термин ул кайсы да булса бер фәндәге, нинди дә булса бер эшчәнлектәге ниндидер төшенчәне белдерә торган сүз яки сүзтезмә. Фәннәр табигый, техник һәм гуманитар дигән белемнәр тирәсенә туплана, аларны өйрәтүче, үстерүче, өйрәнүче кешеләр була, алар бу эшләрендә шул фәннәрнең терминнарын кулланалар.

Нинди дә булса бер фәннең терминнар җыелмасын «терминология» дип атыйлар. Төрле сүзлекләрдә терминология сүзенең бары шул мәгънәсе генә бирелгән. Бу, билгеле, тулы һәм дөрес була алмый. Терминология сүзендә ‘өйрәтмә, аңлатма, фикер, сүз’ мәгънәләрендә кулланыла торган *...лог* өлеше бар. Шулай булгач *терминология* сүзе терминнар турындагы фәнне дә атарга тиеш.

Терминология фәнендә һәр халыкның үз терминнар җыелмасы була, ягъни үз терминологиясе була дип аңлатыла: рус терминологиясе, инглиз терминологиясе, казакъ терминологиясе, татар терминологиясе һ.б.

Һәр фәннең үз терминнары җыелмасы була, ягъни һәр фән үз терминологиясе белән характерлана.

Фәннәрне, иң элек, өч төркемгә аералар, шуңа карап, гомуми терминология дә өчкә бүленә:

1) табигый-фәнни терминнар: боларга астрономия терминологиясе, химия терминологиясе, биология терминологиясе, авыл хуҗалыгы терминологиясе һәм башка табигый-фәнни терминологияләр керә;

2) фәнни-техник терминология составына физика, математика, технология, төзелеш, авиация, тимер юл, нефть сәнәгате һ.б. терминологияләр керә;

3) гуманитар белемнәр терминологиясе тарих, фәлсәфә, хокук белеме, филология, сәнгать белеме, культурология, икътисад, социология, педагогика, психо-

логия, экология кебек фәннәрнең терминологияләреннән тора.

Филологик терминологиянең үзенең составына әдәбият белеме, фольклористика, лингвистика, чыганаклар белеме, текстология, лингвистик география, палеография (язу белеме) терминнары җыелмалары керә.

Терминология (терминнар җыелмасы) дигән термин белән фәннәрнең аерым өлешләренә караган терминнар җыелмасын да атыйлар. Мәсәлән, лигвистик терминология враграк җыелмаларга – фонетика терминологиясе, лексикология терминологиясе, морфология терминологиясе, синтаксис терминологиясе, стилистика терминологиясе кебек төркемнәргә аерыла. Мондый терминнар җыелмасын гомумиләштәреп **терминологик система** дип атарга тәкъдим итүчеләр дә бар [Исхакова, 1987, с. 3].

Телнең гомуми лексик системасына термин бары конкрет бер терминологик система берәмлеге буларак кына керә, дип раслыйлар рус терминологлары.

Термин турында язылган энциклопедик мәкалә авторы Н.В. Васильева **термин** үзенчәлекләрен түбәндәгечә санап күрсәтә:

1) системалылык;

2) билгеләмәсе-дефинициясе булу (күпчелек терминнар өчен);

3) термин үз фәне терминологиясе составында моносемантизмга (бермәгънәлелеккә) омтыла, ләкин шуны да истән чыгармаска кирәк: кайбер терминнар төрле фәннәрдә кулланылалар һәм төрлесендә төрле мәгънә белдерәләр, мәсәлән, *функция* термины а) иҗтимагый мөнәсәбәт өлкәсендә ‘йөкләнгән бурыч’, ‘вазифа’, ‘эш-хезмәт’ мәгънәсен бирә; ә) математикада ‘үзгәрешләре бер-берсенә бәйләнешле булган күренешләр’ мәгънәсендә кулланыла; б) физиологиядә ‘организмның, төрле органнарның үз эшләрен үтәве’ мәгънәсен белдерә; в) лингвистикада ‘тел берәмлегенең ниндидер башка бер функциядә килүе’ мәгънәсен бирә һ.б.;

4) экспрессиясе булмау, ягъни тойгысыз кулланылуы;

5) стилистик яктан битараф булуы.

Терминнарның бу үзенчәлекләре үз терминологияләре составында гына саклана, гадәти сөйләмгә чыгып китсә, термин гадәти сүзгә әйләнә, ягъни детерминологизациягә бирелә: мәсәлән, *шайба, клюшка* кебек спорт терминнары, һәр гаиләдә, бала-чагалар арасында кулланылып, татар теленең гадәти сүзенә әйләнделәр.

Терминның бер төшенчәне белдерергә, ягъни моносемантизациягә омтылышы да үз фәне терминологиясе составында гына күзәтелә. Башка фәндә кулланыла башлый икән, аның төшенчәсе дә үзгәрә, башка сүзгә-терминга әйләнә. Моңа мисал итеп, *операция* һәм *ассимиляция* терминнарын китерергә мөмкин.

**Операция** термины: 1) гуманитар белемнең иҗтимагый-сәяси өлкәсендә ул ‘эш-хәрәкәт, чара’ төшенчәсен, 2) хәрби өлкәдә ул ниндидер максатка ирешү өчен оештырылган хәрби эш төшенчәсен, 3) медицинада – савыктыру максаты белән ясалган хирургик эш төшенчәсен, 4) фи-

нанс-икътисад өлкәсендә – финанс документларын әзерләү төшенчәсен, 5) сәнәгать өлкәсендә нәрсәне булса да ясау, кору эшен бер җирдә, бер вакытта башкарып чыгу төшенчәсен белдерә.

**Ассимиляция** термины: 1) тел гыйлеме өлкәсендә бер авазның икенченә тәэсир итүен, мәсәлән, *урманда* сүзендә яңгырау [*н*] авазыннан соң урын-вакыт килеше кушымчасындагы беренче аваз яңгырау әйтелә (*-да*), *тышт*а сүзендә *тыш* тамырындагы саңгырау [*ш*] шул ук килеш кушымчасын саңгырау аваз белән башларга этәрә *-та*. Биредә саңгыраулыкта яки яңгыраулыкта авазлар яраклашуы – *ассимиляция* барлыкка килә; 2) иҗтимагый-сәяси өлкәдә бер милләт кешеләренең телләрен, гореф-гадәтләрен алмаштыру нәтиҗәсендә башка милләт кешеләре булып үзгәрүен белдерә һ.б.

«Лексика русского языка» дәреслеге авторы А.В. Калинин рус телендә терминнарны дөрес кулланмау нәтиҗәсендә дә кайбер терминнарның моносемантикалыгы бозыла дип яза. Мисал итеп ул *синтагма* терминын кайберәүләрнең дөрес кулланмавын китерә: *Синтагма* – ул сөйләмдә җөмләнең интонацион буыннары, ләкин аны ялгыш *сүзтезмә* мәгънәсендә куллану да очрый, ди автор.

Терминологиянең тагын бер кимчелеген А.В. Калинин кайбер терминнарның синонимнарын да булдырудан күрә. Мәсәлән, рус телендә, *сказуемое* терминына синоним итеп, *предикат* сүзен дә кулланалар. Татарчада да *хәбәр* сүзе урынына *предикат* терминын куллану очраклары күренә. А.В. Калинин *многозначность – полисемия* (татарчада: *күпмәгънәлелек – полисемия*), *орфография – правописание* (татарчада: *орфография – дөрес язылыш*), *азбука – алфавит* кебек синонимнарның кулланылышын терминологик системаның бозылуы дип карый [Калинин, 1966, с. 138].

Хәзерге лингвистикада терминнардагы тулы синонимлык кимчелек санала, ә өлешчә генә синонимлыкны телне бизәкләү чарасы итеп кенә карыйлар.

Терминнарны тагын **гомумаңлаешлы** (общепонятные) һәм **тар махсус** (узкоспециальные) дигән төрләргә дә бүләләр. Гомумаңлаешлы терминнар билгеле бер фән өлкәсендә белгеч булмаган затларга да аңлашыла, **тар махсус** терминнар бары теге яки бу өлкәдәге белгечкә генә аңлашыла.

Терминологлар тагын **фундаменталь-теоретик** терминнарны *номенклатурадан* аерып йөртергә тәкъдим итәләр. Аларның беренче төре төп фәннең гомуми теоретик төшенчәләре *теорема, аксиома, диогональ, төрләнеш, материя* һ.б.ны белдерә. Икенче төре – номенклатура ул теге яки бу белем яки эшчәнлек өлкәсендәге әйберләрнең, эшләнгән продукциянең, коралларның исемнәре була.

Кайбер галимнәр, мәсәлән, татар терминологы Ф.С. Фасеев фикеренчә, номенклатурага караган терминнар башта халык телендә гадәти сүз булып йөриләр, ләкин фәннәр барлыкка килгәч, алар, теге яки бу фәндә кулланылып, фәнни номенклатура, ягъни

фәнни термин булып та үзгәрәләр. Мәсәлән, анатомиядәге *сөяк, умыртка, кабырга, тире* (тән тиресе), *тырнак* кебек номенклатуралар башта халык телендә гомумаңлаешлы сүз булып йөргәннәр. Химиядәге *тимер, күмер, су, тоз* терминнары да башта гадәти сүз булып халык телендә кулланылганнар. Мондый гадәти сүзләр термин буларак кулланылсалар, аларның төшенчәләренә фәнни билгеләмә бирелә.

Фундаменталь-теоретик терминнар, нигездә, термин буларак кына саклана, халык теленә бик сирәкләре генә үтеп керә, ә номенклатура халык телендә гадәти сүз буларак саклана.

Термин төшенчәләрен белдерүдә аерым профессиягә хас булган сүзләр – **профессионализмнар** да катнаша ала. Термин ул теге яки бу фәндә, сәнәгать, авыл хуҗалыгы яки техникада рәсми кабул ителгән төшенчәне белдерә торган даими кабул ителгән сүз, ә профессионализм – ул рәсми кабул ителмичә генә теге яки бу эш, профессия кешеләре тарафыннан сөйләмә телдә куллаңыла торган сүзләр [Калинин, 1966, с. 143]. Профессионализмнар терминнар белән янәшә кулланыла: термин рәсми телдә, профессионализм – теге яки бу профессия кешеләренең сөйләмә телендә. Мәсәлән, балыкчыларның, аучыларның үзара гына аңлашу өчен кулланыла торган профессионализмнары бар.

Югарыда әйтелгәнчә, фәнни төшенчәләрне телдән башка чаралар – формулалар, символлар, фәнни шартлы билгеләр дә белдерә ала. Мәсәлән, математикада √ – тамыр билгесе, *Cu* – бакырның (*купрум* дигәннең) кыскартылып язылган билгесе һ.б.

Галимнәрнең тануына караганда, тюркологиядә терминнар буенча язылган мәкаләләр, монографияләр күп булса да, барлык төрки телләр терминологиясенә нигез булырлык хезмәт тудырылмаган әле. Төрки академиядә бу эш башланды инде дип әйтергә мөмкин.

Югарыда әйтеп үткәнчә, термин ул сүз яки сүзтезмә була, шуңа күрә аның ясалышы сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең ясалышына нигезләнеп өйрәнелә.

1950–1960 елларда татар теле терминнарының ясалыш ысулларын Ф.С. Фасеев җентекләп өйрәнә, кандидатлык диссертациясен яза һәм 1961 елда Мәскәүдә Тел гыйлеме институтында «Способы образования терминов в татарском литературном языке» дигән исем астында аны бик уңышлы яклый.

Татар телендә сүзьясалыш проблемаларын Ф.Ә. Ганиев күп еллар дәвамында җентекләп өйрәнә. 1973 елда ул «Фонетическое словообразование в татарском языке» (40 бит), 1974 елда «Суффиксальное словообразование в современном татарском литературном языке» (232 бит) дигән китапларын бастырып чыгара. Сүзьясалыш проблемаларын тагын да җентеклерәк өйрәнеп, Ф.Ә. Ганиев татар теленең өч томлы академик грамматикасының беренче томында татар телендәге сүзьясалышын тагын да җентекләп, системага салып аңлатты. Болар барысы да терминнар ясалышы

проблемаларына да ачыклык кертәләр.

Ф.С. Фасеев термин ясалышында эре өч төркемне аерып чыгара:

1) телнең сүзлек составындагы сүзләрнең термин булып килүләре;

2) ана теле сүзләренә нигезләп яңа сүзләр ясау;

3) терминнарны башка телдән, бигрәк тә рус теленнән әзер килеш алу.

Туган телгә нигезләп яңа терминнар ясауның биш төрле ысулы бар, ди ул: 1) семантик ысул, 2) фонетик ысул, 3) морфологик ысул, 4) синтаксик ысул, 5) кушма сүзләрне кыскарту (аббревиатура).

Сүзьясалыш юлларын тикшергәч, Ф.Ә. Ганиев түбәндәге ысуларны күрсәтә: 1) суффиксаль (морфологик) ысул: *дәрес* ‘урок’ – *дәреслек* ‘учебник’; 2) сүзләрне кушып сүз ясау (анынча, бу синтаксик юлга кереп бетә алмый): *каракош* ‘орел’ – көнчыгыш ‘восток’; 3) фонетик ысул: *күз* ‘глаз’ – *күрү* ‘видеть’ (бу ысул сирәк кулланыла); 4) лексик-грамматик ысул, моны ул конверсия юлы дип атый (бу – кайбер төр фигыльләрнең исемләшүе, кайбер исемнәрнең рәвешләр булып әверелүе, кайбер исемнәрнең сыйфатка әйләнүе һ.б.); 5) лексик-семантик ысул: *йомгак* ‘клубок’ – *йомгак* ‘вывод’, *ия* ‘владелец, хозяин’ – *ия* ‘подлежащее’; 6) аббревиация: *вуз* ‘высшее учебное заведние’, *политбүлек* һ.б.

Терминнарның ясалыш ысулларын өйрәнгәндә, сүзьясалышның мондый ысулларын да истә тотарга туры килә. Ләкин термин ясалышы ысулларын үзенчәлеклерәк төркемләү кабул ителгән. Алар Ф.С. Фасеевның «Татар телендә терминология нигезләре» дигән китабында тасвирланган [Фасеев, 1969, б. 200]. Бу китапта тугыз ысул санала.

1. Гомумкулланылыштагы гадәти сүзләрне термин-сүз итеп куллану: *нигез* ‘фундамент’ – *нигез* ‘основание’ (химия яки төзелеш өлкәсендә). Гомумкулланылыштагы сүзтезмәләрне термин-сүзтезмә итеп куллану: *йөрәк тибүе* ‘сердцебиение’, *кан әйләнеше* ‘кровообращение’, *җир асты кабеле* ‘подземный кабель’ һ.б.

Терминологизациягә, икенче төрле әйткәндә, термин төшенчәсен белдерүгә төрле сүзләр тартыла: 1) әдәби телдә актив кулланылган сүз: *аклау* ‘реабилитация’, *алкыш* ‘аплодисменты’, *илче* ‘посол’ һ.б.; 2) телгә кабул ителеп җиткән гарәп-фарсы сүзләре: *гомумиләштерү* ‘обобщение’, *сәүдә* ‘торговля’ һ.б.; 3) диалекталь сүзләр дә термин буларак кулланылырга мөмкин: *җайдаклы* ‘всадник’, *тәңгәл* ‘адекватный, тождественный’, *элемтә* ‘связь’, *онык* ‘внук’; 4) әдәби сөйләмә телдәге сүзләр: *түбә* ‘вершина’, *күзәнәк* ‘клетка’ һ.б. [Фасеев, 1961, с. 30].

Катлаулы терминнарда сүзтезмә тулысы белән гадәти әдәби сүзләрдән тора, яисә төп сүз, яисә аергыч сүз гадәти сөйләм сүзе булырга мөмкин: *тешле тәгәрмәч* ‘зубчатое колесо’.

2. Терминнар ясалуда икенче ысул итеп, халыкара лингвистикада ретерминологизацияне, ягъни әзер терминның бер фән өлкәсеннән икенчесенә күчүен

күрсәтәләр. Бер өлкәдән икенчесенә күчкәч, әзер терминның йә тулысынча, йә өлешчә төшенчәсе алмашына, шуңа күрә ул башка терминга әверелә, ягъни бу очракта яңа термин ясала. Мисаллар:

*Агым* – физикада матдәләрнең күчеше, агып торуы, *агым* – әдәбият белемендә бер юнәлеш: *әдәби агымнар* – литературное течение.

Татар телен чит тел буларак (мәсәлән, рус мәктәпләрендә) укыту кулланмаларын әзерләүчеләр телебезгә *адаптация* терминын керттеләр. *Адаптация* – иҗтимагый-сәяси өлкәдә ниндидер шартларга яраклашуны белдерә; физикада ул ‘уңайлашу’, ‘җиңеллләнү’ төшенчәсенә ия; лингвистикада – педагогикада телдәге текстны башка телдәгеләр өйрәнгәндә җиңеләйтү мәгънәсен бирә.

*База* – физикада ярымүткәргечле триодның бер электроды, иҗтимагый-сәяси өлкәдә ниндидер бер күренешнең нигезен белдерә; шуның белән бергә ул башка өлкәләрдә дә актив кулланыла, мәсәлән, икътисадта: *чимал базасы* ‘сырьевая база’, авиациядә: *авиация базасы* ‘авиационная база’, ял оештыруда: *туристлар базасы* ‘туристическая база’.

*Норма* – лингвистик норма, әдәби норма; юриспруденциядә *гомуми танылган норма* һ.б.

*Тавыш* – физикада ‘звук’, иҗтимагый-сәяси өлкәдә ‘голос’ *тавыш бирү*, лингвистикада *тавыш* ‘шум’.

*Җирле* – ‘местный’, *җирле* ‘аборигенный’.

*Аергыч* – физикада ‘разъем’, *лингвистикада* ‘определение’.

*Басым* – физикада ‘давление’, лингвистикада ‘ударение’.

Татар тел белемендә ретерминологизацияне, сүз ясалышының лексик-грамматик ысулына якынайтып, конверсиягә якын тора, дип әйтүчеләр дә бар. Ретерминологизациядә дә, конверсиядә дә яңа сүз – яңа термин ясаладилар. Ретерминологизация очрагында, чыннан да, яңа төшенчәле яңа термин ясала, ә конверсия булганда, сүзнең грамматик роле яисә мәгънәсе генә үзгәрә.

3. Фонетик ысул белән сүз ясау ул сүздәге берәр авазны алмаштыру юлы белән бара. Мисал: *калфак* – хатын-кыз баш киеме, *калпак* ‘әйбер өстенә япкыч’ сүзеннән *п-ф* үзгәреше белән ясалган; *таба* ‘ашамлык кыздыру коралы’ – *тәбә* – табада ‘кыздырылган йомырка’, *әзер* – ‘готовый, готов’ – *хәзер* ‘сейчас’, *ачы* ‘горький’ – әче ‘кислый’, *охшау* ‘быть похожим’ – *ошау* ‘понравиться’.

Сүздәге авазны төшереп калдыру юлы белән дә сирәк кенә булса да сүз ясалырга мөмкин: *тәңре* ‘бог’ – *тәре* ‘крест, икона’.

Метатеза, ягъни авазларның урыннарын алмаштырып кую да сүзьясалышында урын ала: *кыс* ‘сжимать’, *сык* ‘выжимать’, *тирбәтү* ‘качать’ – *тибрәтү* ‘колебать’ һ.б.

Терминолог Ф.С. Фасеев әйткәнчә, фонетик ысул сүз ясауда бик сирәк кулланыла, ә термин ясауда ул гомумән очрамый. Ләкин ул, термин ясауда да фонетик ысулны кулланырга кирәк иде, дигән нәтиҗәгә килә. Мисал итеп: *акыл* ‘ум’ – *гакыл* ‘разум’ сүзләрен китерә.

4. Сүз һәм термин ясалышында иң актив ысулларның берсе – морфологик ысул, бигрәк тә термин-сүзләр ясалышында. Морфологик ысулга, беренче чиратта, кушымчалау-суффикслау юлы карый: *диңгез* ‘море’ – *диңгезче* ‘моряк’, *нигез* ‘основа’ – *нигезләмә* ‘обоснование’, *бәя* ‘цена’ – *бәяләмә* ‘отзыв’, *белдер* ‘скажи, сообщи’ – *белдермә* ‘сообщение, коммюнике’, *суыту* ‘остудить’ – *суыткыч* ‘холодильник’ һ.б.

Кушымчалау ысулы белән термин ясалышын без Ф.С. Фасеев, шул юл белән сүз ясалышын Ф.Ә. Ганиев хезмәтләреннән укый алабыз [Фасеев, 1969, б. 132–140; Ганиев, 1974].

5. Терминнар ясауда синтаксик ысул аерым урын алып тора. Галимнәр фикеренчә, терминнарның өчтән ике өлеше сүзтезмә-терминнардан тора, аларның барысы да синтаксик ысул белән ясалганнар. Мәсәлән, *тимер юл* ‘железная дорога’, *сукыр тычкан* ‘крот’, *кабарынкы линза* ‘выпуклая линза’, *тереләтә авырлык* ‘живой вес’, *тупланган хезмәт* ‘накопленный труд’, *түләнмәгән вексель* ‘неоплаченный вексель’ һ.б.

Синтаксик ысулның үзенчәлекле төре буларак, а) морфологик-синтаксик ысулны (кушма сүзләр һәм терминнар ясалышында: *алмагач* ‘яблоня’), б) синтаксик-морфологик ысулны да күрсәтәләр (соңгысы парлы сүзләр һәм терминнар ясалышында күзәтелә: *ата-ана* ‘родители’, *хатын-кыз* ‘женщина’).

6. Сүзләр һәм терминнар составының баеп, артып торуына аларны борынгыдан ук гарәп-фарсы телләреннән алу сәбәп булып тора. Гарәп-фарсы алынмалары (сүзләр һәм терминнар) барлык телләрдә дә сүз байлыгының шактый өлешен тәшкил итәләр: *җәмгыять* ‘общество’, *сәясәт* ‘политика’, *мәдәният* ‘культура’, ‘цивилизация’ һ.б.

7. Алынмаларның рус теленнән һәм рус теле аша көнбатыш халыклары телләреннән кергәннәре соңгы елларда аеруча еш күзәтелә: *газ, капитал, талант, совет* һ.б.

8. Алынмаларның аерым төрен калькалар тәшкил итә. Калька ул икенче бер телдән туп-туры (сүзгә-сүз, өлешкә-өлеш) тәрҗемә итеп ясалган сүз: *өскорма* ‘надстройка’, *елъязма* ‘летопись’, *субүләр* ‘водораздел’, *бозваткыч* ‘ледокол’, *үзьяшәеш* ‘самобытность’ һ.б.

Ф.С. Фасеев эзләнүләрендә без тагын ярымкалька юлын да күрәбез. Ярым-калькаларга ул шундый мисаллар китерә: истина – *чынбарлык*, заместитель – *урынбасар*.

Калькалаштыру кушма терминнарда ешрак очрый: *радиоалгыч* ‘радиопремник’, *нефтүткәргеч* ‘нефтепровод’ һ.б.ш.

9. Кушма, катлаулы (сүзтезмә) терминнарны кыскарту (аббревиатура) юлы белән сүз яки термин ясау. Бу юл белән ясалган сүз сүзләрнең беренче авазларыннан гына торырга, яисә сүзләрнең кыскартылган өлешләреннән генә торырга мөмкин: *БМО* ‘Берләшкән милләтләр оешмасы’ – *ООН* ‘Организация объединенных наций’, *АКШ* ‘Америка кушма штатлары’ –

*США* ‘Соединенные штаты Америки’, *КФУ* ‘Казан федераль университеты’, *партком* ‘партия комитеты’, *агитбригада* ‘агитацион бригада’, *газпром* ‘газ промышленносте’ һ.б.

Төзелешләренә (структураларына) карап, сүзләр-терминнар берничә төркемгә аерылалар.

Гадәттә иң элек *тамыр* һәм *ясалма* (непроизводные и производные) терминнарны аералар: *тимер* ‘железо’ – *тимерче* ‘кузнец’, *акча* ‘деньги’ – *акчалата* ‘деньгами’, *фикер* ‘мысль’ – *фикердәш* ‘единомышленник’ һ.б.

Ф.Ә. Ганиев составлары ягыннан сүзләрне *синтетик, аналитик* һәм *аббревиатур* дигән төрләргә бүлә. Ф.С. Фасеевның тамыр һәм ясалма төрләргә бүленеше [Фасеев, 1961, с. 30–34] Ф.Ә. Ганиевтә менә шул төрләр эчендә карала [Ганиев, 1974, с. 41–48].

**Синтетик** сүз-терминнарга яки сүзләргә, барыннан да элек, тамыр сүзләр яки тамыр терминнар керә: *көз* ‘осень’, *кыш* ‘зима’, *җир* ‘земля’, *кил* ‘иди’, *кайт* ‘возвращайся’, *тиз* ‘скоро’ һ.б.

Синтетик (тамыр) сүзләргә тагын кайчандыр ясалма булган, ләкин соңрак тамыр һәм кушымчалары аерылмаслык дәрәҗәдә ябышкан сүзләр дә керә. Мәсәлән, *елан* ‘змея’, *болан* ‘олень’, *йомран* ‘суслик’, *әрлән* ‘хомяк’ кебек сүзләр кайчандыр, бик борынгы чорда ясалма булганнар, ләкин хәзер болардагы *-ан/-ән* кушымчасы һәм *йыл(ел), бол, йомр, әрл* тамырлары аерылып тормыйлар. Хәзерге көндә болар синтетик тамыр сүзләргә керәләр. Ф.Ә. Ганиев *бүген* ‘сегодня’ кебек сүзләрне дә синтетик-тамыр сүзләр рәтендә карый, чөнки *бүген* сүзенең *бу* һәм *көн* сүзләреннән ясалганлыгы беленеп торса да, анда бу сүзләрнең дә фонетик составы үзгәргән, ди ул, *бу – көн > бүген* [Ганиев, 1974, с. 41].

Башка телләрдән алынган ясалма *агитатор, каһарман* кебек сүзләр дә татар телендә синтетик сүзләр рәтендә каралырга тиеш була.

Ясалма сүзләр-терминнар да менә шул синтетик сүзләргә карагыла. Алар түбәндәге кушымчалар ярдәмендә ясалалар:

*-чы/-че*: *комбайнчы* ‘комбайнер’, *терлекче* ‘животновод’;

*-чылык/-челек*: *кошчылык* ‘птицеводство’, *терлекчелек* ‘животноводство’;

*-лык/-лек*: *кешелек* ‘человечество’, *бердәмлек* ‘единство’;

*-лашу/-ләшү*: *берләшү* ‘объединение’, *күмәкләшү* ‘коллективизация’;

*-лаштыру/-ләштерү*: *дәүләтләштерү* ‘национализация’, *электрлаштыру* ‘электрификация’;

*-ландыру/-ләндерү*: *яшелләндерү* ‘озеленение’;

*-чанлык/-чәнлек*: *уалучанлык* ‘ломкость’, *ярсучанлык* ‘раздражимость’;

*-ыш/-еш*: *үсеш* ‘развитие’, *чагылыш* ‘отражение’;

*-ма/-мә*: матем. *аңлатма* ‘выражение’, *өстәмә* ‘дополнение’;

*-ымта/-емтә*: геом. *кисемтә* ‘отрезок’, матем. *биремтә* ‘данное’, *сөземтә* ‘резюме’, *сызымта* ‘очертание’;

*-ымча/-емчә*: *кушымча* ‘суффикс, аффикс’;

*-ынча/-енчә*: *төшенчә* ‘понятие’;

*-ынты/-енте*: *йогынты* ‘влияние’, *үсенте, үренте* ‘рассада’, *чыгынты* ‘выступ’;

*-гы/-ге, -кы/-к*: *яралгы* ‘зародыш’, *тойгы* ‘чувство’, *сөйләк* ‘сказ’, *очрак* ‘случай’ һ.б.ш.

**Аналитик** сүзләр, аналитик терминнар башкача **кушма** дип атала. Алар икедән ким булмаган тулы мәгънәле тамыр сүзләрдән, яки бер тулы мәгънәле, бер ким мәгънәле сүздән ясалалар. Бу проблеманы җентекләп өйрәнгән Ф.Ә. Ганиев сүзләренә караганда, татар телендәге иң күп аналитик сүзләр-терминнар ике кушымчасыз сүздән ясалалар: *укып чык* ‘прочитай, прочитывай’, *аккош* ‘лебедь’, *ташбака* ‘черепаха’, *килә төш* ‘подойди поближе’. Аналитик сүзләр-терминнар өчәр, дүртәр сүздән дә ясалырга мөмкин: *үги ана яфрагы* ‘мать-и-мачеха’.

Татар телендә аналитик (кушма) сүзләргә 1) **кушма**; 2) **парлы**, 3) **катлаулы** сүзләр һәм терминнар карый.

**Кушма** сүзләр-терминнар бергә кушылган сүзләрдән торалар. Бу сүзләр арасында атрибутив (аергыч-аерылмыш) мөнәсәбәте һәм предикатив (ия-хәбәр) мөнәсәбәте булырга мөмкин, менә шул мөнәсәбәтләрне югалткач кына үзара кушылган сүзләр кушма сүз ясыйлар, диләр галимнәр.

Ф.Ә. Ганиевнең тикшерү нәтиҗәләре буенча, мондый мөнәсәбәтләрдә кушма сүзләрнең беренче компоненты булып, исемнәр, сыйфатлар, саннар, алмашлыклар һәм кисәкчәләр килә ала, ә икенче компоненты булып бары исемнәр генә килә: *сабантуй* ‘сабантуй’, *җиржиләк* ‘клубника’, *кызылканат* ‘красноперка’ (балык), *өчаяк* ‘таган’, *үзаң* ‘самосознание’, *үзидарә* ‘самоуправление’, *әллә кайда* ‘где-то’ һ.б.

Предикатив мөнәсәбәттәге сүзләрдән ясалган кушма сүзләрдә, беренче компонент булып – исемнәр, икенчесе булып фигыльләр килә: *Хангилде* ‘хан пришел, хан родился’, *Ходайбирде* ‘Бог дал’, *Хакбирде* ‘Бог дал’ и т.д. Кушма сүзләрнең бу төркеме топонимнарда һәм антропонимнарда сакланган.

Кушма (аналитик) сүзләрнең икенче төркеме **парлы сүзләр** яисә **парлы терминнар** дип атала. Парлы сүз яки терминнарның компонентлары бер-берсенә буйсынмыйча, тигез хокуклы булып киләләр: *бала-чага* ‘дети’, *ата-ана* ‘родители’, *моң-зар* ‘обиды’, *савыт-саба* ‘посуда’ һ.б. Тикшерүчеләр фикеренчә, парлы сүзләр бик борынгы заманнарда барлыкка килгәннәр. Аларның компонентлары бер үк диалект сүзләре булмый, төрле диалекттан яки төрле телдән алынган сүзләр була. Мәсәлән, *бала-чага* ‘дети’ дигән парлы сүзнең беренчесе – урта диалект сүзе, икенчесе – көнбатыш диалекты сүзе; *савыт-саба* дигән парлы сүздә беренче компонент – татар әдәби теле сүзе, икенче компонент – үзбәк яки казакъ теленнән кергән алынма.

Кушма (аналитик) сүзләрнең өченче төрен катлаулы сүзләр тәшкил итә. Болар үзара атрибутив, предикатив, хәл яки тәмамлык мөнәсәбәтенә

кергән сүзләрдән торалар. Бу төр кушма сүзләр аналитик сүзләрнең төп өлешен тәшкил итәләр. Мондый кушма – катлаулы сүзләрне татар телендә бишкә бүлеп тикшерәләр:

1) компонентлары изафәт мөнәсәбәтендә торган катлаулы сүзләр: *йорт куяны* ‘кролик’, *каен җиләге* ‘земляника’, *үги ана яфрагы* ‘мать-и-мачеха’, *мүк җиләге* ‘клюква’ һ.б.

2) компонентлары үзара тәмамлык мөнәсәбәтендә торган катлаулы сүзләр яки терминнар. Боларның беренче компоненты гадәттә исем, икенче компоненты фигыль була: *урынбасар* ‘заместитель’, *субүләр* ‘водораздел’;

3) катлаулы сыйфатлар. Боларның төп (икенче) өлеше аналитик фигыльдән, ә беренче өлеше шул фигыльнең иясе булган сүздән тора, ләкин фразеологиягә әйләнгәч, анда бу мөнәсәбәт югала дип әйтерлек, шуның өстенә, катлаулы сүз *-гәч/-гач/-кыч/-кеч* кушымчаларына тәмамлана: *коточкыч* ‘ужасный’ (*котлары очты* ‘ужаснулся’), *искиткеч* ‘удивительный’ (*исләрем китте* ‘удивился’), *шаккаткыч* ‘поразительный’ (*шакларга каттым* ‘поразился’);

4) компонентлары предикатив мөнәсәбәттән торган катлаулы сүзләр дә бар: *кояш тотылу* ‘затмение солнца’, *җир тетрәү* ‘землетрясение’;

5) исем һәм фигыльнең комплетив (хәл яки тәмамлык) мөнәсәбәтенә керүе нәтиҗәсендә ясалган катлаулы фигыльләр дә еш очрый: *юк итү* ‘уничтожить’, *хис ит* ‘чувствовать’, *тар-мар ит* ‘разбить, разбивать’, *сабыр итү* ‘терпеливо ждать’;

6) берсе тулы хокуклы, икенчесе өстәмә төшенчә генә бирә торган фигыльләрдән торган катлаулы фигыльләр: *укып чыгу* ‘прочитать, прочитывать’, *чыгып китү* ‘уйти, уходить’, *өлгерә төшү* ‘созревать еще’.

Татар телендә кыскартылган кушма сүзләр күбрәк очракта алынмалардан торалар: *вуз, наркомпрос, КПСС* һ.б. Татар кушма сүзләреннән кыскартылганнары сирәк очрый: *АКШ* – Америка кушма штатлары, *ТДГПУ* – Татар дәүләт гуманитар педагогия университеты, *КФУ* – Казан федераль университеты.

Кыскартылган кушма сүзләрне татар телендә ике төргә бүлеп карыйлар: инициаллары сакланган кушма сүзләр һәм элементлары сакланган кыскартылма сүзләр.

1. Инициал кыскартылма сүзләрдә кушма сүздәге аерым сүзләрнең инициал авазлары гына саклана: *ГДР (ГеДэРэ)* – Германия Демократик Республикасы; *КДПИ (КэДэПэИ)* – Казан дәүләт педагогика институты; *БҮБК (БэҮБэК)* – Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты; *БАССР (БэАСэСэР)* – Башкортостан Автономияле Совет Социалистик республикасы һ.б.

2. Элементлары сакланган кыскартылма сүзләр ике төрле була:

1) беренче иҗекләре сакланган кыскартылма сүзләр: *райком* ‘район комитеты’, *раймаг* ‘район магазины’. Мондый кыскартылма сүзләр дә татар теленә рус теленнән алынган була: *местком*

‘местный комитет’, *завхоз* ‘заведующий хозяйством’;

2) кыскартылган кушма сүздәге беренче сүзнең беренче иҗеге генә калдырыла, икенчесе улы килеш саклана: *драмтүгәрәк* ‘драмкружок’, *профхәрәкәт* ‘профдвижение’, *партоешма* ‘парторганизация’. Бу төр кыскартылма сүзләр телдә актив кулланылалар.

Шулай итеп татар телендә структуралары буенча түбәндәге термин-сүзләр күзәтелә:

| Синтетик гади сүзләр | Аналитик кушма сүзләр | Аббревиатуралар, кыскартылган кушма сүзләр |
|---|---|---|
| 1. Тамыр сүзләр<br>2. Кушымчалы сүзләр | 1. Кушма сүзләр<br>2. Парлы сүзләр<br>3. Катлаулы сүзләр (сүз-тезмәләр) | 1. Инициаллары сакланган кыскартылган кушма сүзләр.<br>2. Аерым элементлары сакланган кыскартылган кушма сүзләр. |

**Әдәбият**

*Васильева Н.В.* Термин // Лингвистический энциклопедический словарь. М., 1990. С. 508–509.

*Ганиев Ф.А.* Фонетическое словообразование в татарском языке. Казань: ТКИ, 1973. 40 с.

*Ганиев Ф.А.* Суффиксальное словообразование в современном татарском литературном языке. Казань: ТКИ, 1974. 231 с.

*Даниленко В.П.* Лексико-семантические и грамматические особенности слов-терминов // Исследования по русской терминологии. М.: Наука, 1971. С. 7–67.

*Зорин З.М., Черемисина М.И.* О специфике языка слов и языка символов в научном описании (на примере физики) // Исследования по русской терминологии. М.: Наука, 1971. С. 68–77.

*Исхакова Ф.Х.* Структура терминологических систем. Тюркские языки. М.: Наука, 1987. 127 с.

*Калинин А.В.* Лексика русского языка. Пособие для факультетов журналистики университетов. М.: МГУ, 1966. 231 с.

*Суперанская А.В., Подольская Н.В., Васильева Н.В.* Общая терминология. Вопросы теории. Отв.ред. Канделаки Т.Л. М.: Наука, 1989. 247 с.

*Фасеев Ф.С.* Способы образования терминов в татарском литературном языке: автореф. дис. ... канд.филол. наук. М., 1961. 40 с.

*Фасеев Ф.С.* Татар телендә терминология нигезләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 200 б.

***Зәкиев Мирфатыйх Зәки улы,*** *филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

*Ш.Н. Асылгәрәев*

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АЛФАВИТЫ ҺӘМ ОРФОГРАФИЯСЕ ТУРЫНДА

Об ущербности орфографии современного татарского литературного языка всегда говорилось и говорится в средствах массовой информации.

Основной недостаток существующей орфографии – отсутствие в алфавите самостоятельных букв для обозначения фонем «к» и «г», которые являются наиболее употребительными в фонетической системе татарского литературного языка. Составители орфографии считали, что на письме эти фонемы можно передать «морфологическим путем». Но на практике эта теория себя не оправдала. Вследствие того, что в орфографии каждая из букв «к», «г» выполняет двойную нагрузку – обозначает и фонемы «к» и «г», и фонемы «қ» и «ғ», в разговорах людей все больше и больше наблюдается разнобой в произношении слов с этими звуками.

Татарскую орфографию, созданную на базе русского алфавита, необходимо усовершенствовать, исправить и поставить на научную основу. Усовершенствование орфографии, изъятие из нее ничем не оправданных, громоздких правил, намного облегчит обучение грамоте наших школьников.

В статье обосновывается необходимость обновления татарского алфавита и предлагается проект такого обновления.

**Ключевые слова:** орфография, фонема, русский алфавит, словообразование, правописание.

Орфография мәсьәләсе инде гасыр дәвамында татар җәмәгатьчелек фикерен үзенә җәлеп итеп тота. Бу мәсьәләнең шулай озак көн тәртибеннән төшмәвенең сәбәбе, кыскача гына әйткәндә, орфографияне төзегәндә телебезнең табигатен, аның эчке закончалыкларын исәпкә алып бетермәүдә, ягъни алфавит кайсы халыктан алынса, шул халык теленең орфографиясенә буйсындырып төзелгән булуында. Мәсәлән, моннан мең ел элек без гарәп әлифбасын кабул иткәнбез һәм орфографиябезне дә гарәп теле орфографиясенә тулысынча буйсындырганбыз. Шуның нәтиҗәсендә гарәпнең үзебезнең телдә булмаган алты фонемасына алфавитта хәреф алып, үзебезнең телебездә булган унике фонемага хәреф алмаганбыз. Татар теленең тартык авазларны сузыкларга ияртү үзлегенең нәкъ киресе булган гарәп теленең сузыкларны тартыкларга ияртү үзлеге нигезендә орфография нормалары тудырып, *тотын, төтен, белдер, бөлдер, тырыш, пәрәмәч* кебек *а, о, ө, ы, э* сузыклары кергән сүзләрне бөтенләй сузыксыз: *ттн, ттн, блдр, блдр, трш, прмч* рәвешендә язганбыз.

Узган гасырның унынчы елларында гарәп орфографиясенең татар орфографиясендә дини догма булып яшәвенә каршы көрәш башлана. Бу көрәш Октябрь

инкыйлабыннан соң тулы җиңүгә китерә, орфографиябездә үз телебезнең үзенчәлекләре исәпкә алына. Ләкин бу озакка бармый. Башта латин графикасына, ун елдан соң рус графикасы нигезендәге алфавитка күчелә.

1937–39 еллар шартларында барган әлеге күчеш шулай ук догма рәвешендә булган. 1939 елда кабул ителгән алфавит һәм шуның нигезендә төзелгән орфографиябез татар теленең эчке закончалыкларын тулысынча чагылдырып бетерми, чөнки аңа рус теленең үзенчәлекләре көчләп тагылган. Бу хәл, табигый рәвештә, татар кешесенең алфавит һәм орфографиягә карата ризасызлыгын тудыра. Әлеге ризасызлыкка китерә торган кимчелекләр, җитешсезлекләр ТАССР Верховный Советы Президиумы тарафыннан расланган һәм 1941 елда басылып чыккан «Татар әдәби теленең алфавиты һәм орфографиясе» кагыйдәләре тупланмасында тулысынча чагылыш тапкан. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– алфавит һәм орфография төзүчеләр татар теленең, гарәп һәм рус телләреннән аермалы буларак, эчке флексиядән азат, сингармоник агглютинатив бер тел булуын, аның фонемалар составында рус телендә булмаган, бары тик үзенә генә хас 11 специфик аваз [қ], [ғ], [h], [ө], [җ], [ң], [ә], [о], [ы], [э] [ў] (ирен тартык аваз) булуын исәпкә алмаганнар. [Ў] авазына хәреф 1989 елның 27 нче июнендә ТАССР Верховный Советы Президиумы Указы белән расланган Татар алфавитында «w» сурәтендә бирелгән иде, ләкин бу алфавит кулланышка кермәде. Нәтиҗәдә, бүгенге алфавитта [қ], [ғ], [w] (вау) авазларын язуда күрсәтү өчен алфавитта хәрефләр бөтенләй алынмаган. Бу – алфавитның зур кимчелеге булып тора. Алфавитта спецификавазхәрефләрененңбулмавы язу белән уку (әйтелеш) арасында зур аерма тудыра. Мәсәлән, *хәқиқәт, қәнәғәт* кебек сүзләрне хәзерге орфография нигезендә дөрес язу өчен *(хакыйкать, канәгать)* укучыга, бигрәк тә мәктәп баласына (чөнки укырга, язарга мәктәптә өйрәтәләр) түбәндәге кагыйдәләрне өйрәнеп, аларны озак вакытлар дәвамында күңелендә, хәтерендә тотарга: «к» хәрефе [қ] авазы итеп укылсын өчен, аның артыннан [ә] авазы ишетелсә дә, «а» хәрефе язылырга тиешлекне, бу «а» хәрефе [ә] авазы итеп укылсын һәм аның янындагы «т» хәрефе калын булып әйтелмәсен өчен, нечкәлек билгесе куелырга тиешлекне белергә, моның өстенә «т» хәрефеннән соң куелган йомшаклык (нечкәлек) билгесенең, рус телендәгенең киресе буларак, палаталь авазны белдермәвен (икенче төрле әйткәндә, *хакыйкать, канәгать* дигәндәге соңгы аваз [ть]нең *ехать* дигәндәге [ть] авазына охшатып әйтелмәскә тиешлеген) истә тотарга кирәк була, ләкин мондый ясалма, нигезсез кагыйдәләрне истә тоту бик кыен. Мисаллардан күренгәнчә, алфавитта «қ» һәм «ғ» хәрефләренең булмавы аркасында «к» һәм «г» хәрефләре язуда икешәр авазга билге булып йөриләр. «К» хәрефе [к] *(китап, мәктәп)* һәм [қ] *(қызык, қарга)* авазларын, «г» хәрефе [г] *(гөл, гәүдә)* һәм [ғ] *(Ғәзиз, Ғәли)* авазларын белдерә;

– ике авазга билге булып йөрүче хәрефләр «к», «г» белән генә

бетми. Алфавитта ирен-ирен [w] авазы өчен хәреф булмау сәбәпле, укучыларыбыз *тауык, ауыз, ауаз, Уахит, Уәли* кебек сүзләрне *тавык, авыз, аваз, Вахит, Вәли* дип язалар. Укыганда аларны ирен-ирен [w] авазы белән түгел, ягъни язылганча ирен-теш «в» тартыгы белән укыйлар. Ә бит «в» хәрефенең үз функциясе бар. Ул *вагон, винтовка, вожатый* кебек рус сүзләрендәге [в] авазын белдерә. Шуңа күрә аның татар сүзләрендәге [w] авазы белән бернинди дә уртаклыгы юк, аларның хәтта ясалу урыннары да башка;

– хәзерге графикабызда «w» тартыгының [у] сузыгы белән бирелү очраклары да бар: *бау, тау, шау, сау.* Чынлыкта бу сүзләр «w» хәрефе белән язылырга тиеш. Чөнки татар теле законы нигезендә язуда ике сузык аваз хәрефе янәшә килә алмый (килергә тиеш түгел). Әлеге сүзләрдә, «а» хәрефеннән соң килгән хәрефне ачыклау өчен, ул сүзләрне төрләндереп карарга кирәк: *тау – тауы, тау – таwы, бау – бауы, бау – баwы.* Мәгълүм закон буенча «а» хәрефеннән соң «у» хәрефе һич языла алмый, чөнки ул чагында ике генә түгел, өч сузык аваз хәрефләре янәшә булып чыга: *тауы, бауы.* Бу хәлдән чыгу өчен орфография авторлары ясалма кагыйдә уйлап чыгарганнар. Янәсе, татар телендә ике сузык янәшә килә алмау сәбәпле, *тавык, авыз, аваз, бавы, тавы* кебек сүзләрдә ике сузык арасында «в» хәрефе языла. Шулай итеп «в» хәрефе ике авазны: рус теле сүзләрендә *(вагон, вышка)* [в] авазын белдерсә, татар сүзләрендә *(авыз, аваз, тавык, бавы, тавы)* «w» хәрефе функциясен үти;

– «ы» хәрефе белән дә шул ук хәл. Бу хәреф рус телендә [ы] фонемасы *(посылка, вышка)* билгесе булып йөри. Татар телендә алынма сүзләрдә аны без дә шул мәгънәдә кулланабыз. Әмма татарның үз сүзләрендә *(ындыр, ылыс)* ул рус телендәге [ы] авазы белән бернинди уртаклыгы булмаган [ы] авазын белдерә. Бу авазларның һәр икесе ике телнең мөстәкыйль авазлары булуына ышану өчен, аларны рус кешесеннән укытып карау да җитә. Рус кешесе *ындыр, ылыс* сүзләрендәге «ы» хәрефен [ый] авазлар тезмәсе белән укыячак. Шуңа күрә рус теленең [ы] фонемасы да, татар теленең [ы] фонемасы да язуда бер-берсенә охшамаган мөстәкыйль хәрефләр белән күрсәтелергә тиеш;

– алфавит төзүчеләр татар теленең [йе], [йы], [йү], [йу], [йә], [йа] аваз тезмәләрен күрсәтү өчен алфавитка рус теленә генә хас булган «е», «ю», «я» хәрефләрен керткәннәр. Татар сүзләрен рус хәрефләре «е», «ю», «я» белән язу телебезнең морфологик үзлеген җимерүгә китерә. Мәсәлән, *той + а (тоя), төй + ә (төя).* Аваз тезмәләрен «е», «ю», «я» белән язган вакытта (мәсәлән, *тоя (той + а), төя (төй + ә)* тамыр белән морфологик элемент (кушымча) берләшә, тамыр белән кушымча арасында чик югала. Бу күренеш, беренчедән, укучы баланың сүз төзелешендәге ачык төшенчәсен караңгылый, сүзгә морфологик анализ ясауны кыенлаштыра, телнең ялганмалык (агглютинатив) табигатенә ясалма рәвештә флективлык кертеп, бала аңын чуалту-

га китерә. Икенчедән, нечкә әйтелешле [йү], [йә] аваз тезмәләрен калын «ю», «я» белән күрсәтү сузыклар гармониясенә корылган язу системасын боза, җимерә. Шулай булгач, кулланылуы белән телебезнең үзенчәлеген вата, җимерә торган «е», «ю», «я» хәрефләрен татар сүзләрендә [йе], [йы], [йү], [йу], [йә], [йа] тезмәләренең үзләрен язу белән бирү яхшырак булыр иде. «Е», «ю», «я» шартлы билгеләрен татар сүзләрендә язуның һич кирәге юк. Аларның язылышын рус сүзләрендә генә калдырып, татар сүзләрендә *еш* урынына *йыш, ел* урынына *йыл, юк* урынына *йук, ялкын* урынына *йалкын* дип, һәр авазның (фонеманың) үз билгесен язарга кирәк. Аваз тезмәләрен ишетелгәнчә язсак, *яшь (йәш), юнь (йүн), юньле (йүнле)* кебек сүзләрдә нечкәлек билгесе язуның да кирәге калмый;

– «э» хәрефе турында шуларны әйтергә була: бер үк [э] фонемасы хәзерге орфографиядә ике төрле хәреф белән күрсәтелә: сүз башында килсә – «э» хәрефе *(эш, эт, эри, энә),* сүз уртасында һәм сүз ахырында «е» хәрефе белән *(эше, тешсез, кеше)* бирелә. Бу хәл бернинди мантыйкка да сыймый, чөнки фонетика законы буенча бер авазга бер хәреф, бер хәрефкә бер аваз йөрергә тиеш. «Е» хәрефе мөстәкыйль аваз билгесе булудан бигрәк, ул – мөстәкыйль авазлар (й+э һәм й+ы) тезмәсе, ягъни дифтонг билгесе. Белгәнебезчә, хәреф бер үк вакытта мөстәкыйль аваз билгесе дә, дифтонг билгесе дә була алмый. Шуңа күрә татар алфавитында [э] авазын күрсәтү өчен бер генә хәреф – «э» хәрефе генә калырга тиеш.

Кыскасы, татар теленең гамәлдәге, ягъни 1941 елда расланган (әле бүген дә гамәлдән чыгарылмаган) орфографиясе тел үзенчәлекләрен тулысынча исәпкә алып бетерми. Анда күп кенә буталчыклар, татар теленең фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре белән уртаклыгы булмаган, телнең үсешенә комачаулык итә торган, язу аша әдәби әйтелеш нормаларын боза торган шартлы һәм ясалма кагыйдәләр бар. Бу җитешсезлекләр турында газета һәм журнал битләрендә, төрле җыелыш һәм конференцияләрдә үз вакытында күп сөйләнгән, зур-зур бәхәсләр булган, конкрет тәкъдимнәр дә кертелгән. Алар (тәкъдимнәр) «Совет әдәбияты» журналының өченче санында (1954 ел, 104–107 битләр) «Әдәби тел һәм орфография мәсьәләләре: урыннан фикерләр һәм тәкъдимнәр» исемле баш астында туплап бирелгәннәр. Шуларның кайберләре белән бүгенге укучыны да (кыскартып) таныштырып китүне зарур санадык.

Татарстанның Красный Бор районы, Исәнбәй урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гаскәр Бәширов: «Яшәештәге орфографиябез бик катлаулы һәм буталчык. Шунлыктан җидееллык һәм урта мәктәпне тәмамлап чыккан укучыларыбызның зур күпчелеге, без ничек кенә тырышсак та, орфографияне тиешенчә үзләштерә алмыйча китәләр. «Қ», «ғ» авазларының укылышын күрсәтер өчен, кайбер сүзләрдә хәрефләр арттырып язарга, әллә ни кадәр өстәмә чаралар кулланырга туры килә. Мәсәлән, *шагыйрь* (шагир) сүзендә ике хәреф

артык китә. Укылыш та авырлаша. Алфавитта «к», «г», «w» авазлары өчен аерым хәрефләр булмау орфографияне генә түгел, орфоэпияне үзләштерүгә дә бик нык комачаулый. Димәк, ул авазлар өчен аерым хәрефләр алып, орфографияне төзәтергә кирәк. Фамилияләрне язудагы төрлелек тә бетерелсен иде. Татар фамилияләре, татарча ничек әйтелсәләр, шулай язылырга тиешләр, мәсәлән: *Гәлиев, Җәләлиев, Һадиев»* [Бәширов, 1954, б. 104].

Казан фельдшер-акушерлар мәктәбендә татар теле укытучысы Ф. Фасеев болай яза:

«Орфографиядәге катлаулылык һәм буталчыклык «қ», «ғ» авазлары өчен алфавитта аерым хәрефләр булмау һәм рус теленең специфик (палаталь) тартыкларын язуда чагылдыруга җайлашкан «я», «ю», «е» хәрефләрен татар сүзләренә дә җәелдерү нәтиҗәсендә барлыкка килде. Бу җитешсезлекне бетерү өчен, мин шундый тәкъдим кертер идем: татар теленең специфик төп авазларыннан берсе булган «қ», «ғ» тартыкларына алфавитта, һичшиксез, аерым хәреф алу кирәк.

«W» авазын калын сүзләрдә «у» хәрефе белән, нечкә сүзләрдә «ү» хәрефе белән билгеләү, аерым хәреф алуга караганда, уңайрак булачак. Мәсәлән: *һауа, ауыл, тауыш, әүен, үтәүе.*

«Я», «ю», «е», «ё» хәрефләрен бары тик рус теленнән кергән сүзләрне язу өчен генә кулланырга кирәк. Татар сүзләрендә исә алар урынына һәр җирдә кыска «й» хәрефе белән башлап язуны кагыйдәләштерергә. Шулай итмәгәндә, сүзлекләрдә бер үк авазга башланган сүзләр төрле урыннарга сибелеп урнаштырыла һәм кирәкле сүзләрне эзләп табу кыенлаша. Татар телендә тартык авазларның калынлык-нечкәлеге рус, телендәгегә караганда, бөтенләй икенче төрле булганлыктан, калынлык-нечкәлек билгеләрен рус теленнән кергән сүзләрдә генә кулланырга, мәсәлән: *актуаль, принципиаль, объектив, съезд.* Аннан соң алфавитта хәрефләрнең тәртибен беркадәр үзгәртеп, «а – ә», «г – ғ», «ж – җ», «к – қ», «о – ө», «у – ү», «н – ң», «х – һ» кебек хәрефләрне бер рәттән кую да яхшырак булыр иде. Шулай итмәгәндә, алфавит белән эш итү, бигрәк тә сүзлекләрдән кирәкле сүзләрне табу гаять авыр була» [Фасеев, б. 104–105].

Казан дәүләт педагогия институты укытучысы, филология фәннәре кандидаты З. Вәлиуллина да үз фикерен язып җибәргән: «Татар фонетикасын, орфоэпиясен башлап өйрәнүче кайбер студентларга – Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында татар мәктәпләре өчен рус теле укытучылары хәзерләү бүлегендә укучы студентларга – язуда «к», «г» хәрефләренең икешәр фонема аңлатканлыгын, ягъни «ка (ку, ко...)», «га (гу, го...)» аваз тезмәләрендә аларның икешәр төрле укыла икәнлекләрен төшендерү бик читен. Шунлыктан студентлар составында ул фонемалар булган сүзләрне төрлечә яза бирәләр: *«кәнәгәт»* яки *«канагат», «тәбигәт»* яки *«табигат», «диккәт»* яки *«диккат»* һ.б. *«Камыт», «канау»* кебек сүзләрне укыганда ялгыш җибәрәләр: «к»

урынына «ҡ» һәм, киресенчә, «ҡ» урынына «к» әйткән очраклары була. Минем уемча, «к» һәм «г» фонемаларына аерым хәрефләр алу татар орфографиясен җиңелләштерер, төрле буталчыклардан котылдырыр иде. Шулай ук «ю», «я», «е» хәрефләренең язылышын да өр-яңадан карап чыгасы бар. Укучыларга, татар телен башлап өйрәнүче кешеләргә ни өчен «йо, йә» язылып та, «йы», «йе», «йа», «йә», «йу», «йү» тезмәләрен язарга мөмкин түгел икәнлеген, җитмәсә *«юнь», «яшь»* кебек сүзләрдә нечкәлек билгесе язуның кирәклеген төшендерү шактый кыен. Минемчә, «я», «ю», «е» хәрефләрен рус теленнән кергән сүзләрдә генә кулланып, татарның үз сүзләрендә «йа (йал), йә *(йәш),* йу (мәсәлән, *«кер йу»* ), йү *(йүкә),* йы *(йыл),* йе *(йегет)»* тезмәләрен язу уңышлырак булачак.

Татар телендәге «w» фонемасының «в» аша бирелүе дә *(тавык, авыл, әвен)* уңышлы түгел. Татар фонетикасын һәм орфографиясен үзләштерүгә ул зур гына комачау булып тора» [Вәлиуллина, б. 105–106].

СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы гыйльми хезмәткәре К. Сабиров: «Татар алфавитының шул телнең үзенчәлеген ачык күрсәтә торган «ҡ» һәм «ғ» авазларының хәрефләрен төшереп калдыру үз вакытында комиссиянең бу эшкә җитди карамавын күрсәтте. Мондый авазларның булмавы татар телендә *«канат», «карта», «канау», «ураган» «бак»* һ.б.ш. кебек кирәксез график омонимнар арттырып кына калмады, башлыча, фонетик принципка нигезләнгән орфографиядән читкә тайпылу сәбәпле, әйтелеш белән язылыш арасында зур аерма тудырды. Мәктәп балаларының, хәтта студентларның, «к» белән әйтелә торган *«инкарь», «Камал», «фидакарь»* һ.б. сүзләрне, хәзерге кагыйдәләрдән чыгып, «ҡ» белән әйтүләре шул специфик «ҡ», «ғ» авазларын белгертергә тиешле аерым хәрефләрнең булмавына кайтып кала. Шул ук хәрефләрнең булмавы, «ә» авазына бетә торган *«вакыйга», «дәгва»* һ.б.ш. кебек сүзләргә һич тә дөрес булмаган калын кушымчалар ялгап, *«вакыйгаларны, «дәгвалашуы»* дип язуга китерде. Басылып чыккан мәкаләләрдән күренгәнчә, шул ук хәрефләрнең булмавы дистәләгән сүзләргә калынлык яки нечкәлек билгесе өстәү һәм, шуның белән, язу техникасын катлауландыру кебек күренешләрне дә тудырды. «В» хәрефенең дә ике авазга билге булып йөрүен шулай ук уңышлы дип әйтеп булмый. *«Аву», «саву», «тавы», «явуы»* кебек сүзләрне беренче караштa тиз генә аңлап бетерә алмаска да мөмкин, чөнки аларның язылышлары әйтелешләреннән шактый ераклаштырылган» [Сабиров, б. 106].

Казан шәһәренең 80 нче мәктәп укытучысы И. Гомәрова һәм 13 нче мәктәп укытучысы Г. Маликова да үз фикерләре белән ураклашканнар: «Без, укытучылар, эш өстәлендә менә шундый кыенлыкларга очрыйбыз: татар теленең үзенчәлекләреннән берсе булган «ҡ», «ғ» авазлары өчен алфавитта аерым хәреф булмау укучыларны да, укытучыларны да уңайсыз хәлдә калдыра. Хәтта башка фәннәрдән биш билгеләренә генә укучылар да контроль

эш вакытларында, имтиханнарда шушы кагыйдәгә хата ясыйлар.

«Қ», «ғ» авазлары өчен алфавитта аерым хәреф булмаганлыктан, аларның әйтелешен чагылдыру өчен, кайбер сүзләрдә калынлык һәм нечкәлек билгеләре куела. Шул ук билгеләр аеру билгесе булып та йөриләр. Мәсәлән: *мәгънә, тәкъдим, вәгъдә, нәкъ, игътибар, дикъкать, Яхъя, дәрья, мәсьәлә, семья, дөнья.* Укучылар мондый» сүзләрнең дөрес язылышын механик рәвештә генә үзләштерәләр. Шушы төр сүзләрдә санап бетергесез хаталар ясыйлар. Менә бу хаталар да, башта әйткәнебезчә «қ», «ғ» авазлары өчен аерым хәрефләр булмаудан килеп чыгалар. «W» авазын «в» аша билгеләү уңышлы түгел. Мәсәлән, «сулавчы, тавы» дип язып куя укучы. Шулай ук, «давыл, авыл, рәвеш, явым, савым, тавыш» кебек сүзләрне дә я ялгыш укыйлар, я ялгыш язалар. Орфография кагыйдәләрендә «йа» урынына да, «йә» урынына да «я» язуны балаларга төшендерүе авыр («яшь, яше, яз, ял, тия, тыя» һ.б.). «Яшь», «ямь» кебек сүзләрдә «я» (йа)ны нечкә уку өчен («йәм», «йәш» дип уку өчен) «ь» билгесе куюда укучылар һәрвакыт хата ясыйлар. «Ю», «е» хәрефләренең язылышларында да шундый ук кыенлыклар килеп чыга. Югарыда күрсәтелгән кимчелекләрне искә алып, орфографияне төзәтергә, камилләштерергә кирәк» [Гомәрова..., б. 106–107].

Казан шәһәренең 35 нче мәктәбе татар теле укытучылары М. Галләмова белән Г. Мифтахова: «Татар әдәби теленең үзенчәлекле авазларыннан булган «қ», «ғ» авазлары алфавитта аерым хәрефләр белән билгеләнмәү нәтиҗәсендә, укыту процессында зур гына кыенлыкларга очрарга туры килә. Составында бу авазлар булган сүзләрне язган вакытта, укучылар бик күп ялгыш ясыйлар. Мәсәлән, *кәдәр (кадәр), сәгәт, сагәт, сагат (сәгать), игтибар (игътибар), тәкдим, такдим (тәкъдим), фәкәт (фәкать), мәгнә (мәгънә), гәскәр, гәскар (гаскәр), гибарәт (гыйбарәт), диккәт (дикъкать), шөгелләнү (шөгыльләнү)* һ.б. Сөйләү теле белән язу теле арасында зур аерма булганлыктан, «в», «у», «ү» хәрефләрен укыган һәм язган вакытта да күп кенә ялгышларны очратырга туры килә. Мәсәлән, *ауыл (авыл), уакыт (вакыт), дәүер (дәвер), әүен (әвен).* «ъ» һәм «ь» билгеләрен куллану буенча да укучылар күп ялгыш җибәрәләр. Мәсәлән, *«сәгат, ям, яш, диккәт» (сәгать, яшь, ямь, дикъкать)* формасында язалар. Чөнки бу сүзләрдәге нечкәлек билгеләре, «физкультура» сүзендәге кебек, үзенең алдындагы авазны нечкәртмиләр. Шулай булгач, мондый сүзләрдә нечкәлек билгесен куллануның һич кирәге юк. Әгәр «къ» һәм «гъ» авазларына аерым хәрефләр алсак һәм татар сүзләрендә «я», «ю» хәрефләренең язылышын чикләсәк, яки аларны татар сүзләрендә бөтенләй кулланмасак, кирәк-кирәкмәс урыннарда катылык һәм нечкәлек билгеләрен язудан да арынып идек. Татар орфографиясенең төп җитешсезлекләре менә шулар. Аларны без, һич кичекмәстән, төзәтергә тиешбез, югыйсә орфографиянең хәзерге торышы һичничек тә канәгатьләнерлек түгел» [Галләмова..., б. 107].

Җәмәгатьчелек фикере белән партия һәм хөкүмәт органнары да исәпләшергә мәҗбүр була. Мәсәлән, 1954 елның башларында СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы, алфавит һәм орфографиягә багышлап, махсус фәнни киңәшмә үткәрә. Киңәшмәдә, гамәлдәге орфографиянең төп җитешсезлеге итеп, специфик авазлар өчен хәрефләр җитмәү, кушма сүзләр, исем-фамилияләр һәм ялгызлык исемнәр язылышында ныклы бер тәртип булмау, алынма сүзләрне һәм аларга ялганган кушымчаларны анықларга кирәклек күрсәтелә. Шуннан соң СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты татар әдәби теленең аныкландырылган һәм камилләштерелгән орфография проектын төзи һәм аны, укытучылар, язучылар һәм гыйльми хезмәткәрләр белән каткат тикшергәннән соң, Татарстан дәүләт орфография комиссиясенә тапшыра. Дәүләт комиссиясе проектны, җентекләп караганнан соң, киң күләмдә фикер алышу өчен матбугатка чыгарырга тәкъдим итә.

Проект татар орфографиясендә моңарчы яшәп килгән төп җитешсезлекләрне бетерүне күздә тота. Шул максат белән язылышка кайбер үзгәрешләр кертелә. Татар әдәби теле фонетикасына аеруча хас булган [қ], [ғ] авазлары аерым хәрефләр белән билгеләнә. [Қ] фонемасы өчен «қ» хәрефе, [ғ] фонемасы өчен «ғ» хәрефе алына.

[Қ], [ғ] авазларын аерым хәрефләр белән билгеләү нәтиҗәсендә татар теленең үз сүзләрен генә түгел *(қанат, қарга, қойқа),* рус һәм башка теллəрдән кергән сүзләрне дә дөрес укырга мөмкинлек ачыла *(корпус, шкаф, бак, газон, ураган, Камал, инқар),* һич кирәксезгә катылык һәм нечкәлек билгеләрен кулланырга, бер хәреф урынына икенче хәреф язарга да кирәк булмый (дикъкать – диққәт, шигырь – шиғер, кәгазь – қәғәз h.б.).

Кызганыч, проектта кыска ирен-ирен тартыгына урын табылмаган. Ул язуда «у – ү» сузык аваз хәрефләре белән күрсәтелә, диелгән. Ләкин шатланырга иртәрәк: алты-җиде яшьлек мәктәп баласы аларның кайсы озын сузык, кайсы кыска сузык хәрефе икәнен каян белсен соң? Проект авторлары укучыны *тауы, дәүер, дәүа, һауа* кебек сүзләрне *тавы, дәвер, дәва, һава* дип ирен-теш тартыгы «в» белән бозып сөйләүгә чик куела, дип шатландырмакчы булалар. Ләкин шунда ук: «сүз башларында кыска „у–ү" урынына „в" язу калдырыла», – дип язылган. Димәк, язуда бер үк авазны ике төрле хәреф белән язабыз булып чыга. Проект авторлары моны зур ялгышка санамыйлар.

Ни кызганыч, 1958 елда киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителгән проект гамәлгә кертелми, проект хәлендә кала. Әмма шунысы куанычлы: ул 1989 елның 27 июнендә Татарстан АССР Югары Советы Президиумы Указы белән расланган «Татар әдәби теле алфавиты»ның нигезе итеп алына.

Алфавит киң җәмәгатьчелек тарафыннан күтеп алынса да, гамәлгә ашмады, андагы уңай үзгәрешләр язуга кермәде. Моңа 2000 еллар башында җәмәгатьчелектә киң таралыш алган «яңадан яңалифкә кайту» фикере комачау итте.

Россия хөкүмәте яңалифкә кайту мөмкинлеген чикләгән бер вакытта, иң дөрес юл – 1989 елның 27 нче июнендә Татарстан АССР Югары Советы Президиумы Указы белән расланган татар әдәби теле алфавитын гамәлгә кертү булыр иде.

Бу алфавитны һәм аңа нигезләнеп төзелгән орфографияне гамәлгә куюның берниндә кыенлыгы да юк, чөнки матди чыгымнар таләп итми, барлык хәрефләр дә компьютерда урын алган. Әлеге алфавит һәм орфография кагыйдәләре язуыбызда моңарчы яшәп килгән төп җитешсезлекләрне бетерүне күздә тотып тәкъдим ителгән. Алар тормышка ашкан очракта зурларга гына түгел, мәктәп укучысына да яшьтән үк язганны дөрес итеп укырга һәм саф әдәби телебездә матур итеп сөйләргә шартлар туар иде.

Әлеге алфавит нигезендә төзелгән орфография язуыбызны дөньяның иң алдынгы һәм камил язулар рәтенә чыгарыр дип ышанырга иртәрәк. Бу әле камиллеккә баруның бер адымы гына. Язу төзек, камил, укучыга тиз һәм җиңел аңлаешлы булсын өчен, Г. Ибраһимов әйткәнчә, алфавитта һәр авазга бер хәреф, һәр хәрефкә бер аваз йөрергә тиеш.

## ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ АЛФАВИТЫНЫҢ ЯҢАРТЫЛГАН ПРОЕКТЫ

Бу идеалга якынлашу өчен безгә тизрәк читтән кергән ике аваз тезмәсе функциясендә йөри торган «е» (йе – йы), «ю» (йу – йү), «я» (йа – йә) хәрефләреннән, сүзне кисүдәге (ъ) катылык, (ь) нечкәлек билгеләреннән һәм (э) хәрефеннән котылу зарур. Безгә киң җәмәгатьчелек фикеренә колак салырга вакыт җиткәндер инде. Гамәлдәге алфавит һәм орфографиябездә яшәп килә торган күп санлы хаталардан, ялгышлардан арынып, укучыга яңа, камилләштерелгән алфавит һәм орфография проектлары тәкъдим итәргә кирәк. Минемчә, анда телебезнең барлык специфик авазларына да урын бирелергә тиеш. Шулай ук чит теллардән кергән, телебез өчен ят булган хәрефләрдән һәм билгеләрдән дә котылырга кирәк. Мәкаләнең ахырында шундый проект тәкъдим итәргә булдым. Анда хәреф саны да гамәлдәге алфавитныкыннан артык түгел: барысы 36 хәреф һәм бер апостроф (') билгесе.

Яңартылган алфавит гамәлдәге алфавитка нигезләнеп төзелде һәм, киң җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алып, аңа кайбер үзгәрешләр кертелде:

1. *Каз, карга, Газиз, гаилә, гайрәт, Вахит, аваз, һава,* кебек сүзләрдә авазлары әйтелеп һәм тавышлары ишетелеп тә, әмма гамәлдәге орфографиябездә чагылыш тапмый торган [қ], [ғ], [w] аваз хәрефләре, рус теле һәм аның аша кергән *культура, физкультура, февраль, апрель, июнь, июль, генераль* (генераль план), *идеаль* (идеаль фикер), *оригиналь* (оригиналь хезмәт) кебек сүзләрдә нечкәртү, йомшартуны күрсәтү өчен ' (апостроф) билгесе өстәлде. «Қ», «ғ», «w» хәрефләре сүзнең барлык позициясендә дә (башта, уртада, ахырда) калын сузыклар янәшәсендә дә, нечкә сузыклар янәшәсендә дә языла.

2. Аваз тезмәләре функциясен башкаручы «е», «ю», «я» хәрефләре алфавиттан чыгарылды. Орфографиядә бу функцияне [йы], [йә], [йу], [йү], [йа], [йә] аваз тезмәләре үтиячәк.

3. Сүзнең калынлыгын һәм нечкәлеген сүз составындагы сузык авазлар билгели, ягъни составында калын сузык булса, сүз дә калын, нечкә сузык булса, сүз дә нечкә әйтелә. Шуңа күрә алфавитта ъ (калынлык) һәм ь (нечкәлек) билгеләрен тотуның кирәге калмый. Яңартылган алфавитка алар кертелмәде.

4. *Кулъязма, кулъюгыч, мәсьәлә, тәэмин, тәэсир, маэмай* кебек сүзләрдә сүз кисү һәм сүз аеру вазыйфасын башкаручы «э», «ъ», «ь» билгеләре урынына (апостроф) билгесе кертелә. (кул'йазма, мәс'әлә, тә'мин һ.б.).

| Баш хәрефләр | Юл хәрефләре | Хәрефләрнең әйтелеше |
|---|---|---|
| *1* | *2* | *3* |
| А | а | а |
| Ә | ә | ә |
| Б | б | бы |
| В | в | вы |
| Г | г | ге |
| Ғ | ғ | ғы |
| Д | д | ды |
| Ж | ж | жы |
| Җ | җ | җе |
| З | З | зы |
| И | и | и |
| Й | й | кыска и |
| К | к | ке |
| Қ | қ | қы |
| Л | л | лы |
| М | м | мы |
| Н | н | ны |
| Ң | Ң | ңы |

| *1* | *2* | *3* |
|---|---|---|
| О | о | о |
| Ө | ө | ө |
| П | п | пы |
| Р | р | ры |
| С | с | сы |
| Т | т | ты |
| У | у | у |
| Ү | ү | ү |
| W | w | wы |
| Ф | ф | фы |
| Х | Х | хы |
| Һ | Һ | һы |
| Ц | ц | цы |
| Ч | ч | чы |
| Ш | ш | шы |
| Щ | щ | щы |
| Ы | ы | ы |
| Э | э | э |
| ' | ' | апостроф |

**Әдәбият**

*Бәширов Гаскәр.* Совет әдәбияты. 1954. № 3. Б.104.
*Вәлиуллина З.* Совет әдәбияты. 1954. № 3. Б. 105–106.
*Галләмова М., Мифтахова Г.* Совет әдәбияты. 1954. № 3. Б. 107.
*Гомәрова И., Маликова Г.* Совет әдәбияты. 1954. № 3. Б. 106–107.
*Сабиров К.* Совет әдәбияты. 1954. № 3. Б. 106.
*Фасеев Ф.* Совет әдәбияты. 1954. № 3. Б. 104–105.

***Асылгәрәев Шәрифҗан Нурлыгәрәй улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК: 821.512.145

***Д.Ф. Заһидуллина***

# Г. ӘПСӘЛӘМОВ ПРОЗАСЫ: КӨЧЛЕ КЕШЕ ФӘЛСӘФӘСЕ АША РОМАНТИЗМГА

*Татар әдәбиятында иң авыр елларда*
*Әпсәләм бер үзе ун ел буена татар халкын*
*татар теле янында тотып торды.*
Х. Туфан

Статья посвящена творчеству Г. Абсалямова, в чьих произведениях военных и послевоенных лет, написанных в рамках канонов социалистического реализма, воспроизводятся общая патриотическая сила и интернациональная природа стремления к победе. Но эта патриотическая волна выводит образы людей за рамки схемы соцалистического реализма, на место «силы единения масс» приходит героизм отдельной личности: герои, созданные писателем, воплощены в амплуа истинных богатырей, сильных людей, личностей, способных изменить мир. В творчестве писателя появляется романтическая сильная личность – национальный герой, татарин. В условиях, когда по требованию идеологии эпохи наблюдалось усиление интернационализма, подчеркивалось лидерство не отдельного человека, а партии, создание в татарской литературе образа татарского борца, батыра-татарина уже само по себе было проявлением отваги! Писатель в лозунг эпохи «сильный человек – коммунист» вносит свою поправку «сильный человек – тот, кто служит народу», сильных личностей создает в традициях классического романтизма с помощью понятий «красота» и «справедливость». Эти герои в общую реалистическую ткань произведения вносят романтический «голос», или наоборот, как в романе «Белые цветы», выводят роман к романтическому направлению. В этом творчестве в плане компановки произведения и отношений автор – герой вновь обновляется синтетизм.

**Ключевые слова**: романтизм, синтетизм, образ главного героя, роман.

Габдрахман Әпсәләмов әдәбият мәйданына Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан килеп керә: М. Горький исемендәге Әдәбият институтын (Мәскәү) тәмамлаган яшь язучының 1940 елда «Киләчәк безнеке» исемле пьесасы, 1941 елны беренче хикәяләр җыентыгы басылып чыга. Беренче әсәрләрендә, искене җимереп, яңаны төзү барышын үзәккә куйган язучының иҗат стиле формалашуда сугыш елларының йогынтысы зур була. С. Хәким 1984 елда язганча, «Әпсәләмов – тулысы белән Ватан сугышы чоры язучысы. Шул заман рухы тудырган язучы. Күтәренке рух, романтик рух. Стиленең публицистик характеры да шуннан. Сугыш һәм яшьлек, героика бергә кушылды. Заманы – романтик» [Хәким, б.43].

1941 елдан 1946 елга кадәр фронтта булган Әпсәләмов бу чорда язылган күпсанлы хикәяләрендә («Икенче гомер», 1942; «Абушахман», 1942; «Үлемнән

көчлерәк», 1943; «Байрак», 1943 һ.б.), «Ак төннәр» (1946) повестенда гади солдатларның батырлыгы, ил азатлыгы өчен гомерен кызганмавы хакында сөйли, гадәти вакыйгаларда сугыш фаҗигасен дә, кеше күңеленең олылыгын да ачып бирә. Сугыштан соң иҗат ителгән романнарында («Алтын йолдыз», 1948; «Газинур», 1951; «Мәңгелек кеше», 1960) да кешеләрне сугыш шартларында, зур сынаулар аша уздырып сурәтли. Социалистик реализм кануннарын саклап язылган әлеге әсәрләрдә җиңүгә омтылышның гомуми патриотик көче һәм интернациональ табигате тергезелә. Ләкин шушы патриотик дулкын кеше образларын социалистик реализм таләп иткән схемалардан читкә алып чыга, «массалар бердәмлегенең көче» урынына – аерым шәхес героизмы килә, язучы иҗат иткән геройлар – чын батырлар, дөньяны үзгәртерлек шәхес итеп гәүдәләнә.

Э.А. Бальбуров фикеренчә, аерым милләтләр мәдәниятендә мондый күренеш үсешнең тизләнү моментларына хас, «урнашып җиткән сәнгать теле системасының басымына каршы тора», ахыр чиктә, «һәм эчтәлек, һәм форма ягыннан үзгәрешләрне тәэмин итеп, яңа дөнья сурәте урнашуга китерә» [Бальбуров, с. 269]. Г. Әпсәләмов иҗатында да бу шулай. Аның иҗтимагый-тарихи төгәллек белән иҗат ителгән чор картинасына урнаштырылган геройлары бу картинаны киңәйтә, дөньяга төгәл-тарихи гына түгел, бәлки фәлсәфи караш барлыкка китерә. Әлеге үзәк геройларның татар кешесе, татар менталитетын калку рәвештә үзендә йөртүче, гасырлар тирәнлегеннән килгән милли кыйммәтләрне саклаучы амплуасында бирелеше бу тәэсирне көчәйтә генә. Ә. Баянов хаклы рәвештә билгеләгәнчә, «Г. Әпсәләмов әсәрләрендә татар солдатлары, татар кешеләре батырлыгына дан җырлана» [Баянов, б. 63].

Бу яктан язучының «Мәңгелек кеше» романы аерым игътибарга лаек. Аның герое – Бухенвальд үлем лагеренда бунт әзерләгән әсир Бакый Назимов – коммунист. Әсәрнең беренче бүлеге шулай атала да: «Мин – коммунист!». «Сез – подполковник Бакый Назимов. 1941 елда Мәскәүдә хәрби академия тәмамлагансыз. Сугыш башлангач, Волхов фронтында полк командиры. Сезнең полк Волхов урманнарында актык кешесенә кадәр сугышкан. Без моны беләбез һәм тәкъдир итәбез. Сез – батыр командир. Совет хөкүмәте сезне Кызыл Байрак ордены белән бүләкләгән» [Әпсәләмов, 1970, б. 5]. Майор Реммерның әлеге сүзләре укучы күз алдына ул чор әдәбиятында традицион батыр коммунист образын китереп бастыра. Назимов белән бергә, әсирлектә көрәшне оештыручылар да – коммунистлар. Роман буенча автор моны гел тәгаенләп бара. «Совет кешеләренә хас булган типик сыйфатлар – инанганлык, көчле рухлылык – романдагы төп геройларның характерындагы аеруча калку гәүдәләнеш ала» [Мөхәммәдова, б. 26].

Шушы беренче бүлекчә артыннан ук «Кай җирләрнең бөр-

кет баласы» дип исемләнгән икенче бүлекчә тәкъдим ителә. Язучы героеның Урал таулары буенда тууын сөйли: «Әтисе Гатаулла абзыйны авылдашлары буе-сыны һәм көч-җегәре өчен Аю Гатаулла дип, ә балаларын – Аю балалары дип йөрткәннәр» [Әпсәләмов, 1970, б. 13] имеш. Шунда ук Гатаулланың тормыш фәлсәфәсе кителә: «Азамат ир дөньяда гайрәт белән яшәргә тиеш! – дип кычкыра ул бер потлы гер зурлыгындагы йодрыгын селкә-селкә. – Бөркет кебек! Кол булып, бил бөгеп түгел! Беттем дигәндә дә бетмәдем, диген! Минем әткәйнең әтисе Бородино янында Бонопартка каршы күкрәк киереп сугышкан. Сез белмисездер шул әле. Бабайның бабасы, туфрагы җиңел булсын, Пугач янында йөзбашы булган! Казан каласын алганда, беләсегез килсә, иң алдан барган. Йөз мең гаскәр аңа каршы тора алмаган. Йөз мең, мәхлуклар!» [Әпсәләмов, 1970, б. 14]. Шул рәвешле, героен көчле нәселдән чыккан халык улы амплуасына куя.

Алга таба аңа исем кушу вакыйгасы да, Бакыйга кадәр ата белән ананың балалары тормау да, чәчәк авыруыннан чак исән калуы да – татар халык әкиятләре һәм мифлары белән ассоциацияләр уята. Үлем лагеренда әсирнең күргәннәрен сурәтләгәндә, автор кабат халык әкиятләре структурасына мөрәҗәгать итә. Бакыйның өч тапкыр «үлеп терелүе», барлык авырлыкларны сынмыйча кичерүе, ахыр чиктә, Бухенвальдта баш күтәреп, тоткыннарның исән калуын тәэмин итүе – аны чын мәгънәсендә әкияти геройга әйләндерә. Бакый исеме – мәңгелек кеше мәгънәсендә – каһарманлыкның, ил һәм яшәү өчен көрәшнең символына әверелә. Коммунист-героен язучы халыкның әкияти герое структурасында иҗат итә. Аның төп максаты да әкиятләрдәге кебек: үлемне җиңү! Бухенвальдтагы көрәшнең ахыргы максатын язучы Йозеф авызыннан әйттерә: «Көрәш үлемнән көчлерәк».

Шул рәвешле, Г. Әпсәләмовның сугыш геройларын сурәтләүгә багышланган әсәрләрендә татар әдәбияты өчен яңа күренеш калкып чыга: милли герой, көчле кеше, тормышны үзгәртүче генә түгел, бәлки үлемне җиңгән романтик образ – татар кешесе образы ул. Чор идеологиясе таләп иткәнчә интернационализмның көчәюе, аерым кешенең түгел – партиянең лидерлык роле ассызыклану шартларында милли әдәбиятта татар каһарманы, татар батыры образын үзәккә кую үзе дә батырлык була! Әлеге образ язучының үз иҗатын реализм юнәлешеннән романтизмга борып җибәрүгә хезмәт итә. Моңа чор рухы гына түгел, бәлки герой образының милли-мифологик структураларда иҗат ителүе дә зур йогынты ясый.

1960–1980 еллар татар әдәбиятында мәйданга чыккан иң әһәмиятле күренешләрнең берсе, шиксез, классик романтизм традицияләрен тергезү иде. Әлбәттә, 1917 елдан соң формалашкан инкыйлаби, героик романтизм классик романтизм хасиятләреннән читкә китә, яшәп килүче рәсми идеология куйган таләпләргә буйсына. Классик романтизм исә 1930 еллардан башлап, модернистик

күренешләр кебек үк, кире кагыла, буржуаз әдәбиятка хас күренеш кебек шәрехләнә. Шуңа күрә классик романтизмны тергезү XX йөз башы татар әдәбияты традицияләре белән бәйләнеш урнаштыру, шуларны кабат әдәбиятка кайтару төсен ала. Классик традицияләргә йөз тоткан романтизмның үзенчәлекле сыйфаты – ике катлы тормыш сурәтендә инкыйлаби идеал түгел, бәлки гомумкешелек идеалы тудыру иде. Әдип милли әдәбиятка өр-яңа форма һәм эчтәлек, кешедәге аң төпкеле, сиземләү, күзаллау-хыял белән бәйле яңа мотивлар, тормышның чиксезлеген һәм кешенең эчке дөньясының байлыгын белдерүче геройлар бирде.

Чор әдәбиятының олы казанышы булган әсәр – Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» (1966) романы романтизм юнәлешендә иҗат ителә, укучылар арасында иң популяр әсәрләренең берсенә әверелә. Ләкин, фон буларак, төгәл-тарихи вакыт күрсәтелсә дә, әсәрдәге романтик гомумиләштерүләр һәм геройлар тарихлары белән бәйле «тавыш»ларга социалистик реализм таләпләренә җавап бирерлек итеп эшләнгән «өстәлмәләр» килеп кушыла. Шунысы кызык, бу өстәлмәләрдә социалистик җәмгыять төзү тарихындагы фаҗигале хәлләр – шәхес культы вакыйгалары, аларның кешеләр язмышына тәэсире, шуңа мөнәсәбәт күрсәтелә. Шуңа күрә дә татар әдәбияты белемендә романның иҗат юнәлешен билгеләү мәсьәләсендә фикер төрлелеге яшәп килә.

Бу романның да тәэсир көче, популярлык сәбәбе, барыннан да элек, милли характерлар, халкыбызның ерак гасырлардан килгән гүзәл сыйфатларын үзендә туплаган образлар тудыруда булуы шиксез. Г. Әпсәләмов иҗаты чор әдәбияты фонында үзенең милли-халыкчан геройлары һәм сурәтләнгән дөнья ярдәмендә зур гомумиләштерүләр ясалуы белән аерылып тора. Менә бер мисал. Г. Минскийның «Язның бер көне» (1962) повесте сюжет бирелеше, төп конфликт, хәтта халыкка хезмәт итү мотивының беренче планга чыгуы ягыннан «Ак чәчәкләр» романы белән «кисешә». Ләкин роман соңрак иҗат ителгән булса да, нәкъ менә югарыда билгеләнгән сыйфатлар аны тирән эчтәлекле һәм тәэсирле, уйландыра торган текст буларак таныта.

Вакыйгалар медицина институтын тәмамлап, татар авылына эшкә кайткан Гөлшәһидәнең профессор Әбүзәр Таһиров җитәкчелегендә яхшы врач булып өлгерүе, кешеләр белән аралашу һәм аларга ярдәм итү хакыйкатенә төшенүе, Мансур белән мөнәсәбәтләре, гаилә кору тарихы хакында сөйли. Төп геройның бәхеткә ирешү юлын тасвирлау ике сюжет чылбыры тирәсенә җыела: берсе – медицина белгечләре тормышын яктыртып, аңа хас проблемаларны күтәрә, биредәге каршылык гомумкешелек әхлагы үлчәвенә салына; икенчесе – мәхәббәт тарихы – романтик алымнарга таяна.

Романтик сюжет сызыгы Гөлшәһидәнең Мансур белән танышуы, гашыйк булуы, үткән мәхәббәт тарихлары турында сөйли, Мансурның кинәт аны ташлавы, Илмирага өйләнүе, кызлары Гөлчәчәк тугач, Илмираның һәлак булуы кебек вакыйгалар

җирлегендә үсә бара. Язучының Гөлшәһидә хисләрен аның үз исеменнән сөйләп баруы әсәрне психологик дулкынга көйли. Чын татар кызына хас иң матур сыйфатларны үзенә туплаган Гөлшәһидә идеаллаштырылып сурәтләнә. Язучы Гөлшәһидә һәм Мансур күңелендә туып, үсә-ныгый барган хис һәм фикер көрәшен, үзгәрешен детальләп сурәтли, укучыны сокланырга, борчылырга, алар тормышы белән яшәргә мәҗбүр итә. Әлеге мәхәббәт тарихы татар әдәбиятындагы сөюгә багышланган гүзәл әсәрләр традицияләрен дәвам итә. Хисләр алмашуын табигать белән янәшәлектә тасвирлау, психологик характердагы символик, метафорик образлар һәм детальләр куллану, метафора рәвешендә җыр текстларын урнаштыру шундыйлардан.

Төп каршылык Әбүзәр белән Фазылҗан, ягъни дөньяга төрле карашлы шәхесләр арасында бара, Мансур, Гөлшәһидә, Юматша, Сәлах Саматов, Клавдия Сергеевна кебек геройлар йөзендә кабатланып, ике төрле дөнья моделе төзүгә китерә. Язучы раслаган һәм хуплаган модель «халыкка хезмәт итү» кебек аңлашыла: «Халык ул бөек шагыйрьләрен дә, художникларын да, һәм меңләгән Лотфи, Шәйхук, Мортазаларын да тудыра. Без барыбыз да халыктан чыккан һәм актык сулышыбызга кадәр халыкка хезмәт итәргә тиешбез» [Әпсәләмов, 1968 б. 470]. Моны Г. Әпсәләмов төп герое авызыннан кат-кат әйттерә. Әйтик, Янгура белән мәкаләләр язу турында сөйләшкәндә профессор болай ди: «Гонорар өчен язганда, әлбәттә, шулай итәргә кирәк, ләкин халык өчен язганда, – профессор башын чайкап алды, – халык өчен язганда, Фазылҗан, эш башкачарак» [Әпсәләмов, 1968, б.76]. «Халык» төшенчәсе профессорның пациентлары – чын халык уллары кебек тәкъдим ителгән оста куллы, матурлыкны яратучы, хезмәт сөючән, бай күңелле һәм олы йөрәкле геройларны, аларның дөньяга карашын, яшәү рәвешен күрсәтеп ачыла. Шушы ачкыч-сүз романны бер үзәк тирәсенә туплаучыга әверелеп, төп геройларның эш-гамәлләре, уй-фикерләре иҗтимагый сәбәпләр, коммунизм төзү белән детерминацияләнмичә, романтик төстә, халыкка хезмәт итү кебек гомумкешелек идеалы аша аңлатыла. Авторның өстенлекле «тавыш»ы да романтик кимәлдә булып чыга.

Дәвалаучы докторларның берсе – үз эшенә салкын карый торган Сәлахның битарафлыгы аркасында авыруның үлгәнен белгәннән соң, профессор авызыннан мондый сүзләр яңгырый: «Ак халат астында таш бәгырь... бу ваба кебек куркыныч нәрсә. Кеше аңа җанын ышана, үз бәхетен, семьясының бәхетен ышана, ә ул...» [Әпсәләмов, 1968, б. 116].

Әсәр ахырында, Г. Тукай шигыренә мөрәҗәгать итеп:

«Әйдә халыкка хезмәткә,
Хезмәт эчендә йөзмәккә!», –

дигән сүзләрне әйткәч Әбүзәр Гиреевич болай дәвам итә: «Халыкка хезмәт итү минем иң татлы хыялым иде. Университетны тәмамлагач, терапия корифее – профессор Алексей Николаевич Казем-Бек миңа ординатурада калырга тәкъдим итте. Бөек Казем-Бек! Ә мин авылга җибәрүләрен үтендем. Чишмәгә. Башкорт далаларында адашкан

Чишмәгә! Минем күбрәк вакытым юлда, авылларда үтте» [Әпсәләмов, 1968, б. 506].

Шушы позициягә каршы куелган Фазылҗан Янгурага исә аны электән яхшы белгән авыру болай ди: «Сез авыруларны түгел, чиннарны дәвалаучы икән!» [Әпсәләмов, 1968, б. 501]. Әлеге фикер – матди байлык, шәхси уңайлы тормыш хакына врач антын бозу – әсәр буенча искәртелеп бара. Әсәрдә Ә. Еникинең матди һәм рухи байлыкларга йөз тоткан геройлар ярдәмендә антитетик характерлы дөнья тудыруы белән аваздашлыкны тоясың!

Роман исеменең төп мәгънәсе дә шушы фикергә бәйле ачыла. Әбүзәр Гиреевич Мансур белән Гөлшәһидәгә әлеге башкорт авылында бер хатынның баласын аякка бастыруын, шул хатынның аңа нидер бүләк итәргә теләвен сөйли. Болыннан ак чәчәкләр җыеп китерсә, моның зур бүләк булачагын әйткән Әбүзәрләр бусагасына кемдер таң белән ак чәчәкләр салып китә башлый. Ә 60 яшьлек юбилеена студентлары профессорга «пыяла савыт эчендә фил сөягеннән эшләнгән гаҗәеп нәфис ак чәчәк» [Әпсәләмов, 1968, б. 508] бүләк итәләр. Әлеге бүләк халык мәхәббәтенең, халык рәхмәтенең символы булып аңлашыла. Аны Мансур белән Гөлшәһидәгә тапшырганда Әбүзәр Гиреевич болай ди: «Бүген бу чәчәкне, дусларым, сезгә бирәм. Гомерегез буе ак килеш, пакь килеш саклагыз аны. Хәшәп булмагыз. Вексельләр белән эш итмәгез! Чиннарны дәваламагыз! Минем кебек картайгач, бу чәчәкне күңелегезгә якын кешегә бирерсез. Берүк, ул кеше врач була күрсен...» [Әпсәләмов, 1968, б. 508]. Бу сүзләрдә символның икенче мәгънәсе – врач һөнәренең изгелегенә ишарә ясавы да күренә. Әсәр ахырында теплоходта билгесез хатын тарафыннан Гөлшәһидәгә рәхмәт йөзеннән бирелгән чәчәкләр кабат халык рәхмәте мәгънәсен алга чыгара. Шул рәвешле, автор позициясе, «тавыш»ы символлар ярдәмендә ассызыклана.

Роман эчендә язучы символның башка мәгънәләрен дә калкытып куя. Гөлшәһидәнең көндәлек тормышында кат-кат күренеп, бу чәчәкләр аклыкны, сафлыкны, чисталыкны да белдерәләр. Мәхәббәт хисе белән янәшәлектә матурлык символына да әйләнәләр.

Врачлар, медицина хезмәткәрләренең көндәлек эш-тормышын яктыртканда да язучы Әбүзәр Гиреевич, Чалдаев, Мансур, Юматша кебекләрнең эш-гамәлләрендә дә, эчке дөньяларында да авыруларга ярдәм итү сыйфатын беренче планга чыгара. Фазылҗан Яңгура, Илһамия, Сәлах Саматов, Клавдия Сергеевна кебекләрнең гамәлләрендә дә, күңелләрендә дә үзләрен өстен итеп күрсәтү, көнчелек, эгоизм, кешеләргә кимсетеп карау тоемлана. Геройларның мондый бүленеше шулай ук халык өчен яшәү белән үзең өчен яшәү каршылыгын ассызыклый.

Романтик уңай геройларның ике буыны мисалында тәкъдим ителүе язучыга гомумкешелек кыйммәтләренең югалмавын, дәвамчанлыгын расларга мөмкинлек бирә. Бер яктан, Гөлшәһидә, профессор Таһиров кебек үк, «көчле кеше» тибы – үз позиция-

сеннән чигенми, башлаган эшен ахырына кадәр җиткерә торган шәхес. Ул – матурлыкка, мәхәббәткә, хакыйкатькә омтылучы, нечкә хисле, шигъри-музыкаль табигатьле, чибәр хатын-кыз. Шул ук вакытта ул – хезмәт кешесе, совет чоры идеаллары белән яши, аларны тормышка ашыру юлында армый-талмый эш-гамәлләр кыла, бу яктан Галияләрнең (Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар») дәвамчысы да. Әсәрдәге конкрет-тарихи фон, иң беренче чиратта, шушы образ ярдәмендә тергезелә.

Бигрәк тә романның дүртенче бүлегендә, Гөлшәһидәнең Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXII съездында делегат булып катнашуы, анда күргән-кичергәннәрен, кайткач шушы хакта сөйләүләрен язучы социалистик реализм таләп иткән күренешләр аша сурәтли. Төп героиня заман кешесе, социалистик идеалларга да тәңгәл килә торган шәхес булып күренә башлый. Бу өстәлмәләрдә шәхес культына мөнәсәбәт белдергән урыннар да бар. «Партиянең көрәш пафосы да, ул көрәшнең дөньякүләм колачы да, гаделлекне ничек яклавы да, куркусызлыгы һәм турылыгы да аңа съездда гына бөтен гүзәллеге, бөтен аяусызлыгы белән ачылды. Әйе, гүзәллеге һәм аяусызлыгы белән бергә. Чөнки хакыйкать кайчак бик ачы да була икән. Күздән яшь чыгарырдай ачы була икән. Шәхес культының илгә, халыкка китергән авыр яралары турында тыңлаганда, Гөлшәһидәнең йөрәге аз әрнемәде.

Ул үзенең пионерда, комсомолда чакта Сталинга биргән антларын, ул үлгәч әрнеп елауларын исенә төшерде. Юк, болар рияланып биргән антлар, рияланып түккән күз яшьләре түгел иде. Болар барысы да чын күңелдән иде, пакь иде» [Әпсәләмов, 1968, б. 339]. Шушы уйларның дәвамы булып кызның көндәлек дәфтәренә төшкән сүзләр дә әлеге фикерне ассызыклый: шәхес культы хакындагы хакыйкать әлеге фаҗиганең кабатланмавы өчен кирәк!

Шунда ук язучы берничә герой мисалында шәхес культы китергән бәхетсезлекләрне искәртеп уза. Чәчәкләр үстерүче Мортаза бабай шикаятьләр язу кебек кыңгыр эшне бәяли: «Менә шул пирсон бакчамның башын ашады. Аның әләкләве буенча килделәр дә... Ә үзебез, камунизм, дибез, кешеләребез яхшыра, чистара, дибез. Иң элек шушындый аша чыккан бдительныйлардан чистарырга кирәк иде безгә...» [Әпсәләмов, 1968, б. 353].

Маһирә ханымның Гөлшәһидәгә сөйләгән тормыш тарихы – ире эсирлектә булган өчен тормышы җимерелү – әлеге хәлләргә тагын да ачыклык кертә төшә. «– Мин сезне эшегездән чыгарырга мәҗбүрмен, – дип, башына күсәк белән суккандай каршы алган. Маһирә ханым ирен яклап авыз ача башлагач, Тютеев өстәл сугып: – Ул – предатель! – дип кычкырган.

– Ни сөйлисез, Шаһгали Галиевич! Андый кешемени ул? Үзегезгә нихәтле яхшылыгы тиде, исегезгә төшерегез. Үлгән хәбәре килгәч, сез аның турында нинди яхшы сүзләр сөйләдегез... Оныттыгызмыни?... – Шулай дип әйттем үзенә. Ә ул күземә карап

үз сүзләреннән ваз кичте, минем ирем аңа гел начарлык кына эшләгән кеше булып чыкты... Шуннан соң мин аңа үземнең сугыш буе госпитальдә эшләвемне, орден-медальләр алуымны, донор булуымны әйтеп карадым. Тютеев бары тик иремнән аерылган тәкъдирдә генә эшемдә калдырырга риза булды. Мин эшемне яратсам да, бу тәкъдимне нәфрәтләнеп кире кактым. Бик кыенлык белән генә хәзерге эшләгән больницага эшкә урнаша алдым. Әбүзәр Гиреевич булмаса, ихтимал, урнаша да алмас идем, ул әллә кайларга барып, минем өчен поручаться иткән. Моны мин гомер онытасым юк. Ләкин миңа бу больницада да тынычлык бирмәделәр. Атна саен диярлек органнарга чакырып тордылар. Бигрәк тә Тютеев азынды. Искә төшерәсе дә килми ул елларны. Өлкән улымны суворовчылар мәктәбеннән кудылар. Әллә акыл керә башлаганга, әллә холкы шундый булганга, бу фаҗигане ул артык авыр кичермәде. Әмма уртанчы малаем мәктәптән һич тә китәргә теләмәде. Китмим, дип, күз яше белән елады... Тютеевларның сүзен тыңлап түгел, шул сабый балам хакына... үз бәхетемне корбан иттем, – диде Маһирә ханым, өстәлгә капланып. – Мин иремнән аерылдым... Мин аны тереләй күмдем... Кем дә булса бу фаҗигане яхшылап аңлармы икән? Балаларыма күрсәтми күпме күз яше түктем мин. Саргаеп, кибеп беттем» [Әпсәләмов, 1968, б. 355–356].

Тагын бер вариант маңгаенда кызыл эзе булган авыруның үзе үлгәннән соң профессорга бирергә дип язып калдырган хатында ачыклана. Ул – гаепсез дип иреккә чыгарган кешеләр өчен үзе зинданга эләккән тикшерүче хакыйкате. Һәм шушы кабатлауларда автор фикере, автор позициясе урнашкан: ул тормыш агышында, җәмгыятьне үзгәртү барышында халык мәнфәгатьләренең беренче урынга куелырга, эш-гамәлләрнең халык өчен әһәмияте күзлегеннән бәяләнергә тиешлеген ассызыклый. Шәхес культының халык өчен түгел, бәлки шәхси мәнфәгатьләрдә яки явыз максатларда кылынган гамәлләренең нәтиҗәсе буларак күрсәтелүе романда язучының теләсә нинди үзгәрешләрнең, инкыйлабларның, хәтта һәр кешенең гадигадәти эш-гамәлләренең халык файдасын күздә тотып башкарылу зарурияте хакындагы фикерен укырга юл күрсәтә.

Үз эшенә бирелгән профессор Таһиров образы да шушы структурада иҗат ителә. Аның тормыш позициясе, яшәү рәвеше авторның да врач намусы, йөз аклыгы турындагы уйланулары, фикерләре булып төгәлләшә. Шуңа бәйләп, врачлар тормышының кредосы ачыклана: ул һәрчак кешеләр тормышы хакына яшәргә тиеш, кешелекнең киләчәге алар кулында. Үз идеясен җиткерү барышында автор тагын да уңышлырак юлны сайлап, ак чәчәкләр образына мөрәҗәгать итә. Көчле позициягә – әсәр исеменә үк чыгарылган әлеге образ вакыйгалар агышында күпмәгънәле символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Бер яктан, ул врачлар, кеше гомере өчен көрәшүче медицина хезмәткәрләре буларак аңлашыла; икенче яктан, аның аклыгы Әбүзәр, Гөлшәһидә, Мансур, Юматша, Ди-

ләфрүз кебекләрнең күңел аклыгына, тормышларындагы якты идеалларына аваздаш яңгырый; өченче яктан рухи югарылыкка ирешү символы булып укыла. Шул рәвешле, романда кешеләр арасындагы ихлас мөнәсәбәтләргә, врачлар тормышындагы хезмәткә табынуга нигезләнгән тормыш фәлсәфәсе татар укучысына якын лирик-эмоциональ дулкында тәкъдим ителә. Г. Әпсәләмов үзе язганча, «Язучының иҗат фантазиясе, әсәрләре никадәр генә катлаулы һәм мавыктыргыч булмасын, алар күктән төшми, түшәмнән алынмый. Ул күзгә күренмәгән, бик нечкә, ләкин гаҗәеп җепләр белән халык тормышына барып тоташа» [Әпсәләмов, б. 120].

Сәясәткә, идеологик таләпләргә түгел, халык тормышына барып тоташа торган «җепләрне» Г. Әпсәләмов романтик геройлар, көчле кеше – романтик образларында таба. Шушы сыйфат аның иҗатында яңалык булып яңгырый, язучы чорның «көчле кеше – коммунист» лозунгысына «көчле кеше – халыкка хезмәт итүче» дигән «төзәтмә» кертә, көчле шәхесләрне, классик романтизмдагыча, матурлык һәм хакыйкать төшенчәләре ярдәмендә иҗат итә, шулай итеп әдәбиятның сурәтләү өлкәсен иҗтимагый мөнәсәбәтләрдән – гомумкешелек кыйммәтләренә юнәлтүгә үз өлешен кертә. Язучы иҗатында, иҗтимагый сәбәпләр һәм ситуацияләргә бәйлелектә калса да, характер буларак романтик көчле шәхесләр пәйда була. Әлеге геройлар әсәрләрнең гомуми реалистик тукымасына романтик «тавыш» алып керәләр яки, киресенчә, «Ак чәчәкләр» романындагыча, әсәрне романтизм юнәлешенә алып чыгалар. Бу иҗатта әсәрнең оештырылышы һәм автор-герой мөнәсәбәтләре ягыннан синтетизм күренеше кабат яңара.

**Әдәбият**

Ак чәчәкләр бүләк итте. Габдрахман Әпсәләмов турында истәлекләр. Казан: Мәгариф, 2001. 159 б.

*Әпсәләмов Г.* Ак чәчәкләр. Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. 523 б.

*Әпсәләмов Г.* Сайланма әсәрләр. 6 томда. Т. 4: Мәңгелек кеше. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. 357 б.

*Бальбуров Э.А.* Художественно-философский неосинкретизм в русской литературе начала XX века: дис. ... д-ра филол. наук. Новосибирск, 2006. 382 с.

*Баянов Ә.* Кыялар исән кала // Ак чәчәкләр бүләк итте. Габдрахман Әпсәләмов турында истәлекләр. Казан: Мәгариф, 2001. Б. 63–66.

*Мөхәммәдова Г.* Ул үзе дә – каһарман! // Ак чәчәкләр бүләк итте. Габдрахман Әпсәләмов турында истәлекләр. Казан: Мәгариф, 2001. Б. 26–27.

*Хәким С.* Батырлыкка чакырган кеше ... // Ак чәчәкләр бүләк итте. Габдрахман Әпсәләмов турында истәлекләр. Казан: Мәгариф, 2001. Б. 43–44.

*Мәкалә РГНФ (проект № 14-14-16002) гранты кысаларында эшләнде.*

***Заһидуллина Дания Фатыйх кызы**, филология фәннәре докторы,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибе.*
*E-mail: zagik63@mail.ru*

УДК 821.512.145

***Ф.Ф. Хәсәнова***

# РЕНАТ ХАРИС ИҖАТЫНДА МУСА ҖӘЛИЛ ОБРАЗЫ

В статье предлагается обзор произведений Рената Хариса в контексте изображения образа Мусы Джалиля. Особое внимаие уделено тому, что образ Джалиля сопровождает поэта с начала его творчества, т.е. с 1960-х годов.

**Ключевые слова:** личности с трагической судьбой, джалиловедение, символ мужества татарского народа, драматическая поэма, «Сонет о крови Джалиля».

Хәзерге әдәбиятта татар халкының гыйбрәтле язмышлы тарихи шәхесләренә багышлап язылган әсәрләрнең артуы күзгә ташлана [Хасанова, 2009]. Шагыйрь Газинур Морат, әлеге күренешкә үзенең шигъри мөнәсәбәтен белдереп, болай дип язган иде:

*Бөекләргә таянабыз,*
*Тормыш белән бәхәс чыгып,*
*үзебезне яклаганда,*
*аклаганда,*
*яман сүздән сакланганда...*
[Морат, 2005]

XIX гасырның билгеле шагыйре Гомәр Мөхәммәт углының «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» әсәрендә дә *«Һәр чор әдәбияты үз заманының күренекле шәхесләре турында язарга тиеш!»* дигән фикер үткәрелә [Гайнетдин, 2001]. Шәехзадә Бабичның «Китабеннас фи хакыл-хавас» (1917) китабы да билгеле шәхесләрне барлауга багышлана [Әдәбият..., 2007].

Татар әдәбиятында әлеге тема 90 нчы еллардан соң аеруча активлашып китте кебек. Һәр татар шагыйренең диярлек М. Акмулла, Г. Тукай, Г. Исхакый, Дәрдемәнд, Һ. Такташ, М. Җәлил, С. Хәким, Х. Туфан, Ә. Еники турында шигырьләре бар. Соңгы елларда Ф. Шәфигуллин, К. Сибгатуллин, Рәш. Әхмәтҗан, Ф. Сафин, М. Әгъләм, Т. Миңнуллин турында язучылар күбәйде [Хәсәнова, 2010]. Шагыйрьләр, бу дөньядан киткән шәхесләр турында яза-яза остарып, хәзер исәннәргә дә игътибар итә башлады. 1967 елда Шәүкәт Галиев сирәк очрый торган талантлы шәхесләрне үзләре исән чагында ук өйрәнеп калырга кирәклекне язып чыккан иде. Әдәбият белеме галиме Нил Юзиевның «Традицияләр яңарганда» исемле китабы басылып чykканнан соң, ул:

*Эзләнергә, уйланырга, шигырь*
*белән янарга.*
*Сау шагыйрьләр турында да*
*мөмкин икән язарга!»* –

дип язган булган [Галиев, 2002, б. 184].

Ә менә халык шагыйре Ренат Харис гомер буе татар халкының күренекле шәхесләренә: язучышагыйрьләре, тарихчы-сәясәтче, сәнгать өлкәсендә эшләүчеләргә игътибарлы булды [Харисов, 2006, б. 466–499]. Шул сәбәпле, аның Муса Җәлил турында язуы һич тә гаҗәп түгел. Аның үзенең Муса Җәлил исемендәге Дәүләт

премиясе иясе икәнлеге дә «тема эчендә булу»ын күрсәтә. Шагыйрь бер шигыренең исемен «Татарлык тамгасы» дип атый. Анда мондый юллар бар:

*Тукай – татарның җыр-моңы,*
*Җәлил – батыр агасы.*
*Кем икән безнең татарда*
*Чын татарлык тамгасы?»*

[Харисов, 2002]

Татар әдәбияты Җәлил образын тудырган әсәрләргә бервакытта да кытлык кичермәде. Шагыйрь реабилитацияләнгәннән соң, Совет чоры әдәбиятында әлеге күренеш югары ноктасына җитте кебек. Бигрәк тә Илдар Юзеев күләмле драматик поэмалары белән матур биеклекләр яулады [Юзеев, 2002]. «Соңгы төн» трагедиясендәге Җәлил образының татар әдәбиятындагы ныклы, какшамас, сәясәт җилләреннән авышмас бөеклеге яңа гасырга чыккач язылган әсәрләргә мөнәсәбәтендә дә күренде [Сәхапов, 2009]. Ике авторның Җәлил шәхесенә кара ягу фактларын күрсәткән поэмасы газетада басылып чыгу белән, аларның икесе дә җәмәгатьчелекнең кискен нәфрәтенә дучар булды [Баттал, б. 29]. Әсәр авторлары, «татарлык тамгасы» булган Җәлил образын каралтып күрсәткәннәре өчен, Татарстан Язучылар берлегеннән чыгарылды [Бәдертдинова, б. 153].

Ренат Харис, үзе дә сугыш чоры баласы булганлыктан, сугыш темасыннан беркайчан да читкә китмәде [Харисов, 2011]. XXI гасырга чыккач, ул Бөек Ватан сугышына карата өр-яңа карашларны чагылдырган, совет чорында киң катлам кешеләргә билгеле булмаган фактларны күрсәтеп, берничә әсәр язды. «Шөкер», «Җиңүче», «Җиңү күргәзмәсе» поэмалары – шундыйлардан [Харисов, 2001]. Бу поэмалар, укучы өчен өр-яңа кызыклы сюжетка нигезләнеп, бер үк вакытта документальлеккә дә дәгъва итә торган, лирик-публицистик жанрга мөнәсәбәтле әсәрләр рәтендә урын алырга лаек.

Шагыйрь иҗатының беренче чорында ук «Җәлилчеләр» циклын язган иде [Харисов, 2006]. Цикл 14 бүлектән гыйбарәт. «Кереш» һәм «Соңгы сүз»дән кала тагын 12 бүлекнең һәрберсе берәр җәлилче исеме белән атала. «Без батырлык эзләп яшәмибез», дип башланып киткән кереш горурлык пафосы белән тулы, совет чорына хас лозунглар да мул кулланылган юллардан тора. «Муса Җәлил» исемле бүлек шагыйрьнең үлем карары «өстенә» язган җыр тексты белән хәтергә кереп кала.

Бу өлешне укып, Җәлилнең үлем карарына җавап итеп нинди шигырьләрен язганын да чамаларга була. Р. Харис *шигырендәге «катыйль», «үлемгә ышанмыйм», «кансыз палач», «илгә җырым кайтыр»* детальләре шуңа ишарә. «Гайнан Кормаш» бүлеге әлеге җәлилченең фашистлар тарафыннан ничек имгәтелүе турындагы юллардан башланып китә. Аның, бармакларын сындырып, оча сөякләрен чатнатсалар, Абдулла Алишны күзенә көчле ут юнәлтү белән җәзалыйлар. Шул рәвешле яктылыкка нәфрәт тудырмакчы булалар. Әмма шигырьдән алган яктылыкка зыян сала алмыйлар.

«Фоат Булатов» дип исемләнгән бүлектән дә күп инфор-

мация алырга була. Биредә дымлы камерада ялангач кешене, аяк-кулларына тимер богау кидереп, ач килеш салкын идәндә тоту турында сүз бара. Ә Әхмәт Симайны, ашатмыйча, азык исе белән җәзалау кулланыла. «*Мин егылган саен, минем өчен ыңгыраша иде таш идән», –* дип яза шагыйрь бу турыда. Җиденче бүлек Фоат Сәйфелмөлеков турында. Аның монологы сатлыкҗан булмас өчен көрәшүдән гыйбарәт.

Гариф Шабаев турындагы бүлек тә шундый рухта. Зиннәт Хәсәнов берөзлексез җырлату аша җәзалана. Тавышы беткәч, ул Ватан гимнын башкара. Ахыры үкенечле бетә: кыйналудан чәчләре кәфен төсенә керә. «Рәхим Саттар» исемле унынчы бүлек, җәлилчеләр турындагы дөреслекне сөйләр өчен, берсенең качып китүе турында бара. Әмма ул сазлыкка барып чыга, яралана, кулы хәнҗәр тота алмагач, үзе теләп сазлыкка батып үлә. Абдулла Батталов монологы үзенең сатлыкҗанны таный алмавы өчен үкенүе турында. Әхәт Атнашев, үләр алдыннан туган ягын, утыртып киткән өянкесен, әнисен сагына. Әмма бу сагыну богау бауларын өзәргә генә ярдәм итми. Унөченче бүлек Сәлим Бохараев турында. Ул җәлилчеләрнең үлем каршындагы халәтен *«трагик моңлы бер дастан»* дип атый. Соңгы ундүртенче бүлектә керештәге сүзләр кабатлана. *«Ватан өчен яшәү – безнең бурыч!»* чакыруы өстенлек ала.

Шулай итеп, «Җәлилчеләр» циклы башы гильотинада чабылган батырлар турында. Һәр монологтан патриотик пафос бөркелеп тора. Гомумән, чит илгә «качарга» җыенган кешеләргә укып чыгарга тәкъдим итәрлек материал бу.

Шагыйрь 2006 елның август аенда «Җәлил каны турында сонет» яза [Харисов, 2011, б. 197]. Сонет ул – 14 шигъри юлдан торган катлаулы строфалы шигырь формасы. Ул дүртәр юллык ике строфадан («катрен»), өчәр юллык тагын ике строфадан (терцет) төзелә. Мондый формалы әсәрнең рифма системасы үзгә була [Әдәбият, 2007, б. 177]. Жанр таләпләре буенча һәр строфа үзенә генә хас мотивны чагылдырырга тиеш.

Бу яктан караганда беренче строфа һәр елның егерме бишенче августында (җәлилчеләрне җәзалаган көн) шагыйрь аңында кабынган хис турында булса, икенче строфа – капма-каршы – 1906 елның 15 февраленә багышлана, бу көндә үткәрелеп килә торган төрле чаралар Муса Җәлил һәйкәле янына килү белән бәйләнә, өченче строфада *«батырлыкта – матурлык»* афористик фикере үткәрелә, ә дүртенчесендә шагыйрьнең олы гражданлык хисе чагыла: *«Яшим үз халкымның күзен үбеп!»*

Шагыйрьнең 105 еллыгына Р. Харис иҗатында «Бакый Урманче ташлары» исемле цикл пәйда була [Харисов, 2011, б. 164–181]. Әлеге цикл 17 «таш»ны берләштерә. Биредә мәшһүр сынчы ясаган скульптуралар турында сүз бара. Шуларның берсе – Муса Җәлил. Шигырьнең эчтәлеге авторның эчке монологында чагыла. Җәлил ташына карап, автор уйга кала, күңеленә әгәр «Моабит дәфтәрләре» илгә кайтмаган булса,

татар шагыйре мәрмәр яки бронзага әверелә алыр идеме, дигән уй кила. Үзе соравыннан куркып та куя: «утлы сорау» дип яза ул. Беләбез: әлеге утлы сорауның нәрсәгә китергәнен. Нәтиҗәдә, дәфтәрләр илгә кайтмаса да, М. Җәлил кебек бөек йолдыз югалмас иде, архивлар актарылыр, тарих тузаннары кагылыр иде дигән фикергә киленә.

Йомгакны Р. Харисның үз сүзләре белән чыгару дөрес булыр. Аның «Реформалар сонеты»нда мондый юллар бар: *«Реформалар канын сөртә-сөртә, ничә буын инде кериләнде»* [Харисов, 2011, б. 184].

Җәлил – ул чыннан да «татарлык тамгасы». Аның турында бары тик дөреслекне генә язарга мөмкин. Бу шәхес исеменә ниндидер яла ягу, уйдырмалар чыгару безнең халык файдасына түгел. Архивлардан яңа материаллар да табыла тора, аларга нигезләнгән әсәрләр дә язылыр дип ышанасы килә.

**Әдәбият**


Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / төз-авт. Д.Ф.Заһидуллина һ.б. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

*Баттал Ф.* Хакыйкать кадерлерәк // Мирас. 2009. №9. Б. 29–41.

*Бәдертдинова Л.Ш.* Гази Кашшафның әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми эшчәнлеге: монография. Казан, 2014. 216 б.

*Гайнетдин М.* Хакыйкать юлыннан: әдәби тәнкыйть. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 319 б.

*Галиев Ш.* Сайланма әсәрләр. 5 томда. 2 т.: Юмор, сатира, хатирәләр. Казан: Татар. кит. нәшр, 2002. 496 б.

*Гыйлаҗев И.* Каһарманмы, хаинмы? // Ватаным Татарстан. 2009. 16 гыйнвар.

*Морат Газинур.* Бөекләргә таянабыз // Төнге әверелеш: Шигырьләр, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 399 б.

*Сәхапов М., Яһүдин Э.* «Барбаросс» инкыйразы // Мирас. 2009. № 6, 7.

*Харисов Р.М.* Сандугачлар тынган вакыт: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 527 б.

*Харисов Р.М.* Сайланма әсәрләр. 7 томда. 3 т. / төз. һәм кереш сүз авт. Ф.Ф. Хәсәнова. – Казан: ТКН, 2006. – 511 б.

*Харисов Р.М.* Сайланма әсәрләр. 7 томда. IV т. / төз. һәм кереш сүз авт. Ф.Ф.Хәсәнова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

*Харисов Р.М.* Хәл-әхвәл: Шигырьләр, поэмалар һәм җырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 2208 б.

Харис Р.М. Певчая ночь: стихотворения и поэмы / пер. с татар. Н. Переяслова. М.: Вече, 2011. 240 с.

*Хасанова Ф.Ф.* Посвящения чувашским поэтам в современной татарской литературе = DEDICATION TO CHUVASH POETS IN THE MODERN TATAR LITERATURE // Вестник Чувашского университета. Серия «Гуманитарные науки». 2009. № 3. С. 336–340.

*Хәсәнова Ф.Ф.* Заман һәм шагыйрь: монография. Казан: Изд-во МО и Н РТ, 2010. 298 б.

Юзеев И. Сайланма әсәрләр. 5 томда. III т.: Шигырьләр, хикәяләр, сәхнә әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 592 б.



***Хәсәнова Фәридә Фирдәвес кызы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге җитәкчесе*
*e-mail: farida.5656@mail.ru*

УДК 821.512.145

***Р.Ф. Харрасова***

# ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНЫҢ АКАДЕМИК БАСМАСЫНА КУЕЛГАН ТАЛӘПЛӘР

В статье сделаан попытка осмысления подготовки «Истории татарской литературы в 8 томах» в плане успешного использования опыта предыдущих поколений и вписания татарской литературы в контекст развития литератур тюркских народов и общемирового литературного процесса.

**Ключевые слова:** татарская литература; академическое издание; требования, предъявляемые к академическим изданиям.

Академик басма төшенчәсе белән, гадәттә, әдәби әсәрләрнең фәнни институт галимнәре тарафыннан текстологик планда эшләнгән күптомлыкларын атыйлар. Зур коллективның гыйльми эзләнүләре, эшчәнлеге нәтиҗәсендә туган барлык китапларны, шул исәптән әдәбият тарихларын да әлеге термин белән атап йөртү традициясе бар. Дәүләт оешмалары планына кертелеп, басылып чыккан андый капиталь хезмәтләргә куелган таләпләр шактый югары, һәм алар теге яки бу проблемаларны чишү рәвешен ала.

Татар әдәбияты тарихының яңартылган академик басмасын төзү идеясе инде Үзгәртеп кору елларына кадәр үк галимнәр арасында таралган иде. Шул заманның икътисади һәм башка мөмкинлекләреннән чыгып, алтынчы томны бастыру белән канәгатьләнделәр һәм аны чыгаруны перспективага калдырдылар. Академик басмаларга керү әдип өчен мәртәбә булган кебек, гасырларга калачак күптомлыкларны эшләү дә мәртәбә, һәм аңа хокук галимнәрнең күпьеллык фәнни эзләнүләре, шул эзләнүләр юлында ирешкән уңышлары, язу осталыгы белән алына. Академик хезмәтләрне башкарып чыкканда, аларның бездән соң да калганын һәм актив кулланышта йөриячәген онытмаска кирәк.

Каләм иясенең күптомлыкларын әзерләүгә аның инде басылып чыккан аерым китапларындагы җитешсезлекләрне барлау һәм төзәтү аша килгән кебек, милли әдәбиятның гомумтарихын язу да шул тарихның аерым чорларын һәр яктан җентекле тасвирлау аша тормышка ашырыла. Кызганыч, бу эш бездә өлешчә генә башкарылган. Танылган галимнәр тарафыннан әдәби берәмлекләрне – әдәбият тарихындагы мөһим әсәрләрне, үзенчәлекле иҗатларны, сүз сәнгатенең гомуми барышын, һәр күренешен күпсанлы монографияләрдә чагылдырып, әлеге монографияләргә апробацияләр уздырып, тиешле урыннарын үзгәрткәч, гомуми нәтиҗәләрен үз эченә алган мәкаләләрне әзерләнеп ятучы

томлыкларга кертү бер идеал булып кала.

Билгеле, тәүге томнары халыкка ирешкән әдәбият тарихына А. Әхмәдуллинның драматургия барышын чагылдырган хезмәтләре, И. Нуруллин, М. Гайнуллин, Г. Халит һәм башкаларның дәреслек-кулланмалары, китаплары билгеле бер дәрәҗәдә таяныч булып тора. Алай да теге яки бу чорны чагылдырган альтернатив тарихларның юклыгы, югары уку йортлары өчен элек чыгарылган дәреслекләрнең заманга ярашлы яңартылмавы, әлеге дәреслекләрнең татар әдәбияты тарихының бөтен этапларын тирән һәм тулы чагылдырмавы, татар язучыларының иҗатына багышланган китапларның азлыгы коллективыбыз алдында торган бурычларны чишүдә зур кыенлыклар тудыра.

Беләбез ки, академик басмалар башка төр хезмәтләрдән фәнни тирәнрәк, тулырак һәм шул ук вакытта җыенкырак та булырга тиеш, шулай икән, ул буш урында барлыкка килә алмый. Академик басмаларда алар әзерләнгән вакытта фәннең торышы, иҗтимагый-сәяси фикернең эчтәлеге мөһим роль уйный. Без аны, икенче төрле, чор галимнәренең зурлыгы, сүз ирege, идеологик-сәяси кысалар һ.б. дип шәрехли алыр идек. Әгәр басмачылык эше иҗтимагый-сәяси шартларга, фән үсешенә шул дәрәҗәдә бәйле икән, академик планда башкарылган күптомлыкларны да мәңгелек басма дип карарга кирәкми. Аларның озак еллар дәвамында укучыларга, укытучыларга, яшь галимнәргә фәнни таяныч була алуы мөһим. Кызганыч ки, фәнебез һәм әдәбиятыбыз үсештә, дип, гел мактана килсәк тә, икемеңенче елларга килеп кергәч, һәр икесе эчке кризис кичерә башлады, һәм аның нәтиҗәсе озакламый үзен тагын да ныграк сиздерер дип уйларга кирәк. Менә шушы шартларда күптомлыкларны әлегә татар фәнен тотып торган галимнәребез тарафыннан мөмкин кадәр тизрәк әзерләп бетерү мөһим.

«Татар әдәбияты тарихы» язылу дәвамында бик күп галимнәр бу эшкә үзеннән өлеш керткән, аларның кайберләре арабызда юк инде. Бу, үз чиратында, кайбер мәкаләләрдәге аерым карашларга авторлык хокукы һәм яңа фәнни фикер арасындагы каршылыклар проблемасын китереп тудыра. Хезмәт коллектив башкарылса да, авторлык хокукын исәпкә алмау мөмкин түгел. Теге яки бу галим уздырган карашлар коллективныкы белән тәңгәл килмәгәндә, каршы фикерләр кереш һәм йомгакларда, жанр турындагы язмаларда әдәп кысаларында гына, мәсьәләгә фәнни җәмәгатьчелек мөнәсәбәте рәвешендә генә яктыртыла.

Милли әдәбиятлар тарихы теге яки бу регионның Рәсәй, дөнья халыклары мәдәнияте эчендә тоткан урынын күрсәтүгә хезмәт итә. Ул – милләтне, аның фикерләү рәвешен, зыялыларының аерым чорларда алга куйган максат-бурычларын, дөньяны күзаллауларын, каләм ияләренең фәлсәфи-эстетик карашларын башкаларга да таныта. Академик басманы әзерләүчеләр эш нәтиҗәләрен башка милләтләр дә кул-

ланачагын белеп хәрәкәт итәргә тиеш. Кыскасы, әдәбиятның теге яки бу чорын тасвирлаганда, аны өлешчә Идел–Урал, Рәсәй, төрки халыклар сүз сәнгате контекстында да карарга кирәк.

Теләсә кайсы академик басма мәгърифәт таратуны һәм иҗтимагый-сәяси бурычларны күз уңында тотып башкарыла. Шунлыктан фәнни редакторлар да, басманы чыгаруга җаваплылары да, корректорлар да үз алларына анда хаталарны калдырмау яисә, һич югы, минималь итү максатын куеп эш йөртергә бурычлы.

Институтыбыз хезмәткәрләре сигезтомлыкны әзерләү барышында бик күп проблемаларны чиштеләр һәм әле дә чишәләр. Бердән, академик басмаларда әдәбият бер бөтен берәмлек һәм аның барышы өзлексез дип карала. Бу мәсьәләне соңгы күптомлык ахыргача хәл итте дип уйлыйк. Шул ук вакытта авторларыбыздан классик һәм классик булмаган сәнгать системаларының үзара тәэсирен ачу, әдәбиятыбызда ныгыган төп иҗат юнәлешләренә һәм әдәби методларга махсус игътибар, әдәбият тарихындагы авангардлык хәрәкәтләрен объектив бәяләү, алар таянган теорияләр һәм бу теорияләрнең гамәлдә чагылышы турында фәнни фикер йөртү сорала.

Гадәттә, әдәбият тарихлары буенча академик басмалар проблемалы-монографик принципка нигезләнә. Анда иң элек томга Кереш, чорның иҗтимагый-мәдәни хәл-торышы, шул этапта төр, жанр үсешләрен чагылдырган мәкаләләр урын ала. Без укучыга тәкъдим иткән хезмәт тә шул принципларда төзелде. Иҗаты яктыртылачак язучыларны, тирәнтенрәк анализланачак нәфис текстларны сайлаганда югары уку йортларының, мәктәпләрнең уку-укыту программалары да исәпкә алынырга тиеш. Димәк, академик басмаларны төзүче коллективларга, аның өчен җаваплы редколлегиягә югары уку йортларының галимнәре кертелү – мәҗбүрияттер.

Беләбез ки: әдәбият тарихлары, еш кына, дәреслек ролен дә үти. Шулай икән, ул башка төр фәнни басмаларга куелган таләпләрдән бераз читкәрәк тә китә. Дөрес, хезмәтнең дәреслек сыйфатларын да кайгыртып, галимнәр югары фәннең дәрәҗәсен төшерергә тиеш түгелләр. Икенче төрле әйткәндә, академик басмада урын алган мәкаләләр теманы субъективлыкка-фаразларга да урын калган, төп игътибар лектор зәвыгы белән генә сайланган текстларга юнәлтелгән лекцияләр кысасында гына чагылдырыла алмый.

Дәреслек сыйфатламалары дигәндә, аңа авторларның һәркем өчен ачык аңлаешлы, саф милли телдә язуы да кирә. Стильләре, кайчак хәтта фикерләре дә төрле авторларның язганнары бер сулышта укылырга, теге яки бу мәкалә белән танышканда укучы төртелеп калмаска тиеш. Язмаларның зур аудиториягә адреслануы мәгълүматны ачык җиткергән комментарийларга ихтыяҗ тудыра. Комментарийлар галимнәр тарафыннан әзерләнсә дә, күптомлыкның нәшрият хезмәткәрләре тарафыннан чыгарылуы институттан билгеләнгән редакторга

җаваплылыкны бермә-бер йөкли. Аннан әдәбиятның барлык чорлары буенча мәгълүматлылык, кеше хатасын күрерлек белем таләп ителә.

Әдәбият тарихының академик басмасын томнарга бүлүнең принциплары гади, ул әдәбиятның үз этаплары белән билгеләнә. Ә менә бу бүленешне хәл итү, еш кына, проблема дәрәҗәсендә торып баса. Рус галимнәре, әдәбиятыбыз ачык кануннарга гына нигезләнеп үсмәгән, анда теге яки бу методларның, стильләрнең алмашынуы тигез генә бармаган, алар, гадәттә, янәшә дә яшәгән, шунлыктан әдәбият тарихларын этапларга бүлү бик кыен, диләр. Татар әдәбияты тарихын да методларның эзлекле алмашынуы рәвешендәге умырткага гына утыртып булмый.

Рус галимнәре әдәбият тарихларын язганда новаторлык номинацияләре артыннан кумаска, әдәбиятларны теге яки бу әдәбиятлар дәрәҗәсенә көчләп тартмаска, һәркайда зур Яңарышлар эзләмәскә киңәш итә. Мондый куркынычлар бүгенге көндә татар галимнәрен аеруча нык сагалый. Академик басмаларның дөньяга килүе милләтнең рухи-матди алгарышы белән билгеләнә. Әдәби барыш та халыкның иҗтимагый-сәяси хәленә, менталитетына, нәфис текстларга, укучы зәвыгына һәм башка бик күп нәрсәләргә бәйле. Аны һәрвакытта да икенче бер халыкныкына тиңләү омтылышы, бәясен арттырудан битәр, төшерүгә китерә. Килешергә кирәк: академик басма комплиментар хезмәт булудан битәр, тирән фәнни анализга корылган күптомлык булырга тиеш.

1941–1956 елларда рус әдәбияты тарихының унтомлыгы чыгу уңаеннан язылган мәкаләсендә Константин Исупов фәндә хәтта экспериментлар рәвешендә башкарылган альтерантив тарихлар булмауга кайгыра. Ул, «әдәби генералитет» яңадан каралуга мохтаҗ, ди. Бу адымга баручыларны исә зәвыксызлыкта һәм үткәнгә ревизия ясауда гаепләячәкләр дип белдерә [Исупов]. Әдәбият тарихына кертү өчен язучылар сайлау проблемасы бездә бервакытта да хәл ителмәячәк. Теге яки бу яңа исемне фәнни елъязмаларга кертү, моңарчы макталганнарны, исемнәр алганнарны төшереп калдыру гасыр дәвамында газета-китап язганга, өстәгеләр сөйләгәнгә табынган җәмәгатьчелектә зур резонанс тудырачак. Әзерләнүче күптомлыкка яңа исемнәр шактый кертелсә дә, бу катлаулы мәсьәлә безнең тарафтан гына ахыргача чишелер дип уйламыйм. Шул ук вакытта, намуслы галимне рангларга баш ию борчырга һәм ул авторлар приоритетын иң-иң дигәннәргә бирүне кайгыртырга тиеш.

Әлбәттә, бер генә әдәбият тарихы да барлык талантлы каләм ияләрен үзенә «сыендырып» бетермәячәк. Минем уемча, бу проблеманы күп томлыкларның санын арттыру, «тарих»ны ачык система итеп калдыру аша чишәргә мөмкин. Ул чагында бүген әдәбиятка армый-талмый хезмәт итеп тә, «генералитет» эчендә булмаганга, дәреслекләргә һәм әдәбият тарихларына керми кал-

ганнар хакында киләчәк томнарда язу мөмкин булачак.

Әдәбият елъязмасын башкарып чыкканда, бик күп яңа әсәрләр актив кулланышка кереп китә яисә кереп китә ала. Кызганыч ки, узгандагы чорларны тулы чагылдыру өчен, текстлар җитми. Галим теге яки бу әсәр хакында тәфсилле анализлый калса да, укучы аны табып укый алмаячак. Еш кына авторларыбыз үзләре дә узгандагы мирас белән башкаларның хезмәте аша гына таныш. Каләм иясләребезнең архивларда югалган һәм үзләре тарафыннан юк ителгән әсәрләре, һаман да кулъязма хәлендә яшәгән күпсанлы әдәбият чорларны тулы чагылдырырга, соң дәрәҗәдә объектив булырга мөмкинлек бирми. Икенче яктан, әдәбият тарихын язуга система җимерелгәч тотынсак та, ул барыбер идеологик һәм бюрократик диктаттан тулысынча азат түгел. Бу бөтен халыкларда да шулай. Татар язучыларының барлык мирасы халыкка бүгенге графикада тулысынча кайтарылмаганга да, әдәбият тарихыбызны язуда соң сүз була алмый.

Кыскасы, Татар әдәбияты тарихының академик басмасының нинди булуы чор-җәмгыять тудырган рухи-матди шартларга дә, татар фәненең үсешенә дә, шул үсеш биеклегеннән торып мәкаләләр язарлык галимнәрне бергә туплый алуга да һәм басмага карата дөрес таләпләр куеп, шуларның үтәлешен тәэмин итүгә дә барып тоташа.

**Әдәбият**

*Исупов Константин.* Оглянись на дом свой, или история литературы как исповедь духа // Вопросы литературы. 1997. № 2.

***Харрасова Рифә Фәтхерахман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Ә.М. Шәрипов***

# МӘҢГЕЛЕККӘ ТАУЛАР БЕЛӘН КАЛАМЫН...
## (Әдхәт Синугылның тууына 80 ел)

В статье освещаются жизнь и творчество поэта и общественного деятеля Адхата Макаримовича Синегулова (Адхата Синугыла), внесшего весомый вклад в развитие татарской поэзии 2-й половины XX века; в частности, рассматриваются вопросы тематического диапазона и поэтики его произведений.

**Ключевые слова**: татарская литература, переводческая деятельность, классики мировой литературы, тематика, лирика, поэтика.

Әдхәт Синугыл үз гомерендә шактый катлаулы һәм сикәлтәле юл үтә. Аның тормышы вакыйгаларга да бай, эшләгән вазифалары да күптөрле була. Кыскача гына аның тормыш юлына тукталып китик.

Әдхәт Мәкәрим улы Синегулов (Әдхәт Синугыл – аның әдәби псевдонимы) 1935 елның 15 мартында Башкортстанның Стәрлебаш районы Куганак-Баш авылында эшче гаиләсендә туа. Бер яшьтә чакта ук ул ятим кала: әнисе вафат була. Әтисе Мәкәрим, үз кулындагы өч баланы аякка бастыру өчен, Стәрлетамак районындагы заводка кара эшче булып урнаша. 1941 елда әтисе дә фронтка китә, 6 яшьлек Әдхәт башта туган авылындагы бабасында яши, аннары Стәрлебаш район үзәгендәге балалар йортында тәрбияләнә. Шундагы унъеллык татар мәктәбендә укый. Аны тәмамлагач, армиягә алына һәм Ерак Көнчыгыштагы хәрби парашютчылар частенда хезмәт итә. Нәкъ менә армиядән кайткач, янып торган, әмма киңәшер кешесе, таянып торырлык урыны булмаган 21 яшьлек егетнең тормышта үз урынын табу өчен көрәше башлана. Кайларда гына яшәми дә, нинди генә вазифаларда хезмәт итми ул! «Кая гына бармый, ниләр күрми, Ир-егеткәй белән ат башы» дип, нәкъ менә Әдхәт Синугыл кебек катлаулы тормыш юлы үткән кешеләргә карата әйтә торганнардыр. 1956–1958 елларда ул Стәрлебаш район комсомол комитетында инструктор, аннан тирә-як авыл мәктәпләрендә башлангыч сыйныфлар укытучысы, Түбән Шәкер мәктәбендә мөдир, Васильевка авылында китапханәче, Миякә район газетасында тәрҗемәче булып эшли. 1959 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1964 елда университетны тәмамлагач, Сарман районының Иске Минзәләбаш авыл мәктәбендә тарих, татар теле һәм әдәбиятын укыта. Аннан Казанга күчеп килә, Биектау район газе-

тасында тәрҗемәче, район радиотапшырулары мөхәррире булып эшли. 1967–1970 елларда ул Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, ә 1971–1977 елларда Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә Әдәбият бүлеге мөдире вазифасын башкара. 1977–1997 елларда Ә. Синугыл Ташкент шәһәрендә яши. Шагыйрь иҗатын тирәнтен өйрәнгән, Казан университетында аның белән бер группада укыган галим Хатип Миңнегулов күрсәтүенчә, Әдхәтнең Казаннан Ташкентка күчеп китүе аның гаилә хәле белән бәйле була: Әдхәт Кырымнан Урта Азиягә депортацияләнгән күренекле Кырым татары әдибе Шамил Аляддинның кызы Ләйләгә өйләнә һәм Ташкентта яши башлый. Ул анда Үзбәкстан дәүләт кинематографиясендә фәнни-популяр һәм документаль фильмнар буенча өлкән мөхәррир, аннары Бохара, Кашкадәрья һәм Сурхандәрья өлкәләрендә Бөтендөнья Автор Хокукларын (ВААП) саклау буенча Үзбәкстан бүлегенең вәкаләтле вәкиле, аннары «Йолдыз» исемле иҗтимагый-әдәби журналның техник мөхәррире вазифаларын башкара. 1983–1985 елларда Әдхәт Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда укый. Аннан Казанга кайтып, 1992–1993 елларда «Шәһри Казан» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. Аннары «Ватаным Татарстан» газетасы белән «Татар-Информ»ның Үзбәкстан буенча үзхәбәрчесе вазифасында хезмәт куя, бер үк вакытта Үзәк Азиядәге БДБ илләре буенча Мюнхен шәһәрендә урнашкан «Либерти» («Азатлык») радиостанциясенең Ташкенттагы үзхәбәрчесе булып эшли. 1990 елларның урталарыннан алып, Әдхәт Кырымда, Симферополь шәһәрендә яши. Андагы татар диаспорасы белән тыгыз элемтә урнаштыра: Ялта шәһәрендә төрки милләт балаларының халыкара фестивальләрен үткәрүдә якыннан катнаша, алар өчен «Сөембикә варислары» дигән җыр тексты яза. 2000–2001 уку елларында Гарәп әмирлекләренең Донецк шәһәрендәге Ибне Фадлан исемендәге Украина ислам университетында татар теле һәм әдәбиятын укыта. Аның вафаты да бөтенләй уйламаганда гына була: 2004 елның 14 гыйварында, Казанга иҗат эшләре белән килгәч, Язучылар берлеге бинасында кинәт йөрәге туктап вафат була.

Әдхәт Синугыл күпкырлы, киң планлы эшчәнлек алып барган шәхес. Ул – шагыйрь, дә, җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче, журналист, мөгаллим дә булды. Һәр өлкәдә шактый саллы һәм игелекле эшләр эшләп калдырды.

Әдәби эшчәнлеген ул тәрҗемәче булып башлап җибәрә. 1967 елда Әдхәт Африка континенты шагыйрьләре әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп, аларны «Давыллы Африка» дигән җыентыкка туплап, аңа соңгы сүз язып бастырып чыгара. Тагын бер елдан соң, Л. Антонов белән берлектә, гарәп язучысы Латифа әз-Заятның романнарын тәрҗемә итеп, «Ачык ишек» дигән 316 битле китап нәшер итә. Тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеген ул киң диапазон белән алып бара: күп

төрки телләрне өйрәнә, еллар дәвамында үзенең белемен камилләштерә бара, төрки телләр белгече булып таныла. XI гасыр төрки шагыйре Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» поэмасы, поляк шагыйре Адам Мицкевичның «Кырым сонетлары», Көнчыгышның атаклы философы һәм шагыйре Әбугали бине Синаның зур күләмле «Тыйб рисаләләре» дастаны, «Венгр әдәбияты җәүһәрләре» антологиясе, «Эллада кызы» кебек коллектив шигырь җыентыкларындагы Ә. Синугыл тәрҗемәләгән поэтик әсәрләр укучыларны үзләренең камил эшләнгән булулары белән җәлеп итәләр. 1972 елда Вьетнам язучылары хикәяләренең тәрҗемәләрен «Пальмалар шавы» исеме белән аерым китап итеп бастырып чыгара. Кайбер әсәрләрен кырым татар теленә тәрҗемәләп, балаларга шул телдә «Яшьлек һәйкәле», «Каракаш», «Миләүшә» исемле китапларын бүләк итә. Аның балалар өчен башкорт телендә бастырган «Урал кунагы» дигән китабы да бар. Бу хезмәтләр Ә. Синугылның киң эрудицияле шәхес һәм тырыш иҗат кешесе булганлыгын күрсәтеп торалар, татар халкы белән Көнчыгыш һәм Көнбатыш халыклары һәм аларның мәдәниятләре арасына үзенчәлекле күпер ролен үтиләр.

Шуның белән бергә Әдхәт Синугыл талантлы, киң планлы, милләтпәрвәр шагыйрь булып та танылды. Аның поэзиясе – үзе зур бер дөнья. Аның шигърияте һәм шигырь китаплары турында үз чорында татар, үзбәк, рус телләрендә егермегә якын мәкалә-рецензияләр басылып чыккан. Алар арасында галим Х. Миңнегуловның «Мәхәббәт һәм нәфрәт шагыйре» исемле хезмәте үзенең тирән мәгънәсе белән аерылып тора. Әмма шулай да Ә. Синугыл исеме соңгы елларда сирәк телгә алына әле. Аның поэзиясе әдәбият белемендә әлегә үзенең тиешле бәясен алып җиткермәде, хәтта аның кабатланмас киң колачлы иҗаты беркадәр онытылыбрак та бара шикелле.

Минем кулда аның 1984 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Җыр төбәген сагынып» дигән шигырьләр җыентыгы. Шушы китаптагы әсәрләрдән генә дә аның киң диапазонлы, киң планлы шагыйрь икәнлеген сиземләргә мөмкин. Китапның беренче битләреннән үк Ә. Синугылның тауларга гашыйк шагыйрь икәнлегенә инанасың. 1974 елның июнендә Стәрлетамак каласында иҗат иткән шигырендә ул үзенең тауларга булган чиксез мәхәббәтен сурәтли, тауларга мәдхия җырлый:

Таулар юкта
Җирдә мин гүя җирсез!
Таулар барда
Үзем таудай тоямын.
Таулар күрсәм,
Бөркет сыман йөрәгем,
Тауларыма
Карап туа җырларым –

дип белдерә.

Бу әсәрен ул:

Ут-ялкынсыз
Калса әгәр йөрәгем,
Янартаудан
Илһам алып янамын.
Таулар белән
Тауда туып-үстем мин,
Мәңгелеккә

Таулар белән каламын, –
дип тәмамлый.

Тауларга булган мәхәббәт аның бөтен иҗат юлы буенча сузыла, бу темага ул үзенең байтак әсәрләрен багышлый.

Тауга гашыйк шагыйрь үзенең тормышында да таулар кебек горур булып яшәде, вакланмады, әйтәсе килгән сүзен турыдан ярып әйтте. Аның бу сыйфаты 1977 елда замандашына адреслап язган «Хөкем итмә» дигән шигырендә болай чагылды:

Хөкем итмә, туры әйтсәм әгәр,
Һәм калдырсам синең хәтерне.
Эчкерсез җан гына әйтә туры,
Астыртынның теле мәкерле.

Аның шигырьләре ихлас гражданлык, туган иленә, туган халкына чиксез мәхәббәт белән сугарылган. 1975 елның мартында (Казанда яшәгән чор) язган «Якташларга сәлам» шигырендә ул:

Хатлар язсам, якташларым, сезгә
Казан белән башлыйм сүземне.
Мин – тауларда туган татар улы –
Монда килеп таптым үземне, –
ди.

Ә. Синугыл әсәрләренең бер өлеше Ташкентта һәм Кырымда яшәгән чорда язылган. «Көньякларда язлар җитте» дигән шигырьләр циклында шагыйрь үзенең Урта Азия табигате тәэсирендә туган хис-тойгыларын тасвирлый: «Чәчәкләр диңгезе», «Ташкент һәрвакыт Ташкент», «Чинар тамырлары», «Кыз куу» һ.б. әсәрләр. Әмма кайда гына яшәмәсен, күпме генә вакыт үтмәсен, ул үз туган халкы – татар халкының патриоты булып калды.

Ата-бабам туган туфракны мин
Алыштырмам һичберни белән.
Батырлары яуда дан казанган
Мин үлемсез Җәлил иленнән, –

ди ул 1982 елда, Ташкентта яшәгәндә язган бер шигырендә.

Еллар буе туган җиреннән аерылып яшәү, табигый ки, нечкә хисле шагыйрь күңелендә сагыну-сагыш хисләре тудыра. Ташкент һәм Кырым чорларында иҗат ителгән әсәрләренең байтагы сагыну һәм сагыш хисләре белән өретелгән. Мәсәлән. Ташкентта язылган «Карлы якларга» дигән шигырендә ул:

Сагынуларны хатка төреп салып,
Сәлам язган саен, дусларым,
Кар юлларын үбәр булам ятып
Туган якта калган кышларның! –
ди.

Ә. Синугыл гомере буена дөнья әдәбиятын, бөтендөнья поэзиясен өйрәнеп яши, кайбер шигырьләрен дөнья классикларына ияреп иҗат итә. «Җыр төбәген сагынып» китабында гына да аның Р. Гамзатов, Һ. Һейне, О. Сөләйманов, М. Светлов, Африка шагыйре Гауссу Диавара, Вьетнам шагыйре То Хыу, шулай ук Тукай һәм Дәрдемәнд әсәрләренә ияреп язган шигырьләре китерелә. Аннан соң, ул үзенең шигырьләре ахырына әлеге әсәрнең кайда һәм кайчан язылуын да теркәп барган. Бу аның иҗатын этаплап өйрәнергә мөмкинлек бирә. Анда күрсәтелгән торак пунктлар арасында Куганак-Баш авылы, Карачәй, Махачкала, Шаһтау, Стәрлетамак, Теберда-Домбай, Черкесск, Грозный, Гуниб авылы, Чатыр-Даг, Казан, Мәскәү, Ташкент, Владивосток, Арген, Уфа, Мамай Курган, Дурмен, Термез, Бохара, Күктүбә, Сухуми, Миякәбаш, Латыйп утары авылы исемнәре бар. Бу

исемлеккә карыйсың да: «Дөньяны да гизгән икән бу Әдхәт!» – дип сокланып куясың. Дөньяның күп төбәкләрендә булу, төрле милләт кешеләре белән аралашу аның рухи дөньясын баеткан, күз карашын киңәйткән, иҗатына масштаблылык биргән.

Бу урында мин кыскача гына үземнең Әдхәт Синугыл белән таныш-дус булуыма да тукталып китәм. Аның белән мин студент елларында ук танышып-аралашып яшәдем. Ул татар теле һәм әдәбияты бүлегендә бездән бер ел алда, хәзерге күренекле галим, профессор Хатип Миңнегуловлар белән бер группада укыды. Шул вакытта ук ул сәләтле шагыйрь булып танылды. Бер генә мисал: студентлар арасында аның, башка шигырьләре белән бергә, шаян тонда язылган «Менә, малай! (Буйдак җыры)» дигән шигыре популярлык казанды. Анда түбәндәге юллар бар иде:

Инде мәхәббәтем дә бар,
Икебез дә бигрәк пар.
Менә, малай, мин сиңа әйтим:
Сөймәсәң, сөясе килә...
Сөйсәң, өйләнәсе бар!

Студентлар бу шигырьгә көй чыгарып, үзара шаярышып, такмаклап йөрделәр. Студентлык чорыннан миндә әнә шундый җылы тәэсирләр калды. Университетны тәмамлаганнан соң да безнең бу танышлык-дуслык дәвам итте. 1986 елда ул миңа үзенең «Җыр төбәген сагынып» дигән китабына: «Әнвәр Шәрипләре! Ерак араларны якын итсен, күпер салсын ике арага «Җыр төбәген сагынып» язган китап. Автор – Әдхәт Синугыл. Ташкент. 12.08.86 ел» дигән сүзләр язып бүләк итте. Аннан соң, 1999 елның июль аенда Әдхәт Чаллыга, безгә кунакка килде. Чаллы педагогия институтында әле каникулга китеп өлгермәгән студентлар белән очрашу уздырдык. Шул очрашудан чыккач, пединститутның икенче бинасы алдында аның белән икәү фотога төштек. Ул Чаллыда өч көн кунак булды. Минем хәләл җефетем пешергән бәлешне «Егерме ел бәлеш ашаганым юк иде, сеңлем! Сиңа бик зур рәхмәт» дип мактап ашады. (Бу сүзләрдә аның еллар буе үз туган халкын сагынып яшәве чагыла.) Шул чакта ул үзенең миңа 1986 елда ук бүләк иткән китабына тагын: «R.S. Ошбу китап мөгаллифе Әнвәр сабакташны аның үз йортында күрешү бәхетенә малик булды. 11 июль 1999 елда, Чаллыда. Ә. Синугыл» дип тә язып калдырды. Бу китап миндә аның якты истәлеге булып саклана.

Әнә шундый үзенчәлекле шәхес һәм зур шагыйрь иде Әдхәт Синугыл. Аның иҗаты киләчәктә тирәнтен өйрәнелергә һәм әдәбият тарихында үзенең лаеклы урынын алырга тиеш.

***Шәрипов Әнвәр Мәгъдәнур улы,*** *филология фәннәре докторы,*
*Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр*
*һәм ресурслар институты профессоры*

УДК 821.512.145

***Л.Ш. Гарипова***

# ЯЗУЧЫ МӨХӘММӘТГАРИФ БУРНАШЕВ: тормыш юлы һәм иҗаты турында

В данной статье освещается жизненный путь и творчество М. Бурнашева, известного доселе только как детский писатель. Впервые публикуется отрывок из драматического произведения писателя «Мәрьямнең күрәчәге».

**Ключевые слова:** М. Бурнашев, жизнь и творчество, драма, жанр.

Мөхәммәтгариф Бурнашев – тормыш юлы, иҗаты татар әдәбиятында аз өйрәнелгән шәхесләрнең берсе. Ул, нигездә, балалар язучысы буларак кына искә алына.

Язучының чыгышы, нәселе турында мәгълүмат-истәлек бары Аллаһияр Беләшевнең «Әҗе авылы хакында» (1924) китабында гына теркәлеп калган: «Менә бу Әҗе авылының төзелүенә сәбәп булучы кеше Бурнашев фамилияле читтән килгән бер татар мирзасы икәнлеге мәгълүмдер.

Мәзкүр Бурнашев каян килүе хакында ике төрле риваять бар. Аның берсе Бурнашевны Алтын Урда дәүләтенең бетүе алдыннан үз отряды белән Азиядән килеп чыккан итеп күрсәтә. Ул бу урында тора торган мордвалар белән сугышып, аларны җиңгән дә үзе шунда утырып калган. Бурнашевның Азиядән килгән бер кеше булуына нисбәтән бу авыл да Әзи, русча Азеева дип аталган имеш. Бу Әзи дигән сүз, соңга таба бераз әдәбиләштерелеп, Әҗи дип йөртелә башлаган. Икенче риваятькә караганда, Бурнашев Казан ханлыгы кул астындагы Бурнаш авылыннан чыккан бер кеше икәнлеге беленә. Ул бервакыт Касыйм ханлыгы тарафыннан Ука суының уң ягындагы мишәр, мордва, рус авылларында наместник булып билгеләнгән. Аның Һаҗәр исемле бик акыллы вә булдыклы хатыны булып, безнең якка килгәч, бер бала калдырып үлгән икән.

Шуннан соң Бурнашев үзенә бурычлы булган бер мордвин сәүдәгәренең бик матур кызын мөселман диненә кертеп, үзенә хатынлыкка алган һәм аңардан тагын бер баласы булган имеш.

Худуй бабай Биришевның чукындырылудан куркып үз гаиләсе белән Үгрәүдән Әҗегә качып килүе Иван Грозный заманасында булганлыктан, Әҗенең башлап төзелүенә һәрхәлдә 350 еллардан да ким түгел дигән хөкемне бирергә мөмкин.

Әҗедәге хәзерге Бурнашевларга ерак баба булган Әлмөхәммәднең берсе – Рәҗәп, икенчесе Исәнгилде исемле ике баласы бар иде. Боларның һәр икесенең дә ир балалары булып, хәзерге полтара, пәрәй, шамрай, мортаза, гусар ыруглары вә башка шуларга кардәшлекләре булган Бурнашевлар, Рәҗәптән тәмәй, чик-

май, васиг, симай, бахти, сафиан, сусар, мәрҗи, сапук, хуҗа ыруглары вә башкалар Исәнгилдедән таралганнар.

Әҗенең эшлекле коммунистлары Ибраһим иптәш Бурнашев Әлмөхәммәдкә Исәнгилде аркылы түбәндәге рәвештә барып тоташа: Ибраһим, аның атасы Рәхмәтулла, аның атасы Әбүшахман, аның атасы Муса, аның атасы Исәнбай, аның атасы Буранбай, аның атасы Исәнгилде, аның атасы Әлмөхәммәд.

Хәзерге вакытта Мәскәүдә торучы вә татар балалары тормышыннан берничә рисалә язып нәшер иткән мөхәррир Гариф Бурнашевның нәселе дә Әлмөхәммәдкә Исәнгилде аркылы барып кушыладыр» [Беләшев, б. 3–5].

М. Бурнашевның тууы һәм вафаты турында төгәл мәгълүматлар булмаса да, 1924 елда әле аның исән һәм Мәскәүдә яшәве турында да шушы чыганак аркылы беләбез. Шулай ук язучының «Вакугат фи 1900 санә әлмилади» әсәре [Татар әдипләре..., б. 58] барлыгы, «Шура» журналында язышуы мәгълүм. Мәсәлән, Габдерәшит Ибраһимовның (1857–1944) язучының динифәлсәфи карашларына тәнкыйть мәкаләсе шушы журналның 1917 елгы 14 санында басыла.

Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондында авторның бер әсәре саклана. Бу – «Мәрьямнең күрәчәге» исемле драма. Ул 1902 елда Санкт-Петербург шәһәрендә (гарәп графикасында) басылган. Моны – Мөхәммәтгариф Бурнашевның драма жанрында үзен сынап каравы дип тә әйтергә мөмкин, чөнки әсәрнең композициясе катлаулы түгел. Беренче татар пьесаларына хас булганча, текстта прозадагы кебек хикәяләп күрсәтү, эш-хәрәкәтне авторның үзенең аңлатып бирүе мисалында төгәллекләр дә килеп керә, персонажларның эш-хәрәкәте җәелдерелми. Кайбер күренешләр автор тарафыннан хикәяләп кенә бирелә.

Драманың үзәгендә 17 яшьлек Мәрьям исемле кызның язмышы. Аны Вәлид исемле байга икенче хатынлыкка кияүгә бирәләр. Әлбәттә, бу эш кызның ризалыгыннан башка эшләнә. Әти-әнисенең кадерле бердәнбер кызлары булып үскән Мәрьямнең шушы көннән аянычлы язмышы башлана – ир өендә асрау булып яшәү, өлкән хатынның нахакка рәнҗетүләренә түзү, ахыр чиктә өйдән куылуы, фәкыйрь тормышта яшәп, фәхешханәгә килеп эләгүе, атыш вакытында һәлак булуы...

Әсәр, исеменнән аңлашылганча, татар хатын-кызы язмышы мәсьәләсенә багышланган. Әлбәттә, аның кешечә яшәү мөмкинлекләре җәмгыятьтәге сыйнфый мөнәсәбәтләр белән тыгыз бәйләнгән. Төрле-төрле катлаулардан булган кешеләрнең күңел байлыгын, эшләгән гамәлләрен, холыкларын әнә шул матди нигез билгели дә инде.

Шулай ук XX йөз башы татар җәмгыятендә милләтне алга җибәрү, моңа аң-белемне күтәрү юлы белән генә ирешү җәмәгатьчелекнең төп мәсьәләләреннән берсе иде. Гомумән, бу чор каләм ияләре, милләт алдында торган бурычларны әхлакны

үстерү, яхшырту ярдәмендә хәл итү мөмкин, дип исәплиләр. М. Бурнашев моны Галим образы аркылы бирә. Хосусан ул ачынып: «Татар халкы, хосусән, яшь байларымыз, җәбер-золымны нә икәнлекне белмиләр, исламият нә икәнлекне белмиләр, инсаният нә икәнлекне төшенмиләр, әдәбият нә икәнлекне күрмиләр. Шул наданлык сөрмәсе улан яшь надан байларымызның урынсыз яшь фөкарә кызларыны җәбер идүләре, нахак золым кылулары сәбәбеннән рисвай җиһан улып, кавемезе мәсхәрә, милләтемезе тәхкыйрь идеп йөриләр, – ди –... гаҗәп, кайусына кермә, һаман татар кызлары, бунча да татар кызлары. Бичаралар, фәхешханәдә, трактирда харап ула икән».

Г. Исхакый (1878–1954) үзенең «Өч хатын белән тормыш» әсәре турында: «Татар матбугатында хатыннар хакы өчен тартышучы беренче китап, күпхатынлылык мәсьәләсене тәнкыйть вә аннан көлү», – дигән иде. Әлеге әсәр дә шул җөмләдән. Күп хатын белән яшәү, азгынлык һәм миһербансызлык кебек тискәре күренешләргә каршы чыккан М. Бурнашев та: «Татарларда икешәр, дүртәр хатын алу бик шаигъ, надан кеше дүрт хатын арасында гадәләт илән хәрәкәт итүе кайда, хәтта бер хатыны илән әдәп тарикынча мәгыйшәт итә белмәве һәркемнең мәгълүмедер» – дип, Галим образы аркылы әйттерә.

Әлбәттә, әсәрнең тарихи әһәмияте – үз чорының актуаль мәсьәләләренең кайберләрен күтәреп чыгуында. Биредә әсәрдән бер өзек тәкъдим ителә:

«Өлкән зал, эче гаять зиннәтле – өстәлләр, столиклар, кәнәфиләр, кресло шикелле нәрсәләр, тәрәзә алдында гөлләр, стенада шамаилләр, бер яхшы шкаф, идәнгә яхшы келәмнәр җәелмеш, бүлмәнең уртасында өлкән стол, әйләнәсендә столиклар, түр ягында кәнәфи; өстәл өстендә чынаяклар корулы, бер тарелка илән ак нан, бер касәдә каймак, бер тарелкада җала икмәк куелган бал, варенье шикелле маддәләр һәм бар, самовар өстәлдә кайнап тора, башында кызыл чәйнек. Мәрьям исә өстендә клетчатый коричневый күлмәк өстендә күк камзул, башында ука калфак. Өстеннән кечкенә шәл капланмыш, мәзкүр кызыл чәйнекдән чынаякга чәй коеп, кәнәфидә бордовый күлмәкле, яшел камзуллы, калфак киеп, өстеннән кечкенә шәл ябынып утырган яше кырык биш чамалы бер хатын алдына куеп:

Зөһрә абыстай! Рәхим итеп ашап утырыгыз, башкасы юк, – дия.

Зөһрә: Яхшы, яхшы! Рәхмәт, – дип утыра. Зөһрә чынаяктагы чәйне бетергәч, янә чынаякны Мәрьям кулына биреп, – Байың илән килендәшең кайда киттеләр?

Мәрьям: Авылга, каен әткәләренә кунакка киттеләр, биш-алты көннән артык тормамыз дигәнләр иде, икенче җомга улды. Эчем пошып бетте.

Зөһрә: Ник шундый яхшы өйләрдә эчеңез поша, Аллаһыга шөкерана кыл! Без һәм мулла абзыең илән читтән куанып торамыз, Мәрьям бәхетле, кандай бай йиргә кияүгә китте, әле дә мулла

абзыең кайчан көлә дә, Мәрьямгә безне бик кенә сыйлау кирәк, бән сәбәпче улдым, Вәлид бай өйләнмәкче улгач мәслихәткә килгәндә Мәрьямне мактадым: укымыш, гадәтидә бик яхшы, абыстай да сабак биргән саен Мәрьямне мактый, тиңләре арасында укуга остарагы дип әйтә.

Мәрьям: Абыстай. Бер дә сыйларлык иш имәс, Хода күрсәтмәсен!

Зөһрә: Чамасы килендәш өстенә килгәнгә күңелегез разый имәс, бу заманда күбесе килендәш өстенә бара, бу көн мулла абзыеңызга Бикмөхәммәд бай мәслихәткә килгән өйләнмәкче улып.

Мәрьям: Алла! Ул Бикмөхәмәд байга ни кирәк? Хатыны улса Хәдичә апай күркәмлектә шәһәремездә беренче, баласы дисәң дүрт баласы бар! Кемне алмакчы ул икән?

Зөһрә: Үзеңезнең шәриңеңез Гарәтулла бай кызы Нәгыймәне дип әйткән, һәм бәндән сорашуга кушкан, ничек, гадәте яхшымы, төскә чибәрме дип.

Мәрьям: Ник бирсеннәр бай кызыны дүрт бала, килендәш өстенә.

Зөһрә: Алай әйтә күрмәңез, бу заманда бай кеше сораса, картына, яшенә, тәүфикына, инсаниятенә карау кайда? Дүрт бала түгел, егерме бала өстенә барырлар!

Мәрьям: И бичара Нәгыймә! Әгәр бирсәләр бик аяулы, күрсәңез, зинһар, Рабига апайга әйтегез, бирмәсеннәр иде, Хода күрсәтмәсен көндәш илән торуны, карт ир илән гомер уздыруны, бик кыен!!! Күрсәм үзем һәм Нәгыймәгә әйтер идем бармагыл дип. Абыстай, килен булып төшкәнемә дүрт ай булды, бер көн тыныч торганым юк, көндә килендәшем юк нәрсәләр, сылтау табып үземне хурлыйдыр, гаҗиз улдым, тел кайтарсам өенең тынычы киткәндәй күренә, кайтармасам – туганлы ишетмәгән сүзләр илән үземне әрлидер. Үзенә дә чамасы көндә мине яманлап, фәлән ул, төгән ул диеп әйтә, чөнки ул һәм юкбар нәрсә өчен яман сүзләр илән хурлыйдыр. И абыстай! *(бу сүзләрне әйткәндә Мәрьямнең тавышы калтырап, күзеннән яшьләре тама башлады)* Ач торып яман, начар өйдә ятуга разый улыр идем, шунча хурлык күреп, шундый сүзләр ишетеп торганчы *(күзен яулык илән басып яшьләрен сыпырды)*

Зөһрә: И балам, еглама, сабыр ит, борынгылардан калган сүз – сабыр төбе сары алтын, иншалла, ахыры хәерлегәдер.

Мәрьям: Бар, чыгар Аллаһының язганы, кай итим, егласам да шул, сабыр итсәм дә шул булган эш керде, кайтмас һич кешегә дә сөйләгәнем юк иде, сүз чыккач сезгә генә серемне әйттем, бәнем көнемне Аллаһы дошманга да күргәзмәсен *(шул сүзләр илә чәйләре тәмам улып фатиха соңында Зөһрә абыстай чыгып китәр)*.

Мәрьям: Ултыртышыр идеңез абыстай, *– дип артыннан озата чыгар, кайтып керүенчә өстәлдәге ашларны шкафка, бәгъзесене подноска куяр да ишектән:* Хәбибә! Кереп самоварны алып, чынаякларны себергел, *– дип кычкырыр, бу тавышка*

*ишектән урта буйлы, башына кызыл яулык, өстенә сары күлмәк, алдына кызыл алъяпкыч бәйләп, сәч толымнарына көмеш тәңкәләр асмыш бер хатын йөгереп керүдә*: Абыстай, бу көн Вәлид абый илән карт җиңгиләр килер, сөенче!

Мәрьям: Кем әйтде?

Хәбибә: Садыйк әйтде, ул бүген авылдан килде, аның алдынча әйтергә кушканлар бүген кайтамыз дип (*бу сүзләрне сөйләвенчә самоварны күтәреп чыгып китде. Мәрьям исә кулындагы яулык илән күзләрене басып, столга утырып еглый башлады)»*.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк, Мөхәммәтгариф Бурнашев яңарышны яклаучы алдынгы карашлы мәгърифәтче булып әдәбият мәйданына килгән. Аның тормыш юлы, иҗат эшчәнлеге чыганакларның җитәрлек булмавы сәбәпле әдәбиятта аз яктыртылган, алга таба эзләнүләрне дәвам иттерү сорала.

**Әдәбият**

*Ахметзянов М., Шарифуллина Ф.* Касимовские татары (по генеалогическим и этнографическим материалам) / Казань: Магариф, 2010. С. 60–64.

*Беләшев А.* Әҗе авылы хакында (гарәп шрифтендә) Казан, 1924. 30 б.

Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): библиографик сүзлек / төз. З. Рәмиев. Казан, 2005. 276 б.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / төз. С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 192–194.

***Гарипова Ләйлә Шамиль кызы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*Г.И. Каюмова*

# РИЗВАН ХӘМИД ДРАМАЛАРЫНДА КОНФЛИКТ ҺӘМ ХАРАКТЕРЛАР ГӘҮДӘЛӘНЕШЕ

В статье рассматриваются своеобразие конфликтов в драматургии Р. Хамида, особенности характеров персонажей, их многообразные проявления в разных ситуациях, во взаимоотношениях между людьми.

**Ключевые слова:** Ризван Хамид, драма, конфликт, характер, персонаж, суровость, идея.

Тормышчан характерлар иҗат итүгә, кеше шәхесенең эчке дөньясы үзенчәлекләрен ачуга, төрле сәбәпләр аркасында килеп чыккан катлаулы конфликтларны яктыртуга драматургиядә аеруча зур игътибар бирелә. Кеше пьесада драматик көрәштә, конфликтта ачыла. Үз чиратында конфликтны да эстетик билгеләнгән, эчке хәрәкәткә ия характерлардан башка күз алдына китереп булмый. Бу – конфликт һәм характерны бәйләнештә карарга кирәклеген күрсәтә. Димәк, конфликт һәм характерны, икесе ике категория булса да, «берсе икенчесеннән чыгарыла торган бербөтен» [Горбунова, с. 42] итеп карау зарури.

Р. Хәмид иҗаты көнүзәк проблемаларны кыю күтәрүе, берберсен кабатламый торган тормышчан, бербөтен характерлары һәм тирән драматизмга корылган конфликтлары ягыннан үзенчәлекле. Драматург әдәбият мәйданына узган гасырның 70 нче еллары ахырында килә. 1970–80 елларда язылган пьесаларның һәркайсында диярлек буыннар бәйләнеше, әхлакый эстафета, фән-техника казанышлары һәм социаль психология мәсьәләләре үзәккә куела. Р. Хәмид драмаларын, нигездә, «гаилә драмалары» дип атарга була. Вакыйгалар, еш кына бер гаилә тормышында бара. Әлеге гаилә әгъзаларының бер-берсенә, кешеләргә карата мөнәсәбәтләре күрсәтелә. Мондый драмаларда геройлар үзара туганлык мөнәсәбәтендә торалар. Алардагы эчке кичерешләр шуңа күрә дә тирән һәм тәэсирле. Гаилә әгъзалары, кешеләр арасындагы киеренке мөнәсәбәтләр илдә барган тарихи-иҗтимагый күренешләрне, үзгәрешләрне чагылдыра. Шул нигездә килеп чыккан характерлар бәрелеше драматизмны тәшкил итә. Кешеләрнең характер үзенчәлекләре, эчке драмалары, шәхси фаҗигаләре шул бәрелеш вакытында ачыла.

Р. Хәмид пьесалары тирән психологизм белән сугарылган. Ул персонажларның характер үзенчәлекләрен, рухи дөньяларын ачуга зур игътибар бирә. Аның геройлары характерларының ныклыгы, үзсүзле, принципиаль, максатчан, тырыш, түзем булулары белән аерылып тора.

Әдип иҗатында персонажлар холкына хас сыйфатларны үзәккә туплаучы үзенчәлекләрнең берсе – кырыслык. «Синең урыныңа кайттым» [Хәмид, 1991, б. 48–90 Цитаталар шушы чыганактан алына] пьесасында Хәбировлар характерының асылын билгеләүче сыйфат та нәкъ менә шул. Бу – гаилә әгъзаларының берберсенә, кешеләргә карата мөнәсәбәтләрендә, яшәү рәвешләрендә чагыла. Пьеса образларның тормышчанлыгы, әсәрнең үзенчәлеген билгеләүче Хәбировлар характерының тулы ачылуы белән игътибарга лаек.

Гаилә башлыгы Мәгънәви – тормышта күпне күргән, күпне кичергән тәҗрибәле аксакал карт. Ул – ялкынлы, кайнар йөрәкле, шул ук вакытта бераз басынкы, ләкин әлеге басынкылык артында Хәбировларга гына хас ихтыяр көче сизелеп торган зат. Тормыш мәктәбе үзе аны барысына да өйрәтә. Аның сөйләгән сүзләре акыллы, киңәшләре төпле, күңеле саф, намусы чиста. Шулай да, рәхимсез язмыш сындырып сынаганда, әйбәт кенә булып калып булмый. Бик күп яхшы сыйфатлар да, тискәреләре дә шактый ачыла бу очракта; тик иң әһәмиятлесе – нәкъ менә авыр вакытта яхшы сыйфатларга тугры кала алу, кеше булып кала белү.

Акыллы, түзем Мәгънәви Хәбиров кырыслыгының сәбәпләре нидә соң? Заманында алар буыны колхозга нигез сала. Бөек Ватан сугышы елларында фронтта да, тылда да сынатмый алар. Мәгънәви үзе бу елларда колхозга җитәкчелек итә. Әлеге авыр заманнарда сабыр һәм тыныч кына калып булмый. Гаделлек белән бергә, усаллык та, кырыслык та кирәк була. Катлаулы еллар, үзе дә күп нәрсәне аңлап җиткермәгән авыл халкы белән эшләү, көрәшү, аны тупасландыра. Шулай да ихтыяр көче нык булмаса, карашы дөреслеккә туры килмәсә, гадел, намуслы булмаса, ничә еллар халык белән эш итә алыр идемени Мәгънәви карт, тыңлата алыр идемени ул аларны?! Сүзе үтемле була өлкән Хәбировның. Кирәк вакытта ул кырыс та, сабыр да була белгән. Һәрвакыт уйлап эш иткән. Әле дә авылдашлары, дөреслек эзләп, гадел хөкем сорап, аның янына киләләр.

Халыкның уңай традицияләрен бозып кабул итү, аны шәхси теләкләргә яраклаштыру күренеше пьесада үзенчәлекле чагылыш таба. Мондый хәлне фаш итүдә автор шул ук халык традицияләренә мөнәсәбәткә таяна. Һәр ата-ананың үз баласын тәүфыйклы итеп күрәсе килә, киләчәктә аның үзенә терәк, таяныч булуын тели. Бала әти-әнисенең юанычы, горурлыгы булырга тиеш. Бу Мәгънәви картның оныгы Зәйтүнгә әйткән сүзләрендә дә ачык чагыла: «...Егет кеше икәнсең, эзеңнән таныsыннар. Әнә, Наил абыең баскан җирендә ут чыгара. Җидәү киттеләр институтка, берүзен укырга алдылар. ...Берәү булса, атасының җилкәсен кимереп ятар иде, ә ул без салган акчаны да кире җибәрде», – ди, улы белән горурланып. Мәгънәви карт сүзләрендә үк Наилдә Хәбировлар характерына хас кайбер сыйфатлар ачыла: үз көченә

ышанучан, тәвәккәл, белемгә омтылучан, зирәк, мөстәкыйль. Моның өстенә әле ул максатчан, үз дигәненә ирешүчән, ләкин кырыслык анда чиктән ашкан. Аның, институтны тәмамлагач, авылга кайтып, агроном булып эшләүче Илдус абыйсына «синең урыныңа кайттым» дип ярып салуы бернинди чикләргә дә сыймый. Бу инде – кырыслык кына түгел, кешелексезлек, каты бәгырьлелек.

Мәгънәви карт өчен иң мөһиме – намус пакьлеге, кешеләр алдында йөз аклыгы. Улы Наилнең, авылдашлары белән киңәшләшмичә, үзбелдеклеләнеп, башбаштакланып йөрүен аңлый да, аклый да алмый ул. Наил кешеләргә карата да, гаилә әгъзалары белән мөнәсәбәтендә дә бик кырыс; үзен генә яратучы, олылар фикерен, әти-әни сүзен санга сукмаучы игелексез бала булып чыга. Дуслык, намус, мәхәббәт кебек изге хисләр дә аңа ят сыман. Аз гына вакыт эчендә бик күпләрне рәнҗетергә өлгерә: ял паркы ясау турында сорап килгән картларны куып чыгара, атларны саклап калу нияте белән йөргән туганы Нигъмәтҗанны «эшсез» дип атый, авыру баласының хәлен белү өчен, өенә кайтып килгән склад мөдирен эшеннән куа, тупас сүзләр әйтеп, апасының күңелен яралый, әтисенә каты бәрелә. Бөтен кыяфәтеннән салкынлык бөркелеп тора аның. Хакимлеккә омтылучан Наилдә, барысы да ул дигәнчә генә булырга тиеш. Хатыны Зөһрә аңа «кешеләр өчен куркыныч кеше» булуын, «робот кебек йөрәксез кешеләрнең халык язмышы белән эш итәргә, җитәкче булып эшләргә хакы юклыгын» кистереп әйтә. Моның белән ул Хәбировлар характерындагы кырыслыкны фаш итә, аңа каршы чыга.

Наилнең кырыс характеры үз якыннарының, авыл кешеләренең карашлары, омтылышлары, хис-тойгылары белән каршылыкка очрый. Әсәрнең конфликтын да әлеге характерлар каршылыгы билгели. Шуның белән автор халыкның чын хезмәт традицияләрен хата карашларга каршы куя, матур гореф-гадәтләрнең сафлыгы өчен көрәшә. Әлеге драмада «Без – Хәбировлар» дип күкрәк кагучы таш йөрәкле агроном Наил туганнары һәм халык тарафыннан кискен кире кагыла.

Драматург иҗатында халык характерына ирешүнең үзенчәлекле юллары күзәтелә. Ул тормыш куелыгын бөтен катлаулылыгында бирә. Бай материал кайвакыт жанр чикләренә генә сыеп бетми кебек [Мухамедова]. Бу аның «Китәм инде» [Хәмид, 1987, б. 3–49. Цитаталар шушы чыганактан алына] пьесасында ачык чагылыш таба. Пьеса үзенең күпкырлы булуы, заманының актуаль мәсьәләләрен яктыртуы, әлеге тормыш шартларында кеше шәхесен төрле яклап, тирәнтен ачуы белән әһәмиятле, «лиризм белән явызлыкның үрелеп баруы ягыннан үзенчәлекле» [Илялова].

Әсәрдә вакыйгалар зур булмаган Аксаковка авылында яшәүче аерым кешеләр тормышына гына кагылган кебек тоелса да, асылда сүз әхлак, тормыш кыйммәтләре турында бара. Пьеса 1930 еллардан алып 1970–

80 еллардагы вакыйгаларны үз эченә ала. Авылда коллективлаштыру, колхозлаштыру процессы бара. Әлеге тарихи дәвердә тормыш каршылыклары, кешеләрнең бу каршылыклар белән көрәше күрсәтелә. Авырлыклар, кан, яшь түгү белән искене җимерү, яңаны төзү бара. Кешеләрнең язмышлары алар карамагына тапшырылган җитәкчеләр инициативасы белән хәл ителә. Җитәкчеләрнең бурычы – кешеләрне бәхетле киләчәккә алып бару, ә тарих тәгәрмәче кеше язмышларын рәхимсез рәвештә вата-җимерә хәрәкәт итә. Беркем һәм бернәрсә дә аның юлында киртә була алмый. Чынбарлыкның асылы шул чорда яшәгән кешеләрнең яшәү рәвеше, берберсенә мөнәсәбәтләре, дөньяга карашлары, социаль һәм иҗтимагый бәйләнешләре, рухи дөньялары аша ачыла.

Рәсми сәясәт җимеше буларак, «социалистик реализм» методы бөтен әдәбиятка юнәлеш биреп тора. Әмма бу тар теория бай һәм катлаулы яшәешне тулы итеп чагылдыруга комачау гына итә. Каршылыкларга карамастан, Р. Хәмид үзенең карашын кешенең эчке дөньясына юнәлдерә. Аның җирдәге, тормыштагы урынын эзли, сагышларын, моң-зарларын алга чыгара. Ул да, башка каләм әһелләре кебек, тар теория чиген атлап чыга, чын тормышны, халык тормышын иҗатының нигезе итеп ала. Замандашларын борчыган сорауларга җавап бирергә омтыла; төрле юллар, төрле алымнар эзли, аларны иҗатында уңышлы куллана. Әдип турыдан-туры геройларының күңел дөньяларына мөрәҗәгать итә, замана авырлыкларын аерым кешеләр мисалында ачып сала. «Социаль-әхлакый казанышларны үсеш һәм үзгәрештә күзаллап», драматург «буыннар эстафетасын заман проблемалары югарылыгына куя» [Татар..., 2001, б. 362]. Пьесада сүз, кайчандыр бик якын дуслар булып та, хәзер исә кан дошманнарына әверелгән ике гаилә турында бара. Элек тирә-якта дан тоткан, авылның горурлыгы саналган колхоз рәисе Нурәхмәт белән Инсафетдиннең дошманлыклары шактый күптәннән килә. Бу дошманлыкның сәбәбе шәхси аңлашылмаучанлыклар гына түгел, аның нигезендә тарихи-социаль сәбәпләр ята. Әлбәттә, әлеге искиткеч катлаулы елларда яңа җәмгыять төзүдә карашлары төрле булган ике нык, баш бирмәс шәхеснең дуслык җепләре өзелүе артык аптыраашта калдырмый. Чор таләпләре үзе үк моңа этәрә. Бу ике дусның уй-теләкләре изге була: бәхетле якты киләчәк төзү. Тик мәрхәмәтсез язмыш беркатлы теләк-омтылышлардан хәйләкәррәк булып чыга...

Пьесада яшьләр өлкәннәрнең үткәне һәм бүгенгесенә битараф кала алмый. Алар ике гаилә арасындагы электән килгән дошманлыкның сәбәпләрен ачыкларга, булып узган вакыйгаларга дөрес күзлектән карап, дөрес бәя бирергә, тарихи сәбәпләрне ачыкларга омтыла. Бу бигрәк тә Гамир мисалында ачык күренә. Дошманлыкның сәбәбе Нурәхмәтнең улы Гамирга әйткән сүзләреннән аңлашыла:

«Нурәхмәт: Дуслар идек, бергә колхоз оештырып йөрдек. Яшьләребез бер чама бит безнең. Үзең дә китаплардан укып беләсеңдер, еллар шактый катлаулы чак. Ә безгә ул көн кебек, апачык кебек тоела иде. Тот та яңа тормыш корып җибәр. Һәм шулай иттек тә…»

Тик Нурәхмәт тә, дусты Инсафетдин дә өсләренә төшкән бурычның җаваплылыгын үз вакытында бик үк дөрес аңлап җиткермәгәннәр. Яңа тормышны һәркем үзенчә күз алдына китергән икән.

«Бер анадан туган игезәкләр кебек бер үк уйда» булган ике дусның юллары ник аерылды икән? Моның сәбәбе, бәлки, берсенең – халыкка, кешеләргә, икенчесенең үзенең сыйнфый сиземләвенә ышануында булгандыр. Һәрберсе үз позициясендә эчкерсез була, үзен дөрес эшли дип уйлый.

Инсафетдиннең «халык фикере белән исәпләшергә кирәк» дигән нияте «томана халык»тан ул вакытта ниндидер акыллы фикер көтүне ахмаклыкка санаган, үз карашларына гына табынган, нык характерлы, принципиаль Нурәхмәткә «үзенә каршы котырту» булып аңлашыла. Моның өстенә «байлыгын үз хәләл көче» белән җыйган кулакны яклап, алып калырга тырышу, өстәвенә, «колхозга алсак, әйбәтрәк булыр» дигән сүзләре бөтен эшне Инсафетдинга каршы бора да куя. Бу көтелмәгән хәл, Инсафетдин сүзләре белән әйтсәк, «карьерага омтылучы, беренче рәттә, кеше күзе алдында булуны, башлап йөрүне бик яраткан, күңелендә гел аның постына кызыккан», дустының «батуын гына көтеп йөргән» Нурәхмәт өчен рәислек урынын алырга «җай» тудыра имеш. Шулай итеп, Инсафетдиннең «начар нияте» турында район җитәкчеләренә хәбәр ителә. Озак та үтми, аны вазифасыннан читләштерәләр һәм «караңгы читлек»кә ябып куялар, урыны исә Нурәхмәткә кала.

Колхозлашу еллары, аннан соңгы еллар да – катлаулы, буталчык, рәхимсез чорлар. Нурәхмәт тә, Инсафетдин дә, алар буыны балалары да әлеге миһербансыз чорның явыз системасы ятьмәләренә килеп эләккән корбаннар булып чыгалар.

– Үз эшеңә абсолютно ышану кирәк иде ул чакта, менә нәрсә кыйммәт иде. Һәм корычтай ихтыяр көче, – ди Нурәхмәт. Яшь, энергияле Нурәхмәт боларның берсеннән дә мәхрүм булмый. Үзсүзле, нык характерлы бу кеше, тормышны, кешеләрне бары тик корыч законнар нигезендә генә тотып була, дип уйлый һәм шулай эшли. Беркем белән дә исәпләшми, беркемнең дә сүзенә колак салмый. Әйтерсең ул һәркемнең үз кызыксынуы, үз күңел дөньясы булган җанлы кешеләр белән түгел, ә кушканны гына үтәүче роботлар белән эш итә. Һәркем аның законына гына буйсынып яшәргә тиеш була. Кем дә кем ул законны боза икән, Нурәхмәтнең кан дошманына әйләнә. Шундыйларның берсе дөньяга үз карашы, теге яки бу хәлләргә үзенең мөнәсәбәте белән аерылып торган Инсафетдин дусты булып чыга. Һәм Нурәхмәт законнарына каршы килгән һәркемне аның язмышы көтә.

Атасының гаделсезлекләрен улы Гамирның сүзләре дә раслый:

– Синең үзеңнән башка бүтән кешене тыңлаганыңны хәтерләмим, эткәй… Минемчә, син колхозда да шундый ук тәртип урнаштыргансың. Кешеләр әкренләп күнеккәннәр һәм сизми башлаганнар. Кешеләр инде күптәннән үз башлары белән уйлаудан ваз кичкәннәр...

Егет вакыйгаларга, хәлләргә дөрес күзлектән карарга, дөрес бәя бирергә тырыша. Ул авыл җирендә чәчәк аткан эчкечелек, урлашу, җинаятьчелекнең һаман да бетмәвенең сәбәпләрен өлкән буыннардан, ягъни әтиләреннән эзли. Аның бер генә нәрсәдә иманы камил: ул замандагы күп кенә аңлашылмаучанлыкларның сәбәбе – әтисенең кырыс характерында. Димәк, Нурәхмәтнең шәхесен билгеләүче сыйфатлар ул – кырыслык, усаллык, үз принципларыңа нык ышану, рухи ныклык.

Гамирның уйлары, вакыйгаларга мөнәсәбәте аша пьесада әһәмиятле фикер уздырыла: берәүләрнең чиксез хакимлеге икенче берәүләрнең изелүенә китерә, аларда мөстәкыйльлекне үтерә, кешене шәхес итә торган рухи ирекне сыта, изә. Бу, үз чиратында, кеше шәхесен кимсетүгә китерә.

Инсафетдин дә – бәхетле тормыш корырга хыялланган кешеләрнең берсе. Тик Нурәхмәт белән аларның юллары әлеге якты хыялга барганда аерыла. Инсафетдин хаксызга (заманы өчен хаклы, әлбәттә) төрмәдә утырып чыга. Авылдашлары аннан йөз чөерә. Шулай да аларга аның мөнәсәбәте начар түгел. Ул – кешеләргә күңелен ачуны кирәк тапмаган һәм үз эченә бикләнгән герой. Тыштан караганда күпме коры булса да, асылда, кешелекле. Оныгы Зәримәнең сөекле ире Гамир үлеп, олы фаҗигасе беленгәч, ул бөтенләй башка яктан ачылып китә. Аның Зәримәгә булган мөнәсәбәтендә, әйткән һәр сүзендә теләктәшлек, аңларга, ярдәм итәргә тырышу сизелә. «Кичергән авырлыклар, хаксызга төрмәдә утыру, гомер буе авылдашларының кырын карашларын тоеп яшәү андагы кешелеклелекне үтерә алмаганнар» [Арсланов, 1983]. Аның шәхси үзенчәлекләрен сүздә һәм эштә дөреслек, горурлык, ныклык, принципиальлек, рухи ireклек сыйфатлары билгели. Картларның берсе дә ялгышлардан азат түгел, шуңа күрә күңелләре тынычлык таба алмый, аларның һәрберсе кайчандыр ныклап уйлап бетермичә кылган гамәлләре өчен чын күңелдән үкенә, газаплана, башкалар алдында үзләрен гаепле тоя.

Заман рухын ачуда конфликт гаять зур роль уйный. Әсәрдә җәмгыять үсешенең шул чорына хас тенденцияләре һәм каршылыклары гәүдәләнә [Юзиев, б. 171]. «Китәм инде» пьесасында үзәк конфликтны кешеләрнең изге-якты хыяллары белән явыз чынбарлыкның каршылыкка керүе, көрәше тәшкил итә. Аңа бәйле рәвештә шәхси конфликтлар да үсеш ала. Нурәхмәт белән Инсафетдиннең каршылыклы мөнәсәбәтләре – шуның ачык мисалы.

Пьесада өлкәннәрнең яшьлек хаталары алардан соңгы

буынның язмышына тискәре йогынты ясавы тасвирлана. Кайчандыр җан дуслар булып та, катлаулы елларда юллары аерылган күршеләренең мөнәсәбәте, әнисе ташлап киткәч, әби-бабасында тәрбияләнгән Инзар күңелендә тирән эз калдыра. Әниләре урынына калган бабасы белән әбисенең өлешенә төшкән замана авырлыклары, чор кырыслыгы, сөйгәненнән кире кагылу аны тагын да явызландыра, рухын җимерә, әхлакый сыйфатларына тәэсир итә. Күршеләре Нурәхмәтне, аның улы Гамирны күралмый ул. Соңгысының барысы да яхшы булуыннан көнләшә. Үзенең бар бәхетсезлеген, тормышының көтелмәгәнчә килеп чыгуын да алардан күрә. Һәм шушы сукыр нәфрәт аны соңгы чиктә җинаятьче дәрәҗәсенә китереп җиткерә. Ул – трагик шәхес. Трагизм азмы-күпме пьесадагы һәр персонажга да хас. Аларның һәрберсе – усал язмыш корбаннары.

Драманың иң матур ягын Гамир белән Зәримә мәхәббәте тәшкил итә. Тәнкыйтьчеләр аны Ромео һәм Джульетта мәхәббәтенә тиңлиләр [Илялова]. Әсәрдә яшьләр образы үсеш, үзгәрештә бирелә, аларның язмышлары аркылы үткән белән хәзергенең бәйләнеше сузыла. Зәримә, абыйсы Инзардан аермалы буларак, физик яктан гына түгел, рухи яктан да искиткеч матур кеше. Автор һәрвакыт аның тышкы матурлыгына басым ясый: «...хатын-кыз сынының иң гүзәл, хыялда гына туа торган камиллеге ич бу», – ди, һәм кызның физик матурлыгы белән рухи камиллеге һәрдаим бер-берсен тулыландырып тора. Зәримә дә, Гамир дә – кешелекле, максатчан, нык характерлы, алдынгы фикерле яшьләр. Нинди генә фаҗигале булмасын, аларның мәхәббәтләре тормыш түбәнлекләреннән күпкә өстен. Алар кеше язмышын ватаҗимерә торган законнарга каршы; һәр нәрсәгә үз карашлары, гадел хөкемнәре, тормышта үз юллары бар.

Пьесадан аңлашылганча, явызлык хөкем сөргән җирдә матурлык чәчәк ата алмый. Яшьләр моның белән канәгать түгел: «Цивилизация заманы, кыргый законнар юк диярлек… Тик һаман да кешеләр корбан булалар…», – ди Зәримә. Бу – драматургның Зәримә авызыннан әйттергән социалистик чынбарлыктан канәгатьсезлеге. «Пьесаның төп йөген күтәреп баручы персонажлар социализмны ачыктан-ачык каһәрләмәсәләр дә, авторның кай ноктада басып торуы, үз урынын кыю яклый алуы, халык хакын яклап, йөрәге урталай ярылуы күренеп тора» [Гыйләҗев].

Аталар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәт – Р. Хәмид иҗатының нигезенә салынган проблемаларның берсе. Алдагы драмаларда да без моны күрдек. «Каен җиле» [Хәмид, 1987, б. 50–88. Цитаталар шушы чыганактан алына] пьесасында да аталар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәт үзәктә тора. Әлеге пьесада да кырыслык лейтмотив характер ала. Әти-әнисен, якыннарын гомергә ташлап чыгып киткән Илсур холкында чагыла бу. Илсур – катлаулы шәхес; кечкенәдән гарьчел, үчлекле, шул ук вакытта атасы шикелле үк нык характерлы,

горур була. Әтисенең кырыслыгы улы холкына яшьтән үк эз сала. Нурәхмәт абзый улының кайтмаячагын гомере буе белеп, шуңа эчтән янып яши. Хатыны Гөлбануның уллары утыртып калдырган каен агачы янында көн дә өзгәләнеп аны көтүе картның күңел ярасын тагы да көчәйтә.

Илсур белән якыннан таныш кешеләрнең сүзләренә караганда, аны бер дә начар дип булмый. Эш урынында да хөрмәт итәләр, акыллы кеше булуын әйтәләр. Гаиләсенә ул кирәк. Әнисе аны бер генә мизгелгә дә исеннән чыгармый, акылдан язарлык булып көтә. Аның характерының кырыслыгы якын кешеләрен сагыш утына салуда чагыла. Тормыш иптәше Зинаиданың әтисе Гнат бабай да киявен өнәп бетерми:

– Ниен яратасың аның?! Салкын кеше ул, – ди. Югыйсә үзе, Гнат бабай сүзләре белән әйтсәк, «акыллы да, күңелендә кер дә юк шикелле», тик Илсурның салкынлыгы башка барлык уңай сыйфатларын да каплый. Гнат бабай өчен ул – «үзен-үзе тормыштан сызып ташлаган кеше».

Шуны искәртеп үтәргә кирәк: Илсурдан соң килгән җитәкчедән дә салкынлык, кырыслык бәрелеп тора. Күрәсең, яңа җәмгыять кешеләренә хас сыйфаттыр бу! Илсурның өеннән китүен, әти-әнисе янына бер дә кайтмавын «зур берләшмәнең бүлек җитәкчесе, олы гәүдәле, шактый кырыс йөзле кеше» – Юрзин Николай Иванович – аның «мөстәкыйльлеге, корыч ихтыярлы» булуы, әти-әнисеннән, туганнарыннан бәйсезлеге белән аңлата. Алай гына да түгел, аның яңа җәмгыятьнең «яшәү принципларын акылы белән сынап» үзләштергән һәм «башкача яшәргә кирәк дигән фикергә килгән» булуын әйтә. Димәк, Илсур – яңа җәмгыять кешесе. Башкача була да алмый. Ул әти-әнисен онытмаган. Аның кебек «феноменаль хәтерле кеше» әти-әнисен оныта алмый. Күрәсең, ул яңача яшәү принципларын чыннан да яхшы үзләштергән булып чыга. Бу аның үз сүзләреннән дә аңлашыла:

«Илсур: Без, гаилә – дәүләтнең нигез ташы, дибез. Ә ныклабрак тикшерсәң – ул нигез ташы җәмгыятьне тигез булмаган ике төп төркемгә бүлә: бер якта үз туганнарың, икенче якта – башкалар, ягъни чит кешеләр. Димәк, гаилә дәүләтнең нигез ташларын тәшкил итү белән бергә, җәмгыятьнең гармоник рәвештә үсүенә киртә дә булып тора икән.

Гадел: Сез гаилә коруга бөтенләй каршы чыгасызмыни?

Илсур: Мин, бары тик, гаиләнең «туган-тумачалык» дигән законга язылмаган усал көчен тартып алырга кирәк, дим. Ә моны балалар һәм аталар, туганнар арасындагы колларча бәйлелекне бетергәндә генә юкка чыгарып була. Һәркем һәркемнән мораль яктан азат булырга тиеш».

Шул сәбәпле якыннарыннан баш тартып торырга туры килә аңа, чөнки әлеге җәмгыятькә әти-әни алдында бурычлы булу, аларны ярату, хөрмәт итү кебек хисләр ят. Димәк, яңа җәмгыять корыч ихтыярлы хиссез кешеләр тәрбияли. Ата-ананың газиз балалары белән күрешә алмауларының төп сәбәбе дә яңа җәмгы-

ять булдырган принципларга кайтып кала шикелле. Күрәбез ки, яңа җәмгыятьнең яңача яшәү принциплары ата белән баланы бер-берсеннән аеручы, кешене үзенә йолучы көч булып чыга. Әлеге образ турында А. Шәмсутова: «Аны маргиналь герой, ягъни үзе яшәгән мохиттән читләшкән, аның кануннарын кабул итмәгән, үзенчә яшәргә дигән фикергә килгән герой дип атарга булыр иде» [Шәмсутова, б. 126], – дип яза. Дөресрәге, заман кушканча яшәргә дигән фикергә килә Илсур.

Пьесада алай күзгә бәрелеп торган конфликт юк та шикелле. Бу беренче карашка гына шулай. Әсәрнең төп һәм хәлиткеч конфликтын ата-ананың изге теләкләре белән алардан газиз балаларын тартып алган яңа җәмгыятьнең рәхимсез принциплары арасындагы көрәш тәшкил итә. Бу конфликт пьесада ананың, зарыгып көткән улы һаман кайтмагач, ул утыртып калдырган, гомер буе аның истәлеге итеп үстергән каен агачын чабып аударуы аша җәмгыятькә тугры хезмәт итүче улы белән күңелендә барган көрәше сыйфатында бирелә. Үләр алдыннан агачны чабып аударып, бичара ана тормышында иң изге, иң якын кешеләрен рәхимсез җәмгыять принципларына алыштырган улыннан ваз кичүен белдерә. Моның шулай икәнлеге килене Зәримә сүзләрендә дә чагыла: «Димәк, әнисе өчен Илсур исемле малае булмаган бу дөньяда! Канлы газаплар эчендә тапмаган да, йөрәк җылысын кызганмыйча, күкрәк сөтен имезеп үстермәгән дә!»

Пьесада Гнат бабайның Илсурга карата сөйләгән лейтмотив булып яңгыраучы сүзләренә кабат кайтып, шуны әйтергә мөмкин: битараф кеше генә «үзенүзе тормыштан сызып ташлый ала», чөнки андый таш күңелдә хис, кичереш, омтылыш булмый. Ә кешелек кыйммәтен билгеләүче әлеге сыйфатлардан мәхрүм кешенең хәзергесе дә, киләчәге дә юк. Ул үзен дә, башкаларны да бәхетле итә алмый.

Әдәбият мәйданында узган гасырның 70–80 елларында җитештерү темасы бик популяр була. Бу елларда иҗат ителгән пьесаларны тәнкыйтьтә «социологик» (А. Свободин), «аналитик драмалар» дип йөртәләр. Әлеге пьесаларның «көче – документаль төгәллектә, ә йомшак ягы – характерларның психологик яктан эшләнеп җитмәвендә» [Громова, с. 9].

«Айсберг» [Хәмид, 1987, б. 111–156. Цитаталар шушы чыганактан алына] – җитештерү темасын яктырткан драма. Әлеге әсәр илдә бара торган демократик үзгәрешләрнең асылы турында уйландыра. Пьесада хезмәткә мөнәсәбәт аша заманның мөһим иҗтимагый-сәяси һәм әхлакый мәсьәләләре яктыртыла. Геройларның үз эшләренә мөнәсәбәтләре аркылы драматург аларның иҗтимагый-әхлакый йөзләрен, тормыштагы позицияләрен ача, бу мәсьәләне хәл итүгә заманның билгеле бер эз салуын күрсәтә.

Вакыйгалар эш урынында, берләшмә идарәсендә бара. Пьесада бирелгән персонажларның эш алымнары, характер

үзенчәлекләре эшкә булган мөнәсәбәткә бәйле ачыла. Җаваплы урында утыручылар – берләшмә җитәкчесе Троянкер Вячеслав Семёнович, баш инженер Ничичейко Константин Сергеевич, җирле комитет рәисе Архипов Игнатий Николаевичлар йөзендә җәмгыять өчен куркыныч кешеләрне күрәбез. Боларга үз карьераларыннан башка берни дә кирәкми. Әлеге җитәкчеләрнең кылган һәр гамәлләрендә дәүләт милкенә саксыз карашлары, үз эшләренә намуссыз, гаделсез мөнәсәбәтләре фаш ителә. Берләшмә җитәкчесе Троянкерның эш урынында барган хәлләр белән җитәрлек дәрәҗәдә таныш булмавы сизелә. Асылда берләшмәнең җитәкчесе ул түгел, ә Ничичейко белән Архипов кебек тәэсир туа. Алар күп нәрсәне Троянкерга әйтеп тә тормыйча гына эш итәләр. Соңгысына карата чын бәяне яшьтәше, сугышта аның белән бергә булган иптәше Гыйздулла абзый авызыннан ишетәбез:

«Үзгәрдең син, Слава, үзгәрдең... Күкрәгеңдәге йолдызың тәнеңне пешермиме? Хәер, син аны соңгы вакытта гына тага башладың... Элегрәк йолдызыңны күрсәтеп йөрмәсәң дә, барлыгын беләләр иде! Һәм шуның аркасында эшең көйле генә барды да. Шулай булмый ни: Советлар Союзы Герое ич син! «Корыч нервлы кеше» – син идең ул, Слава. Берүзең калгач, унлап танкны яндырган кеше! Әле дә хәтеремдә, землянкада син бирелеп гармун уйнап утырасың. Шунда капитан Шәйдуллин сиздермичә генә колак төбеңдә, шаярып, пистолеттан атып җибәрде, ә синең керфекләрең дә селкенмәде... Без сине корыч нервлы, дип йөрдек, ә син туң нервлы кеше икәнсең!»

Димәк, Троянкер характерын билгеләүче төп сыйфат – «туң нервлылык», ягъни битарафлык. Җәмгыять өчен, кешелек тормышы, яшәеш өчен иң куркыныч нәрсә – битарафлык, ваемсызлык. Җитәкче кешенең, кешеләр язмышы өчен җаваплы кешенең битараф булуы – аеруча куркыныч. Җинаятьчелекнең, тәртипсезлекнең котырып артуына да кеше холкында өстенлек алган шушы сыйфатлар гаепле. Алар белән көрәшәсе урында битараф калу – үзе зур җинаять... Дәрәҗә, җиңел юл белән акча эшләү бозган кешене. Ә инде җибәргән хаталарны, кимчелекләрне күкрәктәге йолдыз белән уңышлы гына каплап килү аны тынычландырган. Троянкерның күкрәгендәге кызыл йолдызы – аның намуссыз вөҗданын яктыртып торучы символик образ.

Рухи бөтенлек, әхлаклылык – кешене шәхес итә торган мөһим сыйфатлар. Рухи бөтенлек юкка чыгу белән, шәхес тә юкка чыга, ягъни кешенең «шәхес» дигән бөек исеме югала. Ничичейко, Архипов, Троянкер – социалистик чынбарлыкның гаделсезлекләрен үзләрендә туплаган рухи гарип кешеләр.

Әлеге пьесада да өлкәннәр белән яшьләр мөнәсәбәте проблемасы үзәккә алына. Тик ул, гаилә чикләре эчендә генә калмыйча, киңрәк планда – эш сферасында яктыртыла. Берәүләрнең кылган гамәлләре, икенче берәүләрнең шушы кылынган гамәлләргә мөнәсәбәтләре аркылы

социалистик җәмгыятьтә хөкем сөргән гаделсезлекләр күрсәтелә. Пьесада яшьләр – замана гаделсезлекләрен ачарга алынган саф йөрәкле, намуслы кешеләр. Алар социалистик җәмгыятьтә чәчәк аткан битарафлыкны, ваемсызлыкны, кешеләр арасындагы һәртөрле явызлыкны фаш итәләр, бу хәлләргә тискәре мөнәсәбәтләрен белдерәләр. Бухгалтер-ревизор Илшат Галимов, «Чаян» журналы корреспонденты Ия, партоешма секретаре Социал Бәдриевич – шундыйлардан. Боларның һәркайсы гаделсезлекләргә каршы үзенчә көрәшә. Әлеге көрәштә характерлар бөтенлеге ачыла. Пьесаның төп конфликтын нигезендә социаль сәбәпләр яткан битарафлык, гаделсезлек, карьеризм белән көрәш тәшкил итә. Кешеләрнең ялгышуларында, газап чигеп яшәүләрендә кырыс чынбарлык, аның рәхимсез законнары гаепле. Хакимият – явызлар кулында. Кемнәрдер, рәхәт яшәү юлларын белеп ала да, шуны кәсеп итә; икенче берәүләр шундыйлар хөкеменнән интегә.

Пьесаның исеме иҗтимагыйсимволик мәгънәгә ия. Кешеләр тарафыннан башкарыла торган җинаятьләрне драматург, бер исем астына алып, «Айсберг» дип атый. Җинаятьләр күп эшләнә, тик аларның барысы да ачылып бетми. Ничичейко, Архиповларның намуссыз әмерләрен сүзсез үтәргә мәҗбүр ителгән ревизия комиссиясе җитәкчесе Илсөяр Зиннуровна сүзләре белән әйтсәк, «айсберг кебек ул: җинаятьләрнең ачылганы шул боз тавының су өстендәге өлеше кадәр генә!» Димәк иң күп өлеше «су астында» кала! Җинаятьләрнең нигезе – җәмгыятьнең гадел булмаган рәхимсез законнары көчендә. Кешеләрнең кылган гамәлләрендәге ялгышларны, гаделсезлекләрне заманага гына сылтап калдыру да дөрес булмас кебек. Әйтик, Илшат та, Ия дә, Социал Бәдриевич тә, Гыйздулла абзый да – шушы заман кешеләре. Тик аларны заман үзгәртмәгән. Бу һәркемнең үз характерына да бәйле күрәсең, дип куя мәсьәләне автор.

Р. Хәмид пьесаларында «телсез калган авыллар, татар халкына карап рәнҗегән таулар телгә килә. Авылларда бетү, кырылыш, инкыйраз. Түбәндә, үзәнлектә яшәп яткан авыллар кими, елга ярлары җимерелә, киләчәктә татар язмышын кулга алырга тиешле егетләр телсез...» [Гыйләҗев]. Мондый чакта җансыз күренешләрнең җанлануы аптыраштa калдырмас. Милләт сагында торган, табигатьнең ныклыгын билгеләгән тарих шаһитләре Кызылтау белән Дүртмаңгай да бу хәлгә ваемсыз кала алмыйлар. Драматург, кешелек тормышының аяныч хәлен, фаҗигасен күрсәтү өчен, шактый еллар сабыр гына татар тормышын күзәтеп яткан тауларны бер-берсенә дәшәргә мәҗбүр итә. «Майның унбишләрендә» [Хәмид, 1989, б. 32–72. Цитаталар шушы чыганактан алына] әсәрендә күрәбез моны. Дүртмаңгай сүзләренә игътибар итик: «Җир өстендә икебез генә калгач… Күз алдыңа китер: беркөнне уянып китәсең – җир өсте шәп-шәрә. Хозурлык!

Итәкләребез чип-чиста. Бер җан иясе кыймылдамый! Сыртларыбызны бернинди агач, үлән тамырлары тишкәләми! Рәхәт. Килер ул көн, күрше, килер… Әнә – түбәндәге авылга кара. Ике аяклыларның тормышы шуңа таба бара, минемчә!» Аллегорик образлар буларак ике тауның сөйләше авылның аяныч киләчәге турындагы фикерне көчәйтү максатыннан бирелгән. Пьесада конфликт та шушы нигездә – авылның киләчәген саклап калу мәсьәләсенә мөнәсәбәттә туа. Гомер буе авылда яшәгән Варис картның туган авылының бетә баруына эче бик поша, йөрәге әрни. Ул шушы таркала барган авылда өй торгызган. Нияте – шәһәрдә Мәгариф министрлыгында җаваплы хезмәткәр булып эшләүче өлкән улы Зәкуанны авылга кайтарту. Ул кайтса, юл да төзелер, күпер дә салыныр, дип өметләнә Варис карт, чөнки өлкән улының абруе зур, сүзе үтәчәк... Тик ата белән баланың дөньяга карашлары күптән инде аерылган булып чыга. Шәһәрдәге рәхәт тормышны ташлап, үзәгенә үткән авылга кайтырга исәбе юк өлкән улының. Атаның якты, изге хыяллары рәхимсез, кырыс чынбарлык белән бәрелешкә очрый.

Шәһәр тормышы шактый үзгәрткән өлкән улны. Зәкуан пьесада үзе турында гына уйлаучы, зур дәрәҗәгә омтылучы, олылар сүзен санга сукмый, якыннарын хөрмәт итми, алар хәленә керми торган, авыл тормышына битараф, каты бәгырьле кеше булып ачыла. Бу аның әтисе Варис картка, энесе Мәгавигә мөнәсәбәтендә дә сизелә, кайчандыр сөйгән кызын ялгыз калдырып ташлап китүендә дә күренә. Әлеге мөнәсәбәтләрдә ирнең характер үзенчәлеге тулысынча ачыла. Зәкуанның улы Айдар белән әңгәмәсендә туган нигезен генә түгел, туган телен дә оныта баруы күзәтелә.

«Җиде баҗа» [Хәмид, 1989, б. 109–153. Цитаталар шушы чыганактан алына] пьесасында драматург рәис образларын үзәккә куеп сурәтли. Пьесада колхоз рәисе Дулат, авыл советы рәисе Сатай, Гыймазетдиновлар гаиләсе белән очрашабыз. Вакыйгалар колхоз үзәге саналган авылда бара. Әсәр ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое булган Күгәй Гыймазетдиновка үзе исән килеш куелган һәйкәлнең югалуы күренешеннән башланып китә. Характерлар, авылның хәле шул һәйкәлгә мөнәсәбәтле ачыла. Аны эзләү барышында төрле гаделсезлекләр, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр ачыклана, илдә колхозларга карата алып барылган сәясәтнең ялгыш яклары күрсәтелә. Р. Хәмиднең бу әсәрендә дә геройлар артык кырыс, бер-берсенә тәнкыйть күзлегеннән карыйлар; аңлашырга, гафу итәргә тормыйлар, мөнәсәбәтләрне гел киеренке тоталар. Пьесада колхоз рәисе Дулат акыллы, сабыр, миһербанлы, уйлап эш итүче кеше буларак ачыла. Кешеләр белән мөнәсәбәтендә дә ипле, авыл халкының борчуларын үз итә, аларга ярдәм күрсәтергә

тырыша; хатын-кызга карата да тәрбияле, чын-чынлап ярата белә. Шул яклары белән ул авылда үзенә кадәр эшләп киткән рәисләрдән, ягъни Күгәйнең кияүләреннән аерылып тора. Драматург илдә хөкем сөргән рәхимсез идеологиягә карата тәнкыйть сүзләрен яшьләр авызыннан әйттерә. Пьесада шундыйларның берсе – Дая. Кыз сүзләрендә рәисләрнең чын йөзләре, булдыксызлыклары, алар алып барган сәясәтнең гаделсезлеге бөтен асылы белән ачыла. Шул булдыксыз җитәкчеләрнең сүзләрен җөпләп утырырга мәҗбүр булган авыл халкының чарасызлыгы күренә. Аның сүзләрендә ни кушсалар, шуны эшләп йөрүче әтисе кебек карусыз кешеләрнең дә колхозны алга җибәрергә ярдәме тия алмаганлыгы аңлашыла, чөнки намуссыз, оятсыз җитәкчеләр Күгәй кебекләр аркасында, аларны юмалап, орден-медальләр биреп, колхозны таларга, халык исәбенә яшәргә мөмкинлек алганнар. Даяның һәр сүзе чәнечкеле, һәр сүзендә – гаделсезлекләргә нәфрәте сизелеп тора. Гомумән, яшьләр сөйләгән сүзләрендә усал, кылган гамәлләрендә – кырыс. Без моны алдагы пьесаларда да күреп уздык. Замана кырыслыгы, өлкәннәрнең үзара мөнәсәбәтендәге, балаларга карата гаилә эчендәге кырыслык аларга да эзен сала. Замана гаделсезлекләрен ачуда каравылчы Чуракай образы да зур роль уйный. Заманында ул бригадир булган. Хәзер башын тилегә салып йөрергә яратса да, барысыннан хәбәрдар. Дөреслекне, идарә эшендәге, кешеләр характерындагы кимчелекләрне, гаделсезлекләрне мисал-дәлилләр белән аның авызыннан ишетергә була. Әтисенә һәйкәл салынуын ишетеп, Искәндәр дә биш елдан соң авылына кайтып төшә. Авылның аяныч хәле, бөтен җирдә хөкем сөргән тәртипсезлек, җимереклек аны битараф калдыра алмый. Җиде баҗа туздырып киткән туган авылын читтән килгән бер рәиснең генә рәткә кертә алмасын аңлап, егет үзе ныклап эшкә керешә. Дөреслек өчен көрәштә Искәндәр үзсүзле, кырыс булса да, мөстәкыйльлеккә омтылса да, «Синең урыныңа кайттым» пьесасындагы Наилдән аермалы буларак, тәҗрибәле өлкәннәрнең акыллы киңәшләреннән башка эшнең килеп чыкмасын яхшы аңлый:

– Кул көчең кирәкми синең, әткәй! Зирәклегең кирәк, кеше белән эш итә белүең, – ди. Эшне иренеп кенә эшли торган Чуракай да аңа чын күңелдән булышырга әзер, чөнки ул анда өмет күрә. Искәндәрнең әлеге җаваплы эшендә өлкәннәр зирәклегенә таянып, алар белән киңәшләшеп эшләве дөрес һәм хөрмәткә лаек. Бу – герой үзаңындагы үсеш, үзгәреш билгесе.

Авылларның матур киләчәге өчен авыл халкының ышанычын акларлык, халыкка киңәшче, ярдәмче була алырлык, тик аны үз фикерләренең колы итмәслек акыллы, җиң сызганып, ныклап торып эшкә тотынырдай рәисләр кирәк. Чын күңелдән башкарган эшнең генә нәтиҗәсе яхшы була.

Язучы, рәиснең намуслы хезмәте – авыл тормышының йөз аклыгы, аның язмышы өчен ул җаваплы, дигән фикер үткәрә.

Барлык персонажларның да чын йөзләре, кичергән фаҗигаләре ачылып беткәч, һәйкәл табыла. Һәйкәлне әтисенең туган авылы беткәнгә күңеле әрнегән Искәндәр яшергән булып чыга. Аның сүзләре игътибарга лаек: «Закон буенча һәйкәл үзебезнең туган авылыбызда куелырга тиеш бит, әткәй. Ә туган авылыбыз үлеп бара. Кабат терелтәсебез бар әле...»

Кибет өчен дә, авыл советы өчен дә, «кәнсәләр» өчен дә җаваплы үткен күзле Чуракай күз алдыннан һәйкәл кадәр һәйкәлнең юкка чыгуы – гаҗәп хәл. Әмма монда, Чуракай әйтмешли, «хикмәт бар», ягъни автор җиткерергә теләгән фикер бар: исән кешегә һәйкәл кую дөрес түгел. Һәйкәлне кеше үлгәч, аның якты истәлегенә куялар. Һәйкәлне юкка чыгарып, Искәндәр, әгәр кешенең йөзе авылдашлары каршында якты икән, исеме болай да яшәячәген төшендерергә тели. Пьесаның төп конфликтын гаделлек, дөреслек, олы кешелек кыйммәтләре өчен көрәш тәшкил итә. Ул гаилә әгъзалары, кешеләр арасындагы киеренке мөнәсәбәтләр рәвешендә чагылыш таба. Кешелек кыйммәтләре өчен көрәш – Р. Хәмид драмаларының барысының да нигезендә ятучы күренеш.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: Р. Хәмид геройлары катлаулы тормыш юлы уза; язмыш сынавы беркемне дә – олысын да, яшен дә аямый. Пьесаларда гәүдәләнеш тапкан конфликтлар аша язучы чор рухын, заман сулышын, әһәмиятле иҗтимагый, төгәл тарихи бәрелешләрне, аларның төп этәргеч көчләрен, персонажларның теләк-омтылышларын, дөньяга карашларын, алар характерының үзенчәлекләрен, социаль билгеләрен ачарга омтыла.

**Әдәбият**

*Арсланов Г.* Китәм инде... // Социалистик Татарстан. 1983. 17 апрель.

*Горбунова Е.* Идеи, конфликты, характеры. М.: Сов. писатель, 1960. 418 с.

*Громова М.И.* Русская современная драматургия: учеб. пособие для студ.-фил., уч-ся ср. учеб. завед. гуманит. профиля. М.:Флинта: Наука, 1999. 160 с.

*Гыйләҗев А.* Сулар үргә аккан чак // Шәһри Казан. 1991. 15 ноябрь.

*Илялова И.* Под знаком судьбы (Под знаком Марса) // Советская Татария. 1983. 22 апреля.

*Мухамедова Г.* Если люди остаются людьми (Пьеса «Под знаком Марса») // Вечерняя Казань. 1983. 13 мая.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда: 60–90 нчы еллар әдәбияты / Баш мөхәррир М. Х. Хәсәнов. Казан: Раннур, 2001. 6 т. 362 б.

*Хәмид Р.* Китәм инде: ике бүлекле драма // Каен җиле: драма әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 3–49.

*Хәмид Р.* Каен җиле: ике бүлекле драма // Каен җиле: драма әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 50–88.

*Хәмид Р.* Айсберг: ике бүлекле драма // Каен җиле: драма әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 111–156.

*Хәмид Р.* Майның унбишләрендә: ике бүлекле драма // Олы юлның тузаны: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 32–72.

*Хәмид Р.* Җиде баҗа: ике бүлекле драма // Олы юлның тузаны: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 109–153.

*Хәмид Р.* Синең урыныңа кайттым: ике бүлекле драма // Китәм инде: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. Б. 48–90.

*Шәмсутова А*. Тарих таный – иҗатына җаннарын салганнарны... // Казан утлары. 2004. № 10. Б. 120–131.

*Юзиев Н.* Конфликт һәм характер // Сәнгатьчә матурлык һәм осталык. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 1 нче бүлек. Б.163–193.

***Каюмова Гөлия Илдус кызы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты*
*Энциклопедистика үзәгенең татар текстларын тәрҗемә итү бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре.*
*e-mail: guliya.kayumova@yandex.ru*

УДК 398.22

*И.Г. Закирова*

## ТАТАР ХАЛЫК ДАСТАННАРЫ

Статья посвящена исследованию татарских дастанов, выявлению их мифологических и исторических основ.

**Ключевые слова:** дастан, классификация дастанов, национальная версия, архаические мотивы, эпический герой, историческое событие.

Эпос – халык тарихындагы аерым вакыйгаларны тасвирлаган фундаменталь характердагы эпик яки лиро-эпик жанр. В.М. Жирмунский, әлеге жанрның әһәмиятен күрсәтеп: «Эпос – ул халыкның героик идеализация масштабындагы үткәне. Аның фәнни һәм тарихи кыйммәте, шул ук вакытта гаять зур иҗтимагый, мәдәни, тәрбияви әһәмияте дә шуның белән аңлатыла», – дип яза [Жирмунский, 1958, с 24] (мәкалә авторы тәрҗемәсе).

Күпчелек төрки халыкларда эпосны *дастан* (фарсы теленнән кергән: – тарих, үткән эшләр) дип атау кабул ителгән Татар фольклорында шушы ук жанрны аңлаткан *кыйсса* һәм *хикәят* терминнары да кулланыла. Башка төрки халыкларда да эпосның үз милли атамалары бар. Героик, фантастик һәм романик эчтәлекле поэтик, прозаик яки катнаш формадагы әсәрләрне әдәбиятта һәм фольклорда дастан дип атыйлар [Литературный..., с. 86–87].

Татар фольклорындагы дастан жанры үзенең тамырлары белән гомумтөрки эпоска барып тоташа. Бөтен төрки халыкларның уртак мирасы булган дастаннар да шактый. Мәсәлән, «Алпамыш» дастаны, татарлардан башка, үзбәк, казакъ, алтай, башкорт һәм башка халыкларда да бар. (Искәрмә: бер үк дастанның милли версияләренең һәм вариантларының исемнәрендә аерымлыклар очрый.) «Кузы-Күрпәч белән Баянсылу» дастаны шулай ук алтай халыкларында, казакъларда, башкортларда популяр әсәр. «Ак Күбек» дастаны себер татарлары һәм алтайларда гына, ә «Түләк» татар белән башкорт халыкларында гына бар. Аерым дастаннар татар халкына тугандаш халыклардан кергән. Аларны уртак мирас дип карап булмый, әмма алар халыклар арасындагы рухи багланышларны, күчешләрне күрсәтү ягыннан әһәмиятле. Мәсәлән, казакъ халкының «Кыз Жибек» дастанын, «Кыз Җефәк» дастаны буларак, татар халкы да белә. «Күр улы» дастаны да татар халкына төрек фольклорыннан кергән. Әмма һәр халык үз вариантында тарихына, көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә бәйле детальләр белән эш итә, үзенең йола-ышануларын сурәтли.

Татар халкының дистә гасырлар элек ислам динен кабул

итүе, язулы һәм китаплы булуы, аның дастаннарына да тәэсир итми калмаган. Җырау-акыннарны китап алыштырган. Шул ук вакытта ислам диненең шаманчылыкны тыюы да, аларны эзәрлекләүгә китергән. Һәр җырау яки акын күпмедер дәрәҗәдә шаман яки күрәзәче вазыйфасын да башкарган. Мәсәлән, «Идегәй» дастаны аша исеме безнең көннәргә килеп җиткән Субра җырауның дастанда күрәзәчелек сәләтенә ия булуы, һәм үткәнне киләчәкне фаразлавы тасвирлана. Дастаннарны башкаруның үзенең күп төрле шартлары һәм тыюлары булган. Әлбәттә, иң беренче шарты – дастаннарны теләсә кем сөйли алмаган. Җырау булу Күкләр яки Тәңре тарафыннан бирелгән сәләт буларак бәяләнгән. Көннең яки елның теләсә кайсы вакытында да дастан сөйләмәгәннәр. Дастаннарда бирелгән мәгълүмат, буыннан буынга күчеп, язылмаган тарих ролен дә башкарган.

Дастаннар – күпчелек төркиләрдә тезмә ягъни шигъри формадагы әсәрләр. Татар дастаннарында, кагыйдә буларак, тезмә һәм чәчмә өлешләр аралашып бара. Күбесендә тезмә өлеше бик аз. Тезмә өлеш «Идегәй» дастанында гына яхшы сакланган. Бу күренеш тә җырау профессиясе югалу белән аңлатыла. Җыраулар дастаннарны яттан белгән, үзләре дә шигъри талантка ия, импровизациягә сәләтле бу кешеләр тезмә дастаннарны сәгатьләр буе башкарган. Аерым әсәрләр яки дастаннарның аерым фрагментлары музыка коралларына кушылып, көй белән башкарылган. Җыраулар юкка чыгу белән, дастаннарны башкару аларның эчтәлеген сөйләү белән алышынган. Бу, әлбәттә, күпчелек әсәрләрнең югалуына, күләмнәре кимүгә китергән. Без укый торган дастаннарны борынгы эпосның кыскача эчтәлеге дип атау да дөреслектән ерак түгел.

Эпос яки дастаннар фольклорның иң күләмле һәм катлаулы жанры. Ул барлыкка килүе белән ыруглык җәмгыяте чорына карый һәм үзендә иң борынгы мотивларны – дөнья яратылу, күкләр, җир һәм җир асты дөньялары турындагы космогоник карашларны да саклый. Эпос формалашуда төп чыганак – ул мифлар. Бигрәк тә культургеройлар – иң беренче кешеләр турындагы мифологик хикәятләр эпос жанры формалашуда мөһим роль уйный [Мифы..., с. 664]. Галимнәр, эпосның бер башлангычы мифлар булса, икенче яктан тарихи риваятьләр булуын күрсәтәләр [Мифы..., с. 664]. Шул рәвешле, архаик эпоста эпик вакыт – мифик дәвер һәм шул ук вакытта реаль ыру-кабилә, беренче архаик дәүләтләр тарихы, алар арасындагы мөнәсәбәтләр тасвирлана. Архаик эпосның бер үзенчәлеге – анда, кагыйдә буларак, үзара дошманлашып яшәгән дуаль система, ягъни «бу дөнья» яки «үз җиребез» белән «теге дөнья» яки «ят җирләр» арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзенчәлекле чагылышы сурәтләнә. Шул ук вакытта әлеге ыру-кабиләара көрәш галәмне хаостан яклауның чагылышы да. Бу һәр дөньяның үз урынында булуы өчен көрәшне аңлата. Һәр стихия вәкилләре үз

дөньяларында яшәргә, икенчеләренә үтеп кереп, бер-берсенең тынычлыгын бозмаска тиеш. Суияләренең, урман ияләренең тынычлыгын саклау, аларның территориясенә рөхсәтсез кермәү хәзерге вакытта көннән-көн актуальләшә барган экологик проблемаларны, ягъни табигатьне саклауны да күз алдында тота.

Төрки фольклорда үзара каршылыклы дуаль система турындагы мотивлар, беренче чиратта, никах белән бәйле сюжетларда саклана. Герой үзенең кәләшен икенче дөньядан – ятлар дөньясыннан ала, аны эзләп параллель дөньяларга барып чыга, дөньялар арасындагы киртәләрне уза, икенче дөнья вәкилләре белән көрәшә. Эпик герой өчен бары үзе яшәгән территория генә «үз» дөньясы булып, билгеле бер чикне узуга «ят» дөнья, икенче дөнья башлана. Ят дөнья – җир асты («Йиртөшлек»), су асты («Түләк») дөньялары булырга, яки елга, дәрья аръягында («Алып Манаш») урнашырга мөмкин. Күрше территорияләр дә «ят» дөньяга карый, ул герой яшәгән территория белән янәшә, ыру агачы Байтирәкне яки Байкаенны узгач башланырга да мөмкин (« Кузы-Күрпәч белән Баянсылу»).

Мәсәлән, «Түләк» дастанында «ятлар» дөньясы – су асты, ягъни Чачдархан патшалыгы. Җир дөньясы Күк тәңре яклавында, ә су асты дөньясына кояш яктысы үлем алып килә. Дастанда мондый эпизод бар: Түләк Аллаһы Тәгаләдән су астына кояш эсселеге, кояш яктысы җибәрүен сорый. «Ул заман кызның тәненә көн төшде, күкрәгендин кереп, аркасындин чыкты – кыз янып үлгик булды. Пулат-сарай ут кебек булды» [Дастаннар, 128]. Ягъни, җир кешеләре өчен яшәү шарты булган кояш, башка дөнья вәкилләре өчен үлем китерә.

«Йиртөшлек» дастанында да кешеләр дөньясына җир асты дөньясы каршы куела. Әмма бу ике дөнья арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләр Түләкнең дә, Йиртөшлекнең дә икенче стихия вәкилләренә өйләнүенә комачауламый. Галимнәр дастан геройларының башка дөнья вәкилләренә өйләнүен экзогам никахларның чагылышы буларак аңлаталар.

Бу дастаннарда кешеләрнең җир өсте дөньясы һәм аңа каршы «ятлар», ягъни кеше түгел затлар дөньясы сурәтләнә. «Ятлар» дөньясы су яки җир асты дөньясы булырга мөмкин, ул үлем һәм авырулар белән бәйле дөнья.

Икенче дөньяга эләгергә геройга аты, алып-каракош, сәмруг кош яки башка ике дөнья арасында арадашчы була алган затлар булыша. Яки икенче дөньяга көймә белән күчерә торган карт ярдәмгә килә. Бу ярдәмчеләр барысы да әлеге юлның бер якка гына булуын хәбәр итә, икенче дөньядан кире кайткан кеше булмый.

Эпик герой җиргә билгеле бер миссия белән туа. Ул – ярым кеше, ярым илаһи зат. Ул, анадан тууы белән җир, кешеләр дөньясына караса да, тууына илаһи көчләр сәбәпче булуны, геройның гади кеше генә түгеллеген дә күрсәтә. Кагыйдә буларак герой өлкән яшьтәге карт белән карчыктан туа. Әмма бу очрак-

та да геройның дөньяга килүе гадәти түгел, бала бирәр изге затның фатихасы белән туарга мөмкин. Яки карчык берәр ризык ашаганнан соң балага уза. Эпик геройның гадәти кеше түгеллеген күрсәткән билгеләре дә була. Бу геройның алтын чәч толымы (Кузы-Күрпәч), аркасындагы яки маңгаендагы мөһере (Алпамша) булырга мөмкин. Аның үлемсезлеге дә геройны гади җир кешеләреннән аерып куя. Күпчелек геройларның дөньяга киләсе алдан мәгълүм була, алар билгеле бер миссия үтәү өчен җибәрелә. Мәсәлән, Гесер турындагы монгол эпосында герой дөньяның дүрт тарафын дошманнардан чистарту миссиясе белән җирдә туа. Бу мотивның эзләре татар халкының алыплар турындагы дастаннарга аваздаш тылсымлы әкиятләрендә дә саклана. Диюне үтерәсе геройның исеме алдан билгеле булу шушы мотивка ишарә ясый (мәсәлән, «Таңбатыр» әкияте). Мондый күренеш әкиятләрнең дастаннардан алынган булуын да аңлатырга мөмкин.

Архаик эпосның төп идеясен тәшкил иткән галәмне яклау һәм саклау өчен барган мифик көрәш, вакытлар узу белән, «үз» җиреңне басып алучылардан саклау өчен көрәш белән алышына. Эпоста тарихилык белән миф арасындагы нисбәт дә үзгәрә. Классик эпос мифлар белән бәйләнешен сакласа да, тарихилыкка да дәгъва итә башлый. Еракта калган вакыйгалар тарихи риваятьләргә нигезләп тасвирлана, мифик вакыйгалар тарихи вакыйгаларга күчерелә. Бу очракта тарихи яки квазитарихи вакыйгалар чынбарлыктагы хәл булып кабул ителә. Әлеге әсәрләр географик атамаларын, халык һәм кабилә атамаларын, аерым шәхесләрнең исемнәрен, чынбарлыкта булган аерым вакыйга турында информация саклавы белән архаик эпостан аерылып тора. Героик эпос баштарак алыплар турындагы борынгы эпос-әкияткә якын булып, ыру-кабилә мөнәсәбәтләрен яктырта. Соңрак, төрки кабиләләр беренче дәүләтләргә оеша башлагач, эпоста да феодаль тормыш рәвеше чагыла башлый. Әйтик, хуҗалык итүдә, аучылыкка караганда, терлек асрау һәм игенчелек өстенлек ала, һөнәрчелек формалаша, индивидуаль гаилә һәм шәхси милек барлыкка килә һәм, беренче чиратта, милеккә бәйле рәвештә сыйныфларга аерылу башлана. Феодализм дәверендә героик эпос тарихи вакыйгаларны сурәтли башлый, әсәрләрдә халыкның этник тарихы, тормыш-көнкүрешенә бәйле үзенчәлекләре, йолалары, гореф-гадәтләре чагылыш таба. Героик эпос тарихи эпос буларак үсеш ала. Анда реаль тарихи шәхес, тарихи вакыйгалар героик эпос кысаларында сурәтләнә башлый. Шул ук вакытта конкрет тарихи вакыйгаларны яктырткан, реаль тарихи шәхесләргә багышланган эпоста да мифологемалар мөһим роль уйный. Хәтта тарихи прототиплары булган эпик геройларның биографиясе дә илаһи яки хөкемдар нәсел дәвамчысы рәвешендә сурәтләнә. Эпик геройның ата-бабалары турында да легендар характерда мәгълүмат бирелә. Мәсәлән, Идегәй турындагы

дастаннарда Идегәйнең шәҗәрәсе изге Баба Төкләскә барып тоташа. Икенче яктан, анасы Пәри кызы булу да Идегәйнең гадәти булмавын исбатлый.

Төрки халыкларны элек-электән янәшә территорияләрдә яшәү, тел уртаклыгы, үзара этник һәм мәдәни йогынтылар һәм бәйләнешләр, уртак тарихи шартлар бәйләп торган. Алтын Урда чорында төрки халыклар арасындагы сәяси, икътисади мөнәсәбәтләр тагын да ныгый, үсеш ала һәм мәдәни һәм рухи байлыкларны үзара алмашу әлеге бәйләнешләрнең бер нәтиҗәсе буларак кабул ителә. Бу – фольклорда бигрәк тә ачык чагыла. Алтын Урда чорына нисбәттә каралган дастаннарның күп санлы милли версияләре һәм вариантлары булу әлеге халыкларның үзара бәйләнешләрен раслый. Шул ук вакытта бер үк персонажлар, уртак сюжет һәм фабула берләштергән милли версияләр аерым эпизодларны тасвирлауда, геройны сурәтләүдә, конфликтны бәян итүдә һәрбер халыкның тормыш рәвешенә бәйле үзенчәлекләргә ия.

Татар дастаннары арасында эпос жанры формалашуның бөтен этапларын күз алдына китерерлек әсәрләр саклана. Борынгы алыплар турындагы әкияти дастаннар да («Алпамша»), героик эпос та («Ак Күбек»), тарихи эпос та («Гайса улы Амәт», «Идегей») һәм героико-романик, ягъни мәхәббәт дастаннары да («Кузы-Күрпәч и Баянсылу») бар.

«Алпамша»ның иң борынгы версиясе – VI–VIII гасырларда яшәгән алтайлыларның «Алып-Манаш» дастаны. Дастан алтай халыкларыннан башка төрки халыкларга да тарала. В.М. Жирмунский дастанның Идел буена XII–XIII гасырларда үтеп керүен яза [Жирмунский, 1958, с. 41]. Галим дастанның татар һәм башкорт халыкларында таралган вариантларында батырлар әкияти эпосына хас архаик үзенчәлекләр саклануын күрсәтә. Бу – батырның алып булуы, магик йокысы, үлемсезлек мотивы һ.б. «Алпамша» дастанының соңгы гасырларга караган татар һәм башкорт вариантларында шактый бозуларга дучар булып, традицион эпизодлар, аерым мотивлар, еш кына, мәгънәләрен дә югалта. Шулай да әлеге әсәрнең төрле милли версияләрен чагыштырып өйрәнү аны реконструкцияләргә мөмкинлек бирә.

Барлыкка килүе белән Алтын Урда чорына нисбәт ителгән «Ак Күбек» дастаны геройның дошманнар эзләп йөреп, алар белән көрәшүен бәян итә. Шул ук вакытта аерым геройның дошманнары белән көрәше нәтиҗәсендә кабиләләр арасында килеп чыккан үзара бәрелешләр феодаль төс ала. Дастан күпмедер дәрәҗәдә баһадирлар турындагы әкият үзенчәлекләрен сакласа да, ул героик эпос жанрына карый. Бер яктан, Алтын Урда чоры тарихи шәхесләренең исемнәре саклану, шул чор халыкларын искә алу, икенче яктан, әлеге вакыйганың гарәп тарихчылары хезмәтләрендә теркәлгән булуы аның тарихи нигезенә дә ишарәли.

«Гайса улы Амәт» дастаны Алтын Урдада тәхет өчен барган көрәшнең бер эпизодын тасвир-

лый. Бу – Алтын Урда тарихының Чыңгызхан нәселе дәвамчылары арасында тәхет өчен аяусыз көрәш барган иң катлаулы чоры, 1350–1380 еллар арасындагы вакыйгалар. Әсәрдә сурәтләнгән күпчелек геройларның прототиплары да мәгълүм шәхесләр – Алтын Урда ханнары.

Феодализм дәверендә эпос жанрының соңгы төре – романик иҗат итеелә. Героико-романик характердагы мәхәббәт дастаннарында егетнең үзенә насыйп кәләшне эзләп, юлга чыгуы, очраган каршылыкларны, киртәләрне үтеп, икенче дөньядан үзенә кәләш алып кайтуы сурәтләнә. Төрки халыкларның «Кузы-Күрпәч белән Баянсылу» дастаны героико-романик дастанның ачык мисалы. Л.П. Потапов әлеге дастанның барлыкка килүен XI–XII гасырларга нисбәт итә [Потапов, с. 132]. Кәләш эзләп юлга чыккан герой юлдагы киртәләрне үтеп, үзенең көндәшләреннән өстенлеген, көчен раслап, икенче дөньядан үзенә аталган кәләшне алып кайта. Мәхәббәт дастаннарында да мифологик мотивлар күп саклана.

Фольклор халык көнкүрешенең мөһим элементы гына түгел, ә тарих һәм этнография буенча мөһим чыганак та. Анда халыкның иҗтимагый мөнәсәбәтләре, ышану һәм йола эзләре, көнкүрешенә кагылышлы күп мәгълүматлар сакланган. Дөрес, халык иҗаты әсәрләрендә вакыйганың төгәл чагылышы түгел, ә аңа карата халыкның мөнәсәбәте тасвирланганын да онытырга ярамый. Фольклор текстларында теркәлгән теләсә кайсы фактның мәгънәсен һәм чынбарлыкны ни дәрәҗәдә төгәл чагылдыруын аның жанр үзенчәлекләрен, художество системасын исәпкә алганда гына билгеләргә мөмкин. Фактның дөреслеге яки үзгәртелеп бирелүе, аның чынбарлыктагыча яки идеаллаштырып сурәтләнүе, тарихилыгы яки фантазиягә корылган булуы жанрдан һәм конкрет әсәрдәге конкрет вакыйга-күренешләрнең үзара бәйләнешеннән дә тора. Бер үк әсәрнең вариантларына мөрәҗәгать итү дә кайсы фактларның традицион һәм тотрыклы, кайсыларының очраклы булуын аерырга мөмкинлек бирә.

Дастаннарда халыкның матди культурасының аерым яклары, иҗтимагый мөнәсәбәтләрен, башка халыклар белән бәйләнешләрен, гореф-гадәтләрен, йола-ышануларын өйрәнү өчен кыйммәтле материал саклана. Аларда халык тормышының төрле этаплары белән бәйле мәгълүматлар, башка чыганакларда сакланмаган кыйммәтле һәм кызыклы тарихи детальләр теркәлгән. Мәсәлән, «Түләк» әсәрендә төркиләрнең бик борынгы бер ышануларының эзе сакланган. Борынгы төркиләрдә тауларга табыну, аларны илаһилаштыру булган. Тауларны изгеләштерү турында Н.Я. Бичурин, Л.Н. Гумилев, А. Инан хезмәтләрендә мәгълүматлар бар. Тау иясенә түгел, ә тауның үзенә табынганнар. Бу – анимистик карашның аниматизм дип аталган примитив формасы. Әсәрдә Түләк туган ыруына, ата-анасына түгел, ә кат-кат Балкан тауга дан җырлый. Әлеге мәдхиядә тауларны изгеләштерү эзләре саклана.

Бәнем тауым Балкан тау,
Башы һауага чыкган тау! –
Тимер белән тайаган,
Алтын белән коршаган,
Ак мәрмәрдән йапкан тау.
..........................................
Башыбызның өстендә
Сайә булган Балкан тау.
[Госманов, 250]

Тауларны җанландыру эзләре хәзерге татар телендәге «тау башы», «тау бите», «тау сырты», «тау түбәсе», «кашлак» (тау кашы) кебек сүз тезмәләрдә дә саклана. Кешеләрдәге төрле әгъза исемнәре тауга да күчкән. Борынгы төркиләр тауның да башы, бите, кашы, сырты бар итеп күзаллаганнар.

Дастаннарда гаилә-көнкүреш, хуҗалык итү белән бәйле йола, гореф-гадәтләр, ышанулар турында да материал табарга мөмкин. Бигрәк тә туй-никах, бала туу, аңа исем бирү, күмү йолалары буенча мәгълүматлар күп саклана.

Мәсәлән, «Алпамыш» дастанының күпчелек вариантларында кияү егетләре арасында уздырылган бәйге турында сүз бара. Туй алды бәйгесендә егетләр ук аткан, көрәшкән һәм атта узышкан. Бу күренеш тормыштан алынган, ә «Йиртөшлек» дастанындагы кияүне сынау мотивы фантастик элементлар белән баетылган. Егет кызның атасы кушкан күп төрле эшләрне башкара. Шушы ук күренеш белән алтай батыры Маадай-Кара турындагы эпоста да очрашабыз. Әлеге әсәрләрдә бик борынгы заманнарда күп кенә төрки халыклар тормышында урын тоткан йола сурәтләнә: кияү, калым түлисе урында, кыз өендә берничә ел хезмәт итә.

Гадәттә, эпик геройның дөньяга килүе, исем алуы да үзенчәлекле. Еш кына балага очраклы килеп кергән кеше, ягъни гаип кунак исем куша. «Алпамыш» дастанында балага исемне бәби туена дәрвиш киемендә килгән изге Шаһимәрдән бирә. Дөрес, бу эпизод әсәрнең татар вариантында сакланмаган. Бары Алпамшаның мөһерле, ук-кылыч алмас булуыннан чыгып кына, әлеге эпизодның, кайчандыр, булганлыгы аңлашыла. Кунграт версиясендә балага Хәким дип исем бирелә. Җиде яшендә бабасы Алтынбайдан калган ундүрт батман бакырдан коелган җәяне тарткач кына аңа Алпамша исеме бирелә. Мондый гадәт күпчелек төркиләрдә булган. Абдулкадир Инан аның якутларда булуын яза: «Борынгы якутлардагы гадәт буенча, бәләкәй чакта балага биргән исем аның чын исеме дип исәпләнми. Чын исем исә җәя тартып, ук ата башлагач кына кушыла» [Инан Абдулкадир, б. 180]. Бу йола угызларда да булган. «Дәдәм Коркут» хикәяләрендә дә, углан баш кисмәсә, кан коймаса, аңа ат бирмиләр, дип язылa. Угыз кабиләләре каһарманнарына, тәүге батырлыкларын күрсәткәч кенә, дәдә Коркут аларга исем кушкан. Ә кайбер халыкларда һәр кешенең исеме булмаган. Аларны ыру исеме белән атап йөрткәннәр. А. Инан кешегә исем бирү белән бәйле төркиләрдә таралган тагын бер гадәт турында яза: «Алтай һәм Енисей төркиләренең поэмаларыннан аңлашылганча, элек шундый бер дәвер булган, ул заманда, ябай адәмнәрнең исемнәре булмаган, һәр берсе кабиләсенең

исемен йөрткән, чын исем алу өчен мәҗбүри рәвештә каһарманлык күрсәтү кирәк булган» [Инан Абдулкадир, б. 181]. Бу фактта этнограф Титов та игътибар иткән [Титов, с. 66]. «Ак Күбек» дастанында геройның туганчы ук исеме мәгълүм булуын шушы гадәт белән бәйләп кенә аңлатырга мөмкин. Көбек Алтайның Улаган аймагында киң таралган ыру этнонимы була. Дастандагы Самыр Казан, Мангыш, Көтән би дә берәр кабилә-ыру этнонимын исем итеп алганнар. Мангыш – дастанда Көтән ханның улы исеме. П.А. Фалев монголларда һәм урянхайларда мангусның явыз рух исеме булуын Мангут кабиләсе Чыңгыз хан гаскәренең нигезен тәшкил иткән батыр сугышчыларны биргән кабилә булган. XIII йөздән башлап, Мангут яки Мангус, кабилә этнонимы булу белән беррәттән, эпоста яңа мәгънә ала һәм куркыныч затны аңлата башлый.

«Ак Кубек» дастанында мәҗүсилек белән бәйле тагын бер күренеш теркәлгән. Ак Күбек, Көтен бине үтерү өчен, һава торышын үзгәртә: көнне суыттыра, су өстенә өч көн дәвамында боз катыра. Бу – тормыштан алынган йола күренеше. Борынгы төркиләрдә шаманнарның һава торышын магия ярдәмендә үзгәртүе «җада» (дьада) дип аталган. Җада күренеше белән алтай халыклары эпосында да еш очрашабыз. «Җада», ягъни «көн җадалау» эпизоды «Ак Күбек» дастанының өч вариантында да бар. Алтай вариантында «суык итте» дип бирелсә, татар версиясенең тара вариантында «Күбәк җәйләде алты көн», ә бараба вариантында ул үзенең исеме белән «көн җадалау» дип аталган. Камшаманнар җада таш ярдәмендә һава торышын үзгәрткәннәр. Җада таш тышкы кыяфәте белән кешегә охшаган, аның күзләре, борыны һәм авызы чамаланган [Алексеев, с. 40; Потанин, с. 352].

Дастаннардагы кабиләара үч алу, бер ыруның икенчесеннән кыз урлавы, батырларның икәү генә очрашып, бер-берсен сүз белән кыздырып көрәшүе, көч сынашуы һәм башка күренеш-вакыйгалар да тормыштан алынган, шул халыкның йола, гореф-гадәтләренә таянып тасвирлана.

**Татар халык дастаннарын җыю һәм өйрәнү тарихы.** Татар халык дастаннарын җыю һәм өйрәнү тарихы XIX йөздә академик В.В. Радлов исеме белән башланып китә. Атаклы тюрколог, этнограф, археолог 150 дән артык фәнни хезмәтләр авторы **Вильгельм Фридрих Радлов** 1837 елда Берлинда туа. Берлин университетының философия факультетында укыганда шәрык телләре белән кызыксына башлый. Философия буенча диссертация яклаганнан соң, урал һәм алтай телләрен өйрәнү өчен 1958 елда Россиягә килә. Бераздан Барнаул тау училищесына немец һәм латин телләре укытучысы итеп билгеләнә. 1959 елда Россиягә тугрылык турында ант бирә һәм Россия подданствосын кабул итә. Галим шул көннән Василий Васильевич Радлов исемен ала. Барнаулда эшләү дәверендә җирле төрки халыкларның телләрен һәм халык авыз иҗатын өйрәнә

башлый. Галим, 1960 елның җәеннән башлап, һәр ел төрки халыкларның тел үзенчәлекләрен һәм фольклорын өйрәнү максаты белән халык арасына чыга башлый. Ягъни, хәзерге тел белән әйткәндә, экспедицияләргә йөри. Алтайда булган дәверендә барлыгы 10 экспедициядә була, алтай, телеут, шор, куманлы, тува, казакъ, кыргыз, абакан татарлары (хакаслар), себер татарлары һәм кытайларның фольклорын һәм тел үзенчәлекләрен чагылдырган материал туплый. 1866 елдан үзенең халыктан язып алган материалларын бастыра башлый. 1866 елда «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи» дигән унтомлыкның. беренче, 1868 һәм 1870 тә икенче һәм өченче томнары дөнья күрә. 1872 елда татар фольклоры өчен хәзерге көнгә кадәр иң әһәмиятле чыганакларның берсе булган дүртенче том – «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменьских татар» нәшер ителә. Бу күптомлык үзләрендә тупланган материалның күләме белән дә, әһәмияте белән дә тиңдәшсез хезмәт була. Дүртенче томда себер татарларыннан 19 авылда җыелган йөз унбер әсәр урнаштырылган. Алар арасында дастаннар, әкиятләр, җырлар, риваятьләр бар. Мәсәлән «Ак Күбек», «Мешәк Алып», «Йәстәй Мөңке», «Кадыш Мәргән» кебек дастаннар нәкъ шушы томга кергән булу аркасында гына безнең көнгә кадәр сакланып калганнар. Бу хезмәт татар халык авыз иҗатын тикшерүчеләр өчен дә, укучы өчен дә кыйммәтле хәзинә.

Томга язылган кереш сүздә себер татарлары турында белешмә һәм китапта урын алган материалларның ни рәвешле җыелуы турында мәгълүмат бирелә. В.В. Радлов себер татарларының фольклорын җыюның катлаулы эш булуы турында да язып калдырган: «Халык риваятьләре – ата-бабаларның гамәлләре турында мәгълүмат саклаган әкиятләр, җырлар яшисен яшәгән картлар күңелендә генә сакланып калган. Бары алар гына үзләренең яшь вакытлары – халык рухы ата-бабаларның батырлыкларын мактаган җыр һәм әкиятләрне башкарырга көч биргән вакыт турында изге хатирәләр саклыйлар. Хәзерге буын, күбесенә эчтәлекләре аңлашылып җитмәсә дә, Мөхәммәдияне, Әхмәт Ясәви хикмәтләрен, Мир Али Ширне җырлыйлар.

Югарыда әйтелгәннәрдән халык әдәбияты үрнәкләрен җыюның никадәр зур хезмәт таләп итүе аңлашыла. Муллалар авыл халкына, еш кына, минем үтенечләрне үтәмәскә киңәш итәләр иде, һәм мин картлардан берәрсен таба алган очракта да, аларның яшьләре белән бәйле җитешсезлекләре һәм күп сөйләшүләре язып алу эшен катлауландыра иде. Шул рәвешле, мин нәрсә ишетсәм шуны, җыр һәм риваятьләрнең иң әһәмиятсез өзекләрен дә язып барырга мәҗбүр булдым» [Радлов, с. XIII–XIV] (мәкалә авторы тәрҗемәсе).

XIX йөз башында татар дастаннары турында беренче фи-

керләр күренә башлый. Авторлар әлеге әсәрләрне дастан дип атамасалар да, «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет», «Сәйфелмөлек» кебек әсәрләрнең тәрбияви һәм эстетик әһәмиятен күрсәтеп, аларга югары бәя бирәләр. Г. Тукай «Таһир-Зөһрә», «Йосыф» китаплары турында, «кечкенә чагында укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәктер» дип яза [Тукай, б. 185].

Татар фольклористикасында эпоска багышланган беренче фәнни хезмәт – Г. Ибраһимовның «Әдәбият кануннары» дигән китабындагы «Каһарманнар поэмасы» бүлеге [Ибраһимов, б. 68–70]. Г. Ибраһимовның бу хезмәтендә сүз бөтен дөньяга мәгълүм эпос үрнәкләре хакында бара.

Г. Сәгъди 1923 елда басылып чыккан «Әдәбият тарихымы, язмалар тарихымы?» дигән мәкаләсендә, халык батырлары җырлары, дастаннары, әкиятләре – алар татар әдәбиятының төп нигез ташы, дигән югары бәя бирә [Сәгъди, б. 41].

XIX гасырның егерменче елларында дастаннарга нигезләнеп язылган әдәби әсәрләр дөнья күрә. 1916 елда Ф. Бурнаш «Коркот» поэмасын яза, «Таһир-Зөһрә» трагедиясен иҗат итә. Шул ук елда «Аң» журналында Мирхәйдәр Фәйзи тарафыннан әдәби эшкәртелгән «Җик Мәргән» дастаны дөнья күрә. К. Юлдаш «Чура батыр» дастанын яза. Казан педагогия институты доценты Нигъмәт Хәким 1919 елда Себердә Ситдыйк Зәйнетдиновтан язып алып, «Идегәй» дастанының җыелма вариантын төзи.

1939 елда Казанда Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты оештырыла. Әлеге институтта башта фольклорны өйрәнүче төркем оеша, соңрак ул фольклор секторына әйләнә. 40 елдан, даими рәвештә фәнни экспедицияләр чыгып татар фольклорын системалы рәвештә өйрәнү башлана. 1940 елда Хәмит Ярми җитәкчелегендә В.В. Радлов эзләре буйлап оештырылган экспедиция вакытында күп санлы фольклор материалы туплана. Мәсәлән, җыелган әсәрләр арасында «Кузы Күрпәч һәм Баянсылу» дастанының бер варианты да бар. Институт тарафыннан оештырылган экспедицияләр вакытында татар халкының егерменче йөзгә кадәр сакланып калган дастаннары язып алына. Әмма 1944 елда ВКП(б) Үзәк Комитетының 9 август карары чыга: «Предложить Татарскому обкому ВКП (б) организовать научную разработку истории Татарии, устранить допущенные отдельными историками и литераторами серьезные недостатки и ошибки националистического характера в освещении истории Татарии (приукрашивание Золотой Орды, популяризация ханско-феодального эпоса об Идегее)» [КПСС в..., с. 518]. Әлеге карар нигезендә «Идегәй» дастаны гына түгел, гомумән эпос жанры фәнни контекстан төшеп кала, татар халык эпосын җыю һәм өйрәнү эше туктатыла. Халык дастаннары байлар һәм югары даирә иҗаты дип карала башлый.

Ф.В. Әхмәтова татар эпосының фәнни яктан өйрәнелә башла-

вы турында: «Татар дастаннарын өйрәнү эше төрле фәнни конференцияләрдә чыгышлар ясаудан башланды дияргә була», – дип яза [Татар эпосы..., б. 19]. 1956 елда Ташкент шәһәрендә «Алпамыш» эпосы буенча уздырылган фәнни конференциядә докладлар белән Х. Ярмөхәммәтов (Хәмит Ярми) һәм А. Вәлитова да катнаша, аларның чыгышларын татар эпосын өйрәнүдә беренче адымнар дип бәяләргә мөмкин. Бу чыгышлар фәнни җыентыкларда басылып та чыга [Тюрко-монгольское...].1964 елда Уфада «Кузы Күрпәч белән Баянсылу» дастанын тикшерүгә багышланган фәнни конференциядә Х. Ярмөхәммәтов бу әсәрнең себер татарлары версиясен тикшерүгә багышланган доклад белән катнаша. Шул вакыттан татар галимнәре дә татар эпосын тикшерүгә багышланган докладлар белән халыкара фәнни конференцияләрдә чыгышлар ясый башлыйлар (Улан-Удэ, 1973; Якутск, 1977; Элиста, 1978 һ.б.). Ф.В. Әхмәтова, Н.Ш. Хисамов, И. Надиров тарафыннан татар дастаннарының сюжет составы, әдәбият, әкиятләр белән мөнәсәбәте турында берничә доклад ясала.

Егерменче йөзнең 80 нче елларыннан татар эпосын өйрәнү ике юнәлештә алып барыла башлый. Беренчесе – эposны фәнни яктан тикшерү, анализлау; икенчесе – татар халык дастаннарын аерым җыентык итеп бастырып чыгару. Дастаннарны өйрәнү эше ике зур галим исеме белән бәйле. Ф.И. Урманчиев татар дастаннарын фәнни яктан өйрәнеп, аларны төрки эпосның аерылгысыз бер өлеше буларак карый, галимнең татар эпосын тикшергән зур фәнни хезмәте 1984 елда дөнья күрә [Урманчеев]. Шул ук елны Ф.В. Әхмәтова татар халык дастаннарын җыйнап, аерым том әзерләп бастыра [Татар халык...]. Ф.В. Әхмәтованың татар дастаннарының бүгенге торышын яктырткан, татар дастаннарын башка төрки халыклар эпосы белән чагыштырган хезмәтләре дә бар [Ахметова].

Бу хезмәтләр әлеге ике шәхеснең дистә еллар алып барган фәнни тикшеренүләренең, эзләнүләренең бер зур нәтиҗәсе булып тора.

Ф.И. Урманчиевның татар эпосына багышланган «Эпические сказания татарского народа» (1980), «По следам белого волка» (1994), «Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә» (1997), «Народный эпос «Идегей» (1999) дигән монографияләре дә дөнья күрде. Галимнең өч томлык «Татар мифлары» дигән энциклопедик характердагы хезмәтендә татар эпосының аерым сюжетлары, мотивлар, эпик геройлар турында бай мәгълүмат бирелә (2008, 2009, 2011). «Ак Күбек», «Җир Төшлек», «Түләк», «Алпамша», «Җик Мәргән», «Кузы Күрпәч һәм Баянсылу», «Алтаин Саин Сүмә» һәм башка дастаннарны тикшерүгә багышланган күп санлы фәнни мәкаләләре «Советская тюркология», «Советская этнография» журналларында чыга. Алар Венгрия, СССРда басылган җыентыкларда, газета-журналларда да даими рәвештә дөнья күрә [Каһарманнар..., б. 261–270].

Н.Ш. Хисамов Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын һәм Йосыф-Зөләйха темасына язылган төрки дастаннарны чагыштырып тикшерә, халык иҗатыннан килгән традицияләр яссылыгында карый.

Дастаннарны халыкка җиткерүдә М.И. Әхмәтҗанов зур эш башкара. Россиянең татарлар яшәгән төбәкләренә оештырылган экспедицияләр вакытында табылган һәм архивта сакланган кулъязма дастаннарны кириллицага күчереп газета-журнал битләрендә, фәнни җыентыкларда бастырып чыгара, аларны фәнни әйләнешкә кертә.

Институтның халык иҗаты бүлегендә Ф.И. Урманчиев һәм А.Х. Садыйкова җитәкчелегендә татар-төрки эпосын өйрәнүгә багышланган диссертацияләр дә якланды. Ф.И. Урманчиев җитәкчелегендә «Идегәй» дастанының тарихи нигезләрен В.И. Хәйруллина тикшерә. Л.Х. Мөхәммәтҗанова төрки халыкларның «Чура батыр» дастанының милли версияләрен чагыштырма планда анализлый (2000). И.Г. Закирова болгар дәверенә нисбәттә «Алпамыш» һәм «Түләк» дастаннарын тикшерә (2000). А.Х. Садыйкова җитәкчелегендә татар дастаннарының дини-мифологик һәм тарихи нигезләрен өйрәнүгә багышланган кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре якланды. «Идегәй» дастанының милли-мифологик һәм дини мотивларын Ф.М. Вәлиуллина өйрәнә (2005), «Түләк» дастанының милли версияләрен А.Р. Фәхретдинова тикшерә (2007), «Алпамша», «Кузы-Күрпәч һәм Баянсылу», «Ак Күбек», «Гайсә улы Амәт» дастаннарының тарихи нигезләрен һәм мифопоэтик традицияләрен И.Г. Закирова тикшерә.

**Татар дастаннарын төркемләү мәсьәләсе**. Татар дастаннарын төркемләү нигездә башка төрки халыкларда кабул ителгән классификацияләрдән нык аерылып тормый. Дастаннарны сюжеты һәм темаларына нигезләнеп берничә төркемгә аералар.

Татар дастаннарын өйрәнгән галимнәр үз классификацияләрен тәкъдим итә. Нигездә зур аерма булмаса да, бу классификацияләр белән таныштырып үтү урынлы булыр.

Ф.И. Урманчиев татар дастаннарын дүрт төркемгә аерып анализлый [Урманчеев].

1. Героик-архаик дастаннар.
2. Героик дастаннар.
3. Лироэпик дастаннар.
4. Китаби дастаннар.

Ф.В. Әхмәтованың үз классификациясе бар. Ул татар дастаннарын тематик яктан классификацияләп өч төркемгә бүлә [Татар халык...].

1. Алыплар турында хикәятләр.
2. Тарихи дастаннар.
3. Мәхәббәт дастаннары.

М.Х. Бакиров татар дастаннарын түбәндәге өч төркемгә аера:

1. Архаик-героик яки әкияти-мифологик дастаннар.
2. Классик-героик дастаннар.
3. Тарихи-героик дастаннар.

Классификацияләүдә аерымлыклар башка халыклар фольклористикасында да очрый. Алар нигездә бер-берсе белән каршылыкка керми. Бер үк төркемне синонимик тер-

миннар белән атауга, яки бер үк дастанны төрле яктан анализлауга нигезләнә. Димәк дастаннарны төркемләүнең шактый ук шартлы булуын да истән чыгарырга ярамый. Беренчедән, бер үк дастанны төрле яктан анализлап, берничә төркемгә кертергә мөмкин. Мәсәлән, «Йиртөшлек» дастанын архаик дастаннарга да, эчтәлегенә нигезләнеп мифологик дастаннар төркеменә дә кертергә була. Шул ук вакытта «Йиртөшлек» дастаны батырлар турындагы дастан буларак та анализлана ала. Татар халкының «Ак Күбек» дастаны, бер яктан, тарихи вакыйгаларны чагылдырса, икенче яктан, алыплар турындагы дастаннарга якын тора. «Түләк» дастаны бер яктан, параллель дөньяларны тасвирлавы белән мифологик дастаннарга туры килсә, икенче яктан, ул мәхәббәт дастанының ачык мисалы булып тора. Татар фольклористикасында классификациядә тәңгәллек яки бертөрлелек булмау күренеше жанрның чагыштырмача яңа өйрәнелә башлавын, терминнар мәсьәләсенең җитәрлек эшләнеп бетмәвен күрсәтә. Әмма бу принципиаль җитешсезлек түгел, эшнең дәвам ителүен күрсәтүче бер күренеш кенә булып тора.

Татар фольклорында дастаннарны классификацияләүдә аларның төп ике төркемен күрсәтү мөһим: китаби һәм традицион дастаннар. Алар икесе дә шартлы атамалар гына. Китаби дастаннарга китап булып басылып чыккан дастаннар да, шәкерт дәфтәрләренә күчерелеп, безнең көннәргә килеп җиткән әсәрләр дә, кульязма китапларда сакланган кыйссалар да керә. Аларны берләштерүче төп билге – таралу һәм саклану рәвешенең язмача-басмача булуы, башкарылу рәвеше исә, кагыйдә буларак, кич утырулар вакытында яисә шәкертләр арасында кычкырып уку. Ә традицион дастаннар бары телдә генә саклана, телдән башкарыла, дөресрәге, аерым кешеләрнең – чичән яки акыннарның хәтерендә саклана. Тагын бер искәрмә бар: халыктан XVIII–XIX гасырларда язып алынган әсәрләр, еш кына, дастаннарның кыскартылган эчтәлеге, аерым шигъри өзекләре генә дастаннарның чагыштырмача үзгәрешсез сакланган өлешен тәшкил итә.

Бу бүленеш дастаннарның саклану һәм башкарылу рәвешенә бәйле. Шул ук вакытта традицион дастаннарның да, язма дастаннарның да үз эчләрендә тематик бүленеш бар. Югарыда тәкъдим ителгән классификацияләр шуларның тематик үрнәкләре булып тора.

Дастаннарны тематик яктан классификацияләгәндә түбәндәгеләрне күз алдында тоту кирәк (галимнәр арасында бер тематик төркемне төрлечә атау кабул ителгән. Терминнарда кабул ителгән бердәмлек юк):

1. Каһарманлык дастаннары. Аларны фәндә алыплар турындагы хикәятләр, героик дастаннар яки батырлар эпосы дип атау да кабул ителгән.

2. Мәхәббәт дастаннары. Романик яки лироэпик дастаннар дип атау да очрый.

3. Тарихи дастаннар.

Батырлар турындагы яки каһарманлык дастаннарын үзләрен ике төркемгә аерып (героик-архаик һәм героик) атау да кабул ителгән.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин, татар халкында борынгы алыплар турындагы әкияти дастаннар да («Алпамыш»), героик эпос та («Ак Күбек»), тарихи эпос та («Гайса улы Амәт», «Идегәй») һәм героико-романик, ягъни мәхәббәт дастаннары да («Кузы-Күрпәч һәм Баянсылу») бар.

**Әдәбият**

Каһарманнар йолдызлыгы. Тарихи-фольклористик очерклар. Казан, 2006.

*Алексеев Н.А.* Ранние формы религии тюркоязычных народов Сибири. Новосибирск: Наука, 1980. 317 с.

*Ахметова Ф.В.* К сравнению якутско-татарских эпических связей // Эпическое творчество народов Сибири и Дальнего Востока. Якутск, 1978. С. 124–129.

*Ахметова Ф.В.* Татар дастаннарының бүгенге яшәеше // Татар халык иҗатының хәзерге торышы. Казан, 1988.

*Бакиров М.Х.* Татар фольклоры. Казан: Мәгариф, 2008. 359 б.

*Госманов М.Г.* Каурый каләм эзеннән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 463 б.

*Жирмунский В.М.* Некоторые итоги изучения героического эпоса народов Средней Азии // Вопросы изучения эпоса народов СССР. М.: Издательство АН СССР, 1958.

*Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974.

*Ибраһимов Г.* Әдәбият кануннары. Казан, 1918.

*Инан Абдулкадир.* Шаманизм тарихта һәм бөгөн. Өфө: Китап, 1998. 180 б.

КПСС в резалюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК (1898–1986). Т.7. 1938–1945. М.: Политиздат, 1985.

Литературный энциклопедический словарь / Под общей ред. В.М. Кожевникова и П.А. Николаева. М.: Советская Энциклопедия, 1987.

Мифы народов мира. Энциклопедия в 2-х т. / Гл. ред. С.А. Токарев. М.: Сов. Энциклопедия, 1992.

Народный эпос «Кузы-Курпес и Маян-Хылу». Уфа, 1964.

*Патов Л.П.* Героический эпос алтайцев // Советская этнография. М., 1949.

*Потанин Г.Н.* Тунгутско-тибетская окраина Китая и Центральная Монголия. Т. II. СПб., 1893. 352 с.

*Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и дзунгарской степи. Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар. СПб., 1872.

*Сәгъди Г.* Әдәбият тарихымы, язмалар тарихымы? // Безнең юл. Казан. 1923. № 1.

Татар халык иҗаты. Дастаннар / төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы, сүзлекне әзерләүче Ф.В. Әхмәтова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 384 б.

Татар эпосы. Дастаннар / төзүче, кереш сүз һәм искәрмәләрне язучы, сүзлекне әзерләүче Ф.В. Әхмәтова-Урманче. Казан: Раннур, 2004.

*Титов.* Богатырские поэмы минусинских татар. Петербург, 1856.

*Тукай Г.* Әсәрләр. 5 томда. Т. 4. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.

Тюрко-монгольское языкознание и фольклористика. М., 1960.

*Урманчеев Ф.И.* Героический эпос татарского народа: исследование. Казан: Татар. кн. изд-во, 1984. 312 с.

*Фалев П.А.* Ногайская сказка об Ак Кобеке // Сборник музея антропологии и этнографии при Российской Академии наук Т. 5. Вып. 1. Петроград, 1918.

*Хисамов Н.Ш.* Бөек язмышлы әсәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.; Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул ‘Али. М.: Наука, 1979.

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,*** *филология фәннәре докторы,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

## Ак Көбек
(Бараба варианты)

Инәсенең карнында Ак Көбек йөрде, туар вакытына җитте. Җиңгәләре килде инәсенә, янына инәсенең утырдылар. Ак Көбек инәсеннән тумады, таң калдылар. Инәсенең карнында Ак Көбек сүләшеп торды: «Мин тумаймын бу юлыңнан, карынның бер ягыннан җыртып чыгармын!» – диде. Җиңгәләре әйтте:

Алтын бишеккә бер салып
Биләр идек Көбәйне,
Көмеш бишеккә бер салып
Биләр идек Көбәйне.

Инәсе әйтте баласына: «Балам, син Ходай яраткан юлыннан чыкмасаң, минем ризалыгым юк». Ак Көбек аннан соң Ходай яраткан юлы белән туды. Торды, атасының кылычын толымына бәйләде, китте ялангач (көе) күлгә аулап балык тотарга. Бер үзәнгә барып төште, бер карт үзәннең янында балык тотып ята. Ак Көбек аңа килде.

Кара әле, кара әле, таз-ай!
Сулар төбен күргән таз-ай!
Бер балык тоткан таз-ай!
Инәм инәмгә изүлек-ай!
Инәм инәмгә изүлек-ай!

Бер чабак сорады. Карт орышып аны: «Фу, кит бу җирдән, сиңа бирергә һич нәрсә балыгым юк», – диде. Ак Көбек үзән белән йөреп китте, анда барды, тагы бер балык тотучы картка җитте. Ул картның янында бер чуртан ятадыр. Ак Көбек аңа килде, әйтте:

Кара әле, кара әле, таз-ай!
Сулар төбен күргән таз-ай!
Бер балык тоткан таз-ай!
Инәм инәмгә изүлек-ай!
Инәм инәмгә изүлек-ай!

Карт әйтте: «И балам, ал бу балыкны ялгыз булса да». Бала бу балыкны алды, капчыгына салды, кайтты кире. Көз вакыт иде, су тонган икән, бер сулыкка Ак Көбек карап күрде, алабуга алабуганы куып йөри, чуртан чуртанны куып йөри, аны күрде Көбек. Аны күреп Көбек әйтте: «Суда балык яу кубара», – диде: «Мин монда тудым, адәм булып мин дә яу күтәрим», – диде.

Аннан кайтып йөреп барса, үзәннән кырга чыккан җирдә, Көден хан алты аяклы аргамакка менеп саклап тора. Бая ялангач суга йөргән баланы күреп Көден хан әйтте бу балага: «Атың кем?» – диде. Бу бала әйтте: «Ак Көбек кеше, синең атың кем?» – диде. Көден хан әйтте: «Атым минем Көден хан». Ак Көбек әйтте аңа:

Көден, көден (дип) дәшәрләр-ай
Атта күрәмен көденне-ай
Атта күрәмен көденне-ай
Көденге диеп аталган-ай
Син дә бер кеше булыпсың-ай.

Ак Көбек әйтте: «Минем атым Ак Көбек», анда Көден хан әйтеп ятты Ак Көбеккә:

Күбек, күбек (дип) дәшәрләр-ай
Күлдә күрәмен күбекне-ай,
Сөттә күрәмен күбекне-ай,
Күбек диеп аталган-ай

Син дә бер кеше булыпсың-ай!

Ак Көбек атасының кылычын алды, алты аяклы аргамакның бер аягын кисеп алды, Көден хан нәмә белми өенә кайтып китте. Ак Көбек тә өенә кайтып барды, килде инәсенә. Инәсенә Көден хан аргамагының алты аягыннан кисеп алган бер аягын бирде, чуртанны да бирде. Инәсе аларны казанга салып кайнатты. Ашадылар, җыйдылар. Ак Көбек әйтте инәсенә: «Мин менәр ат бармы инә?» – диде. Инәсе әйтте: «Син минем карнымда йөргән вакытта бер бия җиленләде унике ай, ул бия инде колынлаган булмак», – диде. «Аным туган колыны син менәр ат ул булыр». Ак Көбек йөгән бау алды, Ак Көбек үргә китте. Барды. Биядән Кызыл Ор туган. Кызыл Ор биянең биле өстеннән ашыра муйным салып, ар ягыннан имчәген авызына алып имеп тора.

Килде Ак Көбек Кызыл Орны колактан тотты, йөгәнләде, өенә алып барды, кайтып өендә иярләде, тун-шайларын киде, бер шәһәргә чыкты. Анда алтмыш алты балта урлап алды; бер башка авылга барды, җитмеш җиде балта урлап алды.

Аннан чыгып килеп Кытай җиренә китте, кылыч сугучы оста кешене эзләп йөрде. Анда барып бер Күчемеч атлы останы тапты. Балталарны Күчемечнең алдына тыкты.

Алтмыш алты балтаны сызгыртып
Саф булатны калдыргыл!
Җитмеш җиде балтаны сызгыртып
Саф булатны калдыргыл!
Күчемеч оста булсаң
Ул булаттан кылыч суккыл!

Күчемеч оста бер көн, бер төн сукты, кылычны бетерде, Күчемеч алты балтаны җуеп яшерде, кылычны алып китерде, Көбеккә бирде. Көбек кылычны кулына алып салмаклады [*чамалап карады*].

Алтмыш алты балтаның ай
Алтысы кайда, Күчемеч-ай?
Алтысын ялгап сукмасаң-ай
Башыңны кисәрмен, Күчемеч-ай.
Җитмеш җиде балтаның-ай
Җидесе кайда, Күчемеч-ай?
Җидесен ялгап сукмасаң-ай
Башыңны кисәрмен, Күчемеч-ай.

Күчемеч кайтты, курыкты, алты балтаны кагып кушты, җиде балтаны янә кагып кушты, өч көн суккач, бетереп кылычны алып килде Көбеккә, кылычны кулына тоттырды. Ак Көбек кылычны башыннан тотып салмаклап әйләндерде, көнгә тотты, кояш багып күренде. Ак Көбек бу кылыч(ны) яхшы дип тапты. Күчемеч Көбеккә әйтте: «Кылычны ярар дисәң инде ял бирмәк кирәк». Ак Көбек торды, Күчемечне мактады:

Сугуына чыдамый,
Сум чүкечләр уалды,
Басуына чыдамый,
Кап күрекләр ярылды,
Андый минем Күчемеч-ай!
Мондый минем Күчемеч-ай!

Торга [*ефәк тукыма төре*] булсын
бу җирдән-әй!
Камга [ефәк тукыма төре] булсын
бу җирдән-әй!
Ишегеңнән так [*байлык*] иңсен-әй!
Төнлегеңнән так төшсен-ай!
Атың-елкың бай булсын!
Баеп-череп үлерсең!

Бу мактаганнан башка ял бирмәде, кайтты аннан соң Ак Көбек өенә. Дәрья якасына барып Ак Көбек бер таз тайга менде, бер киез такыяны [баш киеме] киде, бер киез тунын киде, малын багып ятты. Анда багып йөргән чагында Самыр Казан Алып Ак Көбеккә килде. Ул Ак Көбекнең карт бабасы иде. Самыр Казан әйтте: «Бу кемнең малын багып торасың, таз кол!» – диде. Ак Көбек әйтте Самыр Казанга: «Ак Көбекнең малын багып ятам», – диде. Самыр Казан алып әйтте: «Ак Көбек үзе кайда киткән?» Ак Көбек әйтте: «Ак Көбек ялангач (көе) бу күлгә кышлагалы [*кышларга*] китте». Самыр Казан әйтте: «Кичәге көн-төн

бүгенге көн минем белән мәсләште [*киңәшләште*], минем диңгезем ул поклап яткан тору», – диде.

Самыр Казан дәрьяның уртасына барып суга утырды, дәрьядан ялгыз башы чыгып калды. Ак Көбек коралларын алды, яхшы туннарын киде, кылычын бәйләде, атка менде, көн җадалады [*магия ярдәмендә һава торышына тәэсир итте*].

Яхшы көндә бер әйтсәм-ай
Көн төшер, Ак Көбек-ай
Яман көндә бер әйтсәм-ай
Көн ярәшер, Ак Көбек-ай.

Бер җиде көн җадалады, җиде карыш боз туңдырды; җиде көн җадалагач Кызыл Орына менде, кылычын кулына алды, дәрьяның уртасында утырган Самыр Казан алыпка барды, башын кисәргә килде. Самыр Казан аны өргән иде, тау башына атылып чыгып китте. Янә Ак Көбек Самыр Казанга кире кайтып килде, үтермәкче булды. Самыр Казан тагы өреп тау башына чыгарды. Өченче кире тагы килде. Самыр Казан әйтте: «Ак Көбек, син алдархәйләкәрсең, инде мине бу кылыч белән үтерә алмассың. Кире кайтып бар! Кырда кылычым ятыр. Син бу кылычымны ал! Ул минем башымны кисәр». Аннан барып кылычын алып Самыр Казанның башын кисеп китте. Самыр Казан Алып тубулады, җиде карыш боз туңдырды, боздан Ак Көбекнең малы егылды, кырылды, Ак Көбек үзе тере калды.

Маңгуш алып Көден ханның улы үз җирендә төскә [*урман*] чыккан иде, төсләп йөрде, бер ак киекне үтерде. Анда йоклап яткач Маңгушның колы киекнең итен пешерер иде. Самыр Казанны үтергәндә боз шаулаганын ишеттеләр.

Маңгушның колы әйтте:

– Көзгедә бозлар гүләшер-ай,
Ул ни иде, Маңгушым-ай?
Язгыда бозлар шаулашыр-ай,
Ул ни иде, Маңгушым-ай?

Маңгуш уянып башын күтәреп әйтте:

– Көзгедә бозлар гүләшер-ай,
Куяклар савыт [*көбә күлмәк*]
булмасмы икән?
Язгыда бозлар шаулашыр-ай,
Кылычлар белән булмасмы икән?

Ак Көбек юыртып килә бәйләп, кылычын тагып, йыдасын [*сөңге очы*] турылап сөңгесенең, бер җай белән киләдер, Маңгушның колы Ак Көбекне күрде.

Уң ягында турайганы,
Су ягында сурайганы [*кыегайган*],
Ул ни икән Көбекнең-ай?
Кызыл Орның басуы-ай
Элекке басуы әбәс тур-ай [*түгел*],
Ак Көбекнең күзләре-ай
Элекке күзләр әбәс тур-ай.

Маңгуш торды, Ак Көбекнең килә ятканын күрде, Маңгуш әйтте:

Уң ягында турайганы
Йыдалар мылтык булмас микән?
Сул ягында сурайганы
Уклар саудак булмас микән?
Кызыл Орынны басуынай
Аркасына камчы тигәндер-ай.
Ак Көбекнең күзләренәй
Аракы буза чыккандыр-ай.

Ак Көбек юыртып җитеп киләдер. Маңгуш ягысының керешен салдырырга баскан чакта, ул сынып китте. Ак Көбекнең алдына чыгып утырды. Ак Көбек чабып килде, Маңгушның колы ак киекнең пешкән ботын алып атты. Ак Көбекне җиргә төшермәде, кулы белән тотты, ат өстендә ашады. Килде Маңгушның одауына [*шалашына*] Көбек. «Аш җыешкан яулашмас, диде, дус булаек! Минем йортыма бараек!» – диде. Чакырып китте. Маңгушның колы өенә кайтты, Маңгуш үзе Ак Көбек белән барды; йортына алып барды, сыйлады арацан корацан [*сөттән ясалган аракы*] белән, куйлар, үгезләр суеп ашатып ятты аны.

Маңгуш әйтте Ак Көбеккә: «Син миңа кушлугыңны сылагыл [бир] ». Ак Көбек әйтте: «Юк, җизнә, кушлугымның бәясе кыйммәт». Кактан [*күл, сазлык эчендәге*

*утраучык*] какка чабар кушлугым,
Казларның башын чабар кушлугым,
Күлдән күлгә чабар кушлугым,
Үрдәкләрнең башын чабар
кошлыгым.

Маңгуш әйтте: «И Көбегем, бу кушлугыңның һөнәре яман икән». Кебек әйтте: «И, Маңгуш, син бөркет кошыңны сылагыл миңа!» Маңгуш әйтте: «Юк, җизнә, бу бөркет кошымны сыламаймын, бу кошымның бәясе кыйммәт икән», – диде.

Цөдерер [*ау кошының табышны*
*тибеп алуы*] яхшы цөдерер-ай,
Кырык бер марал цөдерер-ай,
Цөдерер белмәгән ул яман-ай,
Атыңнын башын цөдерер-ай,
Үзәңнең башын цөдерер-ай.

Көбек әйтте: «И Маңгуш, синең бөркет кошыңның һөнәре яман икән, миңа кошың кирәк түгел, калсын синдә». Аннан соң Маңгуш әйтте: «Кушлугың яман торыр Кызыл Орыңны сылагыл миңа!» Көбек әйтте: «Кызыл Орымны сыламаймын, аның бәясе кыйммәт тора», – диде.

Кызыл Орым холыклы,
Койган камыш колаклы,
Тустагандай тояклы,
Сарымсактай азулы [*тешле*
*(азу теш)*],
Бәясен җиткерсәң алырсың,
Бәясен син җиткермәсәң
Кызыл Орым калыр үземә.

Аннан койдылар, аш җыйдылар, арацан корацан эчтеләр, исерек булдылар. Кичкә төн булды. Маңгуш исереп егылды, Ак Көбек әйтте үзенә: «Бу Маңгушны үтерергә кирәк», – диде. Бау белән баглады. Маңгушны бәйләде, бау өзелде. Бау өзелгәндә алты яшьле үгезләрнең тиресеннән ясаган каеш аркан белән бәйләде. Шул ук заманда бәйләгән каешы өзелеп китте, тузәлмәде. Каеш өзелгәнгә Ак Көбек тимердәй богау салды. Маңгуш кыймылдап бирсә, тимер дә сынып китә. Аннан Ак Көбек урамга чыкты бау эзләп. Урамның ул читендә бер ак сакаллы карт кеше килә иде. Карт килде Ак Көбекнең катына. Ак Көбек әйтте картка: «Ирне бәйләргә нәрсәнең тиресе чыдам булыр?» – диде. Карт әйтте: «Ир бәйләргә ир тиресе яхшы булыр», – диде. Ак Көбек әйтте: «И карт, сүзең чын булса, ир тиресе яхшы булса, син тиреңне миңа бир! Ашыңны ашагансың, яшисеңне яшәгәнсең». Ак Көбек картның маңгаена чиертте, үтерде, артының телде тиресен, аягының телде тиресен, кулыннан телде тиресен. Картның сөяген уалады, пилген ташлады, тиресе калды. Алып калды бу картның тиресен, Мангушның кулын кеше тиресе белән бәйләде. Ташлап китте Мангушны. Кунып йоклап калды, кулы-аягы бәйләгән көйгә. Иртән исереге сарыкты, савыкты, уянды. Үзе бауда ятыр, аны күрде. Ак Көбекнең агасы бар иде, олы кызы Маңгушның янында утырды. Ул кыз күптән Маңгуш белән уйнаш иде, бу кызның аты Көн Сылу иде. Көн Сылу Маңгушны күреп әйтте:

– Алтын аякка бал коям-ай,
Эчәр булсаң, Маңгышым-ай;
Көмеш аякка бал коям-ай
Эчәр булсаң Маңгушым-ай.

Маңгуш әйтте кызга:

– Алтын аякка бал көеп-ай
Атаңа кыя аш чәчкел-ай!
Көмеш аякка бал коеп-ай
Иңәңә кыя аш түккел-ай!

Толымыннан тотып типте Маңгуш, җиленә Көн Сылуның бер күзе чыкты. Инде Ак Көбек килде атын иярләп. Маңгушның ак бүз атын иярләп китереп, ул үзенең атына аркан җигеп Маңгушны өйдән сөйрәтеп алып китте. Кабыргасына таш тигәндә ут чыкты. Ак Көбек әйтте:

– Кабыргасыннан ут чыккан
Атасы күрсен: бу кыен-ай!
Күкрәкләреннән ут чыккан
Инәсе күрсен: бу кыен-ай!

Ак Көбек Маңгушны Күрләк [*гөрләп, чылтырап аккан*] дигән

җиргә алып барды, алып барганда Ак Көбек әйтте: «Йә, Маңгуш, әҗәлең монда булсынмы?» Маңгуш җирдә ятып әйтте:

– Күрләк дигән олы су ай
Көр адәмнең йорты иде-ләй,
Начар бичә бер алып-ай
Салып киткән йорты иде-ләй.

Аннан тагын сөйрәтеп алып китте, аны алып киткәч Шарлак [шарлап аккан] дигән үзәнгә барды. Ак Көбек әйтте: «Йә, Маңгуш, монда әҗәлең булсынмы?» – диде. Маңгуш җирдә ятып әйтте аңа:

Шарлак тигән олы су-ай
Шәр [*бай, дәрәҗәле кеше, кенәз кебек титул*] адәмнең йорты иде-ләй,
Явыз бичә бер алып-ай
Салып киткән йорты иде-ләй.

Аннан тагы аны сөрәтеп алып китте, кабыргасына таш тигәндә ут чыгарды, күкрәгенә таш тигәндә очкын чыгарды. Ак Көбек аны күреп тагы әйтте:

– Күкрәкләреннән ут чыккан-ай
Атасы күрсен: бу кыен-ай!
Кабыргасыннан ут чыккан-ай
Инәсе күрсен: бу кыен-ай!

Манар тау башына алып чыкты. Көбек әйтте: «Йә, Маңгуш, әҗәлең монда булсынмы?» – диде. Маңгуш әйтте: «Йә, булсын минем әҗәлем монда», – диде. «Инде мине үтер! Кылыч белән башымны кисәрсең!» Ул: «Минем башымны үзеңнең башыңа тот! Миндәй алып булырсың, – диде, – йөрәгемне чокып алып йөрәгеңә тот! – диде. Миндәй алып батыр булырсың, – диде, – эчәгемне алып чорнал! Миндәй алып батыр булырсың». Ак Көбек Маңгышны башын кисеп үтерде, башын кисеп башына тотарга теләде. Бер җирдән бер ак сакаллы кеше килде, әйтте: «Ак Көбек, ни кылып торасың?» Ак Көбек әйтте: «Мангушны үтердем, башын алып башыма тотарга телим», – диде. Ак сакаллы кеше әйтте: «И Ак Көбек, башыңа башын тотма! Бу башын кыя тауга ташла!» Тау башына башын ташлады, таш җимерелеп төште. Ак сакаллы кеше әйтте: «Йөрәген алып тирән күлгә ташла!» – диде. Йөрәген аңа ташлады, ул тирән күлнең суы кайнап бетте. Ак сакаллы кеше янә әйтте: «Эчәген, алып, бу бай тирәкнең башына ташла!» – диде. Эчәген алып бай тирәкнең башына ташлады, бай тирәк башыннан көеп тамыры белән көеп китте. Ул карт әйтте Ак Көбеккә: «Мин булмасам син үләр идең».

Аннан кайтты Ак Көбек йортына. Көденнең халкы Маңгушны Ак Көбек Манар тау башында үтергәнен белде. Маңгушның атасына әйтергә кирәк. Йортында Маңгушның улы унике яшәр бала булды. Картлар аны өйрәттеләр: «Атаңны Ак Көбек Манар тау башында үтергән; аны карт атаңа – Көден ханга әйт!» – диделәр. Бала барды карт атасына өйрәткән сүзне әйтергә:

Маңгуш бием мартлап [*йоклап (мәрткә китү)*] тор-ай,
Манар тау башында йортлап тор-ай,
Сәлам бирсәм дә алу юк-ай,
Сакалдан капсам да җавап юк-ай.

Көден хан аны орышты. «Бу бала ни-ни сөйлидер?» – дип әйтте. Көден ханга халык әйтте: «Маңгушны Ак Көбек Манар тау башында үтереп киткән». Коден хан улының үлгәнен белеп кайгылы булды, сыктады. Инде җиде йөз чирү коралландырып Көден хан: «Ак Көбекне яуларга кирәк», – диде. Җиде йөз чирү белән коралланып чыкты. Ак Көбекнең йортына китте, яу белән. Төнлә бардылар, урта юлга җиттеләр. Анда Ак Көбек белде: «Көден хан җиде йөз чирү белән миңа яу белән киләдер», – диде. «Алай булса, мин дә коралланып каршы чыгыйм!» – диде. Ак Көбек күп кеше алмады.

Талым Коцаның таз улы,
Чуен төбе Чуп Чура,
Казан төбе Кап Кара,
Солым – Ак Көбекнең агасы,

Биш кенә кеше каршы чыкты. Ак Көбек агасына үр айгырын мендерергә алды. Киттеләр каршы. Анда барганда алабуга балыклар канатларын судан чыгарып күрсәтеп йөриләр. Кырда йөргән Солым балыкларның күрсәткән канатларын күрәдер, әйтте:

Караганга күрсәт,
Миңа нәрсә күрсәтәсең?
Көдерәйгәнгә көдерәй
Миңа нәрсә көдерәясең?

Көден ханга барды Ак Көбек кешеләр белән. Көден ханның халкы әйтте Көбекнең кешеләренә:

– Талым Коцаның таз улы
Талкан сугарга килгәнме
Чуен төбе Чуп Чура
Чуен басарга килгәнме?

Аннан Ак Көбек үзе Көден ханның халкына керде, аларны кылыч белән кырып бетерде. Ак Көбек белән Көден хан икесе очрашты, найза [*сөңге төре*] белән чәнчештеләр. Көден хан Ак Көбекне йыда [*сөңге төре*] белән үтәли чәнечте. Ак Көбек әйтте:

– Чәнчүең дә бар икән-ай,
Күтәрүең дә юк икән-ай.

Көден хан Ак Көбекне йыда белән күтәрде, үз өстендә тотты, Йыданың очында әйтте Ак Көбек:

– Күтәрүең да бар икән-ай,
Селтәвең дә юк икән-ай.

Көден хан йыдасын селтәгәч Ак Көбек йыданың сабынаябышып, тотынып шуып төшеп киләдер. Ул төшкәч кылычын суырды, Көден ханның башын кисеп атты. Көден хан әйтте: «Бүрегем йыгылды», – диде. Ак Көбек йыданы чыгарып ташлады. Кызыл Орына менде, өенә кайтты, Көден ханның кешеләре бер агач алды, муенның сөягенә тыгып куйдылар, ул агачка Көден ханның кискән башын бәйләделәр. Көден хан тере булды, кайтты үз йортына. Көден ханның чирүенең тереләре кайтты, үлгәннәре калдылар.

Көбек яудан кайтты. Ак Көбек алтмыш алты яра белән чыкты, кояш нуры яраларга төшсә, икенче яктан күренер иде, алай булса да үлмәде. Кызыл Ор аты җитмеш җиде яра белән чыкты. Ак Көбек төрле яхшы һөнәрле кеше иде; яралы булганга, ядыганын [*чиртеп уйный торган кыллы музыка коралы*] бер агачка элеп салды, чиртергә көче юк иде.

Каен агачлар ботагы-лай
Сыгылса да сынмас булгай лай,
Исән булсам да килермен-ай,
Төгәл торсам да алырмын-ай.

Аннан китте, камчы сабы белән җирнең кашына таянып, чак кына кайтып барадыр; бер җирдә имән агачка килде, аның ботагына кыцагын [*скрипка*] элеп куйды:

– Имәннәр агач ботагы-лай
Иелсә дә сынмас булгай-лай,
Исән булса да килгәймен-ай
Төгәл торсам да алгаймын-ай.

Аннан китте, барып-барып бер җиргә килде, бер уалган арба анда ятыр, аның алдына килеп торды Ак Көбек.

Алтмыш алты кәгәйле ай
Бу арба нидән уалган ай?
Җитмеш җиде кәгәйле ай
Бу арба нидән уалган?
Алтмыш алты яралы ай
Ак Көбек нидән үлмәгән ай?
Җитмеш җиде яралы ай
Кызыл Ор нидән үлмәгән ай?

Аннан камчысын алды, сукты, арба йөреп китте. Ак Көбек юлы белән китте, барып ятса, бер җирдә бер ак кош үлгән, аның канат йоннары җирдә ята, Ак Көбек аны күреп әйтте:

– Алтмыш алты кавырсынлы-ай
Бу ак кош нидән үлгәндер-ай?
Җитмеш җиде кавырсынлы-ай
Бу ак кош нидән үлгәндер-ай?
Алтмыш алты яралы-ай
Бу Ак Көбек нидән үлмәгән-ай?
Җитмеш җиде яралы-ай
Кызыл Ор нидән үлмәгән-ай?

Ак кошның йонына камчы белән сукты, ул ак кош очып китте. Аннан Ак Көбек йортына кайтып китте. Үзенең шәһәренең юлына төште, шәһәренә якынлашты; юл кырында бер күл бар иде, анда кызлар, хатыннар җитен тартып яталар. Ак Көбек йыдасын алды, йыда белән ул хатыннарның, кызларның күлмәген ыштанын ертып, тартып алды; үзенең алтмыш алты ярасына, атының җитмеш җиде ярасына тутырды, җил тимәсен дип. Хатыннар, кызлар ялангач сыкташып калдылар. Ак Көбек юл белән акырын лап юртып барыр иде. Хатыннар, кызлар аны күрде, Ак Көбеккә әйттеләр:

– Алтмыш алты ялары-ай
Акылын куймас Ак Көбек-ай;
Җитмеш җиде яралы-ай
Холыгын куймас Ак Көбек-ай,
Яхшы җирем дошманы-ай,
Яман җирем олысы-ай
Анда салсаң Ак Көбек-ай
Анда салсаң Ак Көбек-ай.

Ак Көбек тыңламады, ыштанын, күлмәген салмады, барып китте. Йортына барды, шәһәрнең читендә күп кеше гүр ясадылар. Ак Көбек ул кешеләргә килде. «Бу кемнең гүрен казып яталар?» – диде. Ул кешеләр әйттеләр: «Ак Көбек яралы килә, аның гүрен казып ятабыз», – диделәр. Ак Көбек әйтте: «Инде мин үләменме? Бу җирдә ятармынмы?» Ак Көбек саудагын гүргә төшерде, әйтте: «Чынлап та үләр булсам, төбенә төш! Терелсәм, тола төш». Саудагын салгач, көбә күлмәген да салды, түбәндә ятты саудагы, куягы. Инде Ак Көбек аты белән гүргә керде, ятты, кешеләр аны күмделәр. Элек куркак агасы Солым яудан качып кайткан иде. Гүрнең янында торган Солым агасына Ак Көбек әйтте: «Көден хан йортында янә җиде йөз чиру җыеп, җиде йөз чиру белән тагын килер. Җиде йөз чиру белән Көден хан килгәндә миңа тавыш бирерсең! – диде. – Анда мин торып чыгармын».

Инде күмеп ташладылар. Ак Көбек ике кунды, өч кунды күмгәч. Өч кунгач Ак Көбек гүрендә Солым агасы аракы эчте, буза эчте, исерек булды. Солым агасы: «Ак Көбек үлгән булыр, – диде. – Үлгән кеше гүрдән чыгалмас», – диде, терелүенә ышанмады, «Үлгән кеше терелмәс кой», – диде. – Мин аңа барып аны камчы белән сугаем!» – диде. Солым агасы бер атка менде, камчы алып гүргә китте, гүрнең катына барды. «Ак Көбек тор! – диде. – Ни эшләп ятасың?» – диде. Гүренә камчы белән сукты. Коралларын алып атына менеп, гүрне ертып, Ак Көбек аты белән чыгып килде. Өч кабат чабып әйләнде чүлне, Көден ханның чирүен эзләп, һич кешене күрмәде. Кайтып килде Солым агасына. Ак Көбек әйтте: «Көден ханның явы кайда? Ни күренми?» – диде. Солым агасы әйтте: «Көден хан чиру белән килмәгән, мин, үлгән кеше терелмәс дип, сынамакка суктым иде», – диде. Ак Көбек әйтте: «Инде миннән соң үлгәннәр терелмәсен! Инде мин үләмен, минем яраларым ачылды, җиде кунарга бирмәдең», – диде. Аннан гүренә аты белән кереп китте, үлеп калды.

УДК 94
*З.Г. Гарипова*

# МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ ТАТАРЛАРНЫҢ МИЛЛИ-МӘДӘНИ ТОРМЫШЫ (1905–1907 еллар)

Статья освещает культурную жизнь татарских общин Китая, Японии, Турции и др. Особое внимание уделено организации печатного дела, литературному наследию татар, вынужденных жить в эмиграции.

**Ключевые слова:** татары в эмиграции, культурная жизнь татарских общин, эмиганттская печать.

Мөһаҗирлектәге татарларның мәдәни тормышы мәдәният тарихында XX гасыр ахырына кадәр фәнни анализ кысаларыннан читтә калып килгән өлкәләрнең берсе булып санала. Чит илләргә күчеп киткән татарларның әдәби мирасы белән танышу мөмкинлеге илдә иҗтимагый-сәяси үзгәртеп корулар башлангач кына туа. Монда татарлар эмиграциясенең тарихи шартларын һәм сәбәпләрен дә онытырга ярамый. 1552 елда үз дәүләтчелеген югалтканнан соң бу хәрәкәт аеруча көчәеп китә. XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында эмигрантлык хәрәкәтләренең колачы киңәю Беренче бөтендөнья сугышы, ике революция (1905 елгы февраль һәм 1917 елгы октябрь), гражданнар сугышы, Сталин репрессияләре белән бәйләнә. Бу сәбәпләр татарларны, исән калу максаты белән, үзләренең тарихи ватаннарын ташлап китәргә мәҗбүр итә. Нәтиҗәдә алар Җир шарының барлык почмакларында диярлек (Кытайда, Япония, Корея, Австралия, Финляндия, Швеция, Германия, Польша, Румыния, АКШта, Канадада, Төркиядә һәм бераз санда Норвегиядә һ.б. илләрдә) яшәү урыны табалар.

Кытайга киткән татарлар илнең ике географик регионына – Маньчжуриягә (төньяк өлеш) һәм Көнчыгыш Төркестанга (Уйгур автономияле районы) тупланалар.

Маньчжуриягә күчеп китүчеләрнең беренче дулкыны Транссебер тимер юлы төзелеше елларына туры килә. Аннан соң татарлар Көнчыгыш Квантун (Квантунско-Восточный) тимер юлы төзелешендә катнашалар. Мукден, Хайлар, Харбин, Голҗә, Урумчи, Шанхай шәһәрләрендә эре-эре татар мәхәлләләре барлыкка килә. Татарлар, матди һәм рухи ихтыяҗларыннан чыгып һәм мәчетләр мәктәпләр, татарлар кебек мәдәни-мәгариф үзәкләре төзү кебек проблемаларны хәл итү максаты белән, төрле җәмгыятьләргә берләшәләр. Шулай итеп алар белем бирүнең милли системасын булдыралар,

вакытлы матбугат һәм китап басу эшчәнлеген башлап җибәрәләр.

Кытайның себер өлешендәге татар җәмгыятьләренең мәдәни-мәгърифәтчелек тормышын Рокыя һәм Ибраһим Дәүләткилдиевлар (танылган галим, Истанбулның Мәрмәрә университеты профессоры Надир Дәүләтнең әнисе белән этисе), Хөсәен Габдүш, Рабига Даут, Равиль Салихмәт, Мәдинә Салихмәт һ.б.лар җитәкли.

Маньчжуриянең көнчыгышында татар сәүдәгәрләренә элек-электән билгеле булган беренче шәһәр – Хайлар урнашкан. Анда татарларның милли җәмгыяте оеша, төрле түгәрәкләр, хатын-кызлар клублары һәм татар китапханәләре эшли.

Мондый чараларда аларга Әхмәтвәли Ибраһим (Мәңгәр) зур матди ярдәм күрсәтә. Әмма 1940 еллар уртасында, Кытай Халык Республикасы төзелгәч, татар мәктәпләре, мәчетләр һәм җәмәгатьчелек биналары «национализацияләнә». Татарларның бер өлеше кире СССРга әйләнеп кайта, ә кайберләре башка илләргә юл тота.

Харбин шәһәренә татарлар XX гасыр башында ук килеп урнаша. Алар 1906 елда үз хисапларына мәчет салалар. 1918–1919 елларда «Идел–Урал» бергәлеге оеша. 30 нчы еллар уртасында Харбинда 1000нән артык татар яши. Харбин мәктәпләрендә спорт түгәрәкләре, хатын-кызлар, яшьләр клублары эшли, спектакльләр куела. «Идел–Урал» бергәлеге ятимнәргә һәм өлкән яшьтәгеләргә ярдәм фонды оештыра.

Харбинда, көнчыгыш илләрдә беренчеләрдән булып, басма продукция эшләнә башлый. Газета һәм журналлар, китаплар нәшер ителә. Харбин театры сәхнәсендә Г. Камал, Г. Исхакый, К. Тинчурин һәм башка татар драматургларының әсәрләре буенча спектакльләр куела. Әмма мондый тормыш озакка сузылмый. 1950 елда татар мәктәпләре ябыла. Зур көч куеп оештырылган татар мәдәни учреждениеләрен Кытай хакимиятләре тартып ала. Татарлар аннан да башка илләргә күчеп китәргә мәҗбүр була. Язмыш аларны Ерак Көнчыгышның барлык төбәкләренә тарата.

Мукденда татарлар Көнчыгыш-Квантун тимер юлы төзелеше елларында күренә башлый. 1917–1919 елларда инде аларның саны шактый була. Әмин Әбүзәров тарафыннан беренче татар кибете ачыла. Соңрак аның акчасына Мукден үзәгендә ике катлы мәчет төзелә. Бу шәһәргә аның чакыруы буенча егермеләп татар гаиләсе килеп урнаша. Биредә Әхмәтвәли Мәңгәр дә эре фирма ачып җибәрә. Татарлар җәмгыяте оештыра, ул татарларның рухи ихтыяҗын хәл итү белән шөгыльләнә башлый. [Кәримуллин, б. 21–36].

Мукден татарлар җәмгыяте үз милләттәшләре арасында мәгърифәтчелек эшен киң җәелдерәләр. Татарларның беренче корылтае 1934 елда Кобэ шәһәрендә (Япония) уза. 1935 елда Мукден шәһәрендә аларның икенче корылтае була, анда Ерак Көнчыгыштан гына түгел, Европа илләреннән дә катнашалар. Корылтайда татар диаспорасы мәк-

тәпләре, вакытлы матбугат һәм китап басу эше проблемалары, чит җирләрдә яшәүче татарларның матди хәлен яхшырту юллары, милли үзаң тәрбияләү ысуллары, татарларны ассимиляцияләшүдән саклап калу чаралары хакында фикер алышалар. Шушы ук съездда типография оештыру һәм газета чыгару хакында уртак нәтиҗә ясала. Шул елда ук «Милли байрак» газетасы чыга башлый.

Мәгълүм булганча, Мукден татарлар җәмгыяте 1923–1945 елларда эшли. 1945 елдан соң Мукден татарлары да яшәгән торакларын, үзләре барлыкка китергән инфраструктураны ташлап китәргә дучар ителәләр. Аларның бер өлеше СССРга кайта, күпчелеге Төркиягә китә.

Татарларның милли җәмгыятьләре башка шәһәрләрдә дә эшләгән. Мәсәлән, Чэн-Чун шәһәрендә XX гасырның 30 нчы елларында Ши-Ту Хэдзе станциясендә 300 ләп татар яшәгән. Беренче Бөтендөнья сугышыннан соң Хайлар шәһәре юнәлешендәге Хун-Хул җирлегенә 80–100 чамасы татар гаиләсе килеп урнаша, алар да анда үз җәмгыятьләрен төзиләр, мәчет, мәктәп салалар. 1950 еллар башында да Хун-Хул татарлары шундый рәвештәге яшәүләрен дәвам итәләр.

Маньчжуриядә беренче һәм бердәнбер татар авылы барлыкка килә, татарлар аны Ил-дуга дип атыйлар. Анда 100 татар гаиләсе исәпләнә. 1945 елдан соң бу авыл да таркала. Маньчжуриянең татарлар тупланып яшәгән башка шәһәр һәм торак массивлары да мәгълүм. Алар – Дайрен, Муден-Цянь, Тун-Хуа, Фусин, Ак-Цянь, Сипин-Гай, Мен-Духи, Юки-ши, Имен-Ту, Хандан-Хадзе, Ти-Мун, Чинь-Цянь, Чирин, Як-Шэн. Йомгаклап әйткәндә, аларның һәркайсы шул ук язмышка дучар була [Йөртә..., 1992, б. 12–45; Кәримуллин, б.21–49].

Мөһаҗирләрнең бер өлеше Россиягә кайтырга карар кыла. Ләкин аларның алдагы язмышы билгеле түгел. Кытайда калганнарның күбесе, хакимияткә коммунистлар килгәч, озак еллар төрмәләрдә утыралар. Рафаэль Адутов язганча, Сәгыйть әфәнде Садри Кытайның төрле төрмәләрендә сигез ел уздыра, ә аның бертуганы тоткынлыкта 20 ел була. Шундый газапларга дучар ителгәннәрнең исән калганнары Австралиягә һәм Төркиягә күчеп китә. Мөһаҗирләрнең өчтән бер өлеше ул чакта Япония хәрби администрациясе контроле астында булган Кореяга юл тота. Андагы кайбер шәһәрләрдә безнең ватандашларыбызның диаспорасы барлыкка килә, алар әкренләп Японниягә күчә [Адутов, 2001, б. 73–74].

Япониядәге мөселманнар (нигездә Казан татарлары, күпмедер өлеше Россия башкортлары) саны 1920 елларда 400–500 кеше була, 1930 елларга бу күрсәткеч 5–6 меңгә җитә. Алар Токио, Иокогама, Осака, Киото, Кобэ, Нагоя, Кавасаки шәһәрләрендә яшиләр. Бу шәһәрләрнең һәркайсында «Исламия» җәмгыятенең бүлекләре була («Исламия Токио», «Исламия Кобэ» һ.б.). Татарлар Япониядә «Япония мөселманнарының рухи идарәсе»н оештыралар. «Исламия Токио» бүлеге 1924 елда төзелә. Токио,

Кобэ, Нагоя шәһәрендә мәчет, мәдрәсәләр төзү өчен һәм мөселманнар зиратына җир участоклары бүлеп бирелә. 1938 елда салынган Токио мәчете мөселманнарга 48 ел хезмәт итә [Адутов, б. 74].

«Исламия» җәмгыяте активистлары тырышлыгы белән Нагоя һәм Кобэ шәһәрләрендәге мәчетләр каршында мәдрәсәләр төзелә. Императорның белем бирү турындагы 1937 ел, 5 декабрь законы таләпләре нигезендә Токиодагы «Исламия» мәдрәсәсе Япониянең дәүләт мәктәпләре исемлегенә кертелә һәм ул дәүләт мәктәпләренә бирелгән барлык хокуклардан файдалана башлый. «Исламия» мәхәлләсе Япониянең күп кенә күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренең киң яклавы астына алына [Адутов, б. 76].

1934 елда Япониягә татар милли-азатлык хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе Гаяз Исхакый килә. Аның татарларның мәдәни проблемаларын хәл итү максатыннан башлаган эшләре җирле хакимиятнең игътибарын җәлеп итә. Гаяз Исхакый, Япония җәмәгатьчелеген татарларның тарихи язмышы белән таныштыру өчен, япон галимнәре һәм иҗтимагый эшлеклеләре белән үзара элемтәгә керә. 1934 елның декабрендә япон телендә үзенең «Маньчжуриядә яшәүче төрек-татарларының азатлык өчен көрәше» дигән мәкаләсен һәм «Идел–Урал» монографиясен бастырып чыгара. Бу фактор Япониядәге татарларның алдагы тормышына уңай йогынты ясый.

1939–1945 еллардагы сугыш һәм аның нәтиҗәләре татарларны төрле илләр буйлап тарата. Әмма бергәлекнең, кечкенә генә булса да, бер өлеше сакланып кала. Токиода татарлар һәм башкортлар Төрки ассоциациягә берләшәләр. Тәмимдар Мөхит һәм Әнвәр Апанай төрле вакытларда аның рәисе булып торалар. Ивао К. белән Р. Закиров мәгълүматлары буенча, хәзер Япониядә исламга табынучы 60 меңләп япон исәпләнә икән [Йөртә..., б. 46–100; Закиров, с. 190–191].

Гомумән алганда чит илләрдә татарларның берничә мәдәни учагы була. Мәсәлән: Ерак Көнчыгышта (Кытай, Япония, Корея), Көнчыгыш Төркестанда (Голҗә...), Финляндиядә, Төркия, Германия, Румыния, Польша, АКШ һ.б. илләрдә. Харбин, Хайлар, Токио, Нагоя, Голҗә, Хельсинки кебек татарлар күпләп яшәгән җирләрдә милли мәктәпләр эшли.

Татар мөһаҗирләренең иң зур казанышы – аларның әдәби мирасы.

1905–1945 елларда Төркиядә, Венгриядә, Германия, Польша, Кытай, Япония, Финляндия, Швеция, Румыниядә, АКШта типографик ысул белән татар телендә 50 дән артык газета һәм журнал чыгарыла. Күп төрле гектографик, литографик һәм кульъязма басмалар барлыкка килә.

Татар мөһаҗирләренең беренче газета һәм журналлары Төркиядә дөнья күрә. 1905 елда, мәсәлән, Истанбул шәһәрендә «Kazan» журналы басылып чыга. 1908 елда шунда ук журналист Морат мөхәррирлегендә «Үлчәү» газетасы басыла. 1908 елда Төркиядә хакимияткә яшь төрекләр

килгәч, татар язучысы М. Акъегетзадә шәхси типографиясен оештыра һәм анда «Мәтин» газетасын чыгара башлый. Бу басмада ул Төркия икътисади үсеш формаларының максатчанлыгы хакындагы үз фикерләрен пропагандалый. Әмма бу идеяләр яңа хакимият тарафыннан кабул ителми, һәм газетаны чыгару тыела. Акъегетзадә яңа газетага – «Өч кардәш»кә нигез сала. Аны да яптыралар. Ә Акъегетзадәнең үзен Хәрби академиядә укытудан тыялар һәм сөргенгә җибәрәләр [Хилми..., б. 173].

Инкыйлабка кадәр Истанбулда татар телендә күп төрле газета һәм журналлар нәшер ителә. Әйтик, дөньякүләм танылган татар геосәясәтчесе, күренекле публицист, иҗтимагый, сәяси һәм дини эшлекле Рәшит Ибраһимов (еш кына аны Рәшит казый дип тә язалар) татар вакытлы матбугатын оештыручыларның берсе була. Ул 1900–1909 елларда журнал рәвешендә татар, гарәп һәм казакъ телләрендәге җыентыклар бастырып чыгаруны оештыра. Ә 1911–1931 елларда Истанбул шәһәрендә төрек телендә чыгарылган фәнни-популяр журнал «Тюрк юрду»ның беренче нашире һәм мөхәррире татар сәяси эшлеклесе Йосыф Акчура була.

Беренче Бөтендөнья сугышы елларында Австро-Венгрия белән Германиядәге хәрби әсирләр лагерьларында татар газеталары чыга [Насыров, 2004, с. 119].

Журналист һәм крайны өйрәнүче Д. Гарифуллин мәгълүматлары буенча, 1919 ел ахырына Германиядәге хәрби әсирләр арасында өч меңнән артык татар исәпләнә. 1915–1920 еллар дәвамында Вюнсдорф лагерында татар телле хәрби әсирләр өчен 5 газета нәшер ителүе мәгълүм. 1915–1918 елларда анда татар, гарәп, һинд һәм рус телләрендә «Әл-Җиһад» газетасы чыгарылган. 1915 елда аның да нашире һәм мөхәррире Рәшит Ибраһимов була. 1918 елда Цоссенда офицерлар Й. Мозаффаров белән У. Токумбетов, хәрби әсирләр арасында тарату максатыннан, татар телендә газета чыгаруны оештыралар. Тарихчы Тәлгать Насыйров раслаганча, Г. Идриси Вюнсдорфта мөселман хәрби әсирләр өчен татар телендә әдәби-фольклор газета «Яңа тормыш»ны нәшер итүне җайга сала.

1919–1920 елларда Вюнсдорфта шул ук Г. Идриси инициативасы белән хәрби әсирләр өчен «Татар иле» газетасы чыгарыла [Насыров, 2004, б. 119–120].

Гарәп хәрефләре белән җыелган бу газета, 8 битлек булып, даими нәшер ителә. Әлеге басманың максаты әсирлеккә төшкән үз ватандашларының рухын күтәрү, чит җирләрдә татар милләтенең йөзен саклап калу була. «Татар иле» газетасының бер санында татар хәрби әсирләренең Европача гражданнар киемендә төшкән фотолары урнаштырылган. Д. Гарифуллин элеккеге татар хәрби әсирләре аннан Татарстанга алып кайткан газеталарның биш санындагы материаллар белән таныша. Ул, аерым мәкаләләргә (мәсәлән, Габдулла Бигиев имзасы белән 1920 елның 1 гыйнвар санында урнаштырылган «Узмышыбыз» һәм «Өмет») нигезләп, алардагы милли үзаң дәрәҗәсенең югары булуын бил-

геләп үтә [Гарифуллин, б. 221–225]. Газетаның иң актив авторы лагерьда мулла вазифасын үтәгән Габдулла Идрис була. Габдулла Биги газетада шигырьләрен бастыра, Хәбиб Фәйзи, татарларны фикер алышуга чакырып, лагерьдагы яңалыклар турында яза [шунда ук].

1923 елда Берлинда эмигрантларның «Азат Шәрык» журналы басыла, аның белән Гаяз Исхакый, Фуат Туктаров, Мәхмет Әмин, Рәсул-Задә хезмәттәшлек итә.

1928 елда шул ук шәһәрдә «Милли юл» журналы чыгарыла. Аңа нигез салучы Гаяз Исхакый, үзе үк, журналның баш редакторы һәм әйдәп баручы авторы да була. Аны бастыру тарихы хакында Гаяз Исхакый, Балтыйк буе илләрендәге татарлар яшәгән барлык шәһәрләрдә булып чыктым, дип яза. 1930 елда журналның исеме «Яңа милли юл» дип алыштырыла.

11 ел яшәү дәвамында журналның 136 саны дөнья күрә. Гарәп графикасы нигезендә Берлинда басылган бу журнал ватандашларыбыз тарафыннан төрле илләрдән җибәрелгән иганәчелек исәбенә чыгарыла һәм басманың күп өлеше бушлай таратыла. 200 данә чамасы СССРда Мәскәүдәге Польша миссиясе аша таратыла. Конверт эчендәге журналлар Мәскәү почта тартмаларына салына һәм конверт тышына язылган адреслар буенча җибәрелә. Әмма СССРда эмигрантларның почта аша таратылган барлык басмалары да совет органнары тарафыннан конфискацияләнә [Насыров, с. 121]. Журналның төп максаты татар халыкның тарихи юлын яктырту һәм милли азатлыкка ирешү өчен көрәш перспективаларын билгеләүдән гыйбарәт була. Шуннан чыгып, журнал битләрендә татарларның милли-азатлык хәрәкәтләре, аларның 1917–1918 елларда активлашуы турында тарихи материаллар бирелә. Демократик татар дәүләте – «Идел–Урал штаты» оештыру хакында тарихи әһәмияткә ия карар кабул иткән «Милли мәҗлес»нең 20 еллыгы киң итеп яктыртыла. 1938 елда шушы юбилейга багышлап Варшавада уздырылган Бөтендөнья төрки-татар корылтаеннан тулы язма һәм фоторепортажлар урнаштырыла. Гаяз Исхакыйның бу хактагы тулы чыгышы Варшава радиосы аша тапшырыла. «Яңа милли юл» үз укучыларын даими рәвештә «Идел–Урал штаты» төзү өчен көрәшкә өнди.

Журнал битләрендә шулай ук татар халкының һәм башка төрки халыклар җәмәгать, сәяси һәм дини эшлеклеләренең, татар әдәбияты классикларының, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Исмәгыйль Гаспринский, Муса Акъегетзадә, Габдулла Тукай, Ризаэддин Фәхретдинов, Рәшит Ибраһимов, Йосыф Акчура, Фуат Туктаров, Гомәр Терегулов кебек татар вакытлы матбугатына һәм китап басучылыкка нигез салучыларның, Кырым татар халык шагыйре Мөхәммәд Ниязиның тормыш юлы һәм иҗаты турындагы язмалар урын ала. Журналның бер санында исә, XIV гасыр татар сугышчысын, Польшада (1660 ел) татар гаскәрен һәм Наполеонның татар гвардиясен сурәтләгән өч репродукция

урнаштырыла. Алар Польшадагы Мөселман милли музееннан алынган була [Насыйров, 2001, б. 152–165].

Журнал, үткәннәр турындагы тарихи материаллар белән беррәттән, агымдагы вакыйгаларны һәм дөньядагы иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрне дә даими яктыртып бара. Алар арасында СССРда дингә каршы алып барылган чаралар, язмачылыкның кирилицага күчерелүе, мәҗбүри коллективлаштыру, сәяси репрессияләр турындагы материалларга да урын аз бирелми.

1939 елда Германия хакимиятләре фәрманы белән «Яңа милли юл» газетасы ябыла. Басылу дәвамлылыгы, авторлар коллективы составы, тематикасының төрлелеге белән гомуми танылу яулаган «Яңа милли юл» газетасы башка эмигрант газета һәм журналлар арасында аерым урын тота. Шуны да әйтеп үтү урынлы булыр, Икенче Бөтендөнья сугышы барган чорда Германиядә мөһаҗирләр тарафыннан берничә төрле вакытлы басма нәшер ителә.

XIX гасыр ахырыннан башлап күп кенә татарлар Кытайга, Япониягә һәм Кореяга күчеп китә башлый. Ерак Көнчыгыш регионында татар телендәге беренче басма матбугат нәкъ менә 1920 еллар башында татар мөһаҗирләре күпләп тупланган Харбин шәһәрендә барлыкка килә. 1933 елда Гаяз Исхакый, Харбин Ерак Көнчыгышта төрки-татар колониясе үзәген тәшкил итә, дип язган. Инкыйлабтан соң анда киң масштаблы мәдәни чаралар алып барыла. Фәнни-мәгърифәтчелек һәм әдәби эшчәнлек җәелдерелә. Татар телендә газеталар басыла. Алар барысы да китапханә, тамашачылар залы һәм татар яшьләре, хатын-кызлар оешмалары, спорт мәктәпләре урнашкан татар Йорты тирәсенә туплана [Насыров, 2004, с. 124].

1920–1940 елларда Ерак Көнчыгыш регионында татар телендә дистәдән артык газета һәм журнал чыгарыла. Журналлар: «Ерак Шәрык» (Харбин, 1920–1923), «Азат шәрык» (1923), «Ялкын» (Харбин, 1923–1924), «Шәкертләр таңы» (Мукден, 1934–1935), «Игланыл хакыйкать» (Токио, 1932), «Яңа Якут Мөхбире» (Токио, 1932–1945), «Рәсемләр мәҗмугасы» (Токио, 1937); газеталар: «Мең ел» (Харбин, 1922), «Ерак Шәрык» (Харбин, 1924–1925), «Бәйрәм нуры» (Харбин, 1934), «Чаткы» (Харбин, 1932–1933), «Тәммуз» (Харбин, 1934), «Милли байрак» (Мукден, 1934–1945), «Йолдыз» (Тянцзинь, 1928) [Миңнегулов; Таһир, б. 189; Мансуров, с. 36].

Әдәбият белгечләре Кытайда нәшер ителгән басмалардан «Милли байрак»ны аерып күрсәтәләр. Йосыф Акчура аның һәр саны Лондонга Британия музеена һәм Америка конгрессы китапханәсенә җибәрелүен раслаган [Акчура, б. 98].

Т. Насыйров мәгълүматлары буенча, 1905 елдан башлап, бүгенге көнгә кадәр чит илләрдә татар телендә типографик һәм башка ысуллар белән 66 исемдә газета һәм журналлар нәшер ителгән. Аларның күбесе Германиягә туры килә. Анда 18 исемдә газета һәм журнал басылган. Кытайда – 16,

Төркиядә – 14, Финляндиядә – 8, Япониядә – 5, Румыниядә – 6, Венгрия, Швеция һәм АКШта берәр исемдәге вакытлы басма дөнья күргән [Насыров, 2004, с. 127].

Шунысы ачык, мөһаҗирләр басмалары эмиграция шартларында татарларны берләштерүче нигез булганнар, әдәби һәм мәдәни даирә формалаштыруга зур өлеш керткәннәр, һәм чит илләрдәге татар зыялылары моны яхшы аңлаган.

Мөһаҗирлек матбугаты үсешендә Г. Исхакый, С. Максуди, Х. Габдүш, Р. Рәхмәти, Ф. Туктаров, Г. Салиәхмәт, Г. Корбангали, Ә. Мәңгәр, Р. Мөхәмәдиш, И. Дәүләткилде, Х. Хәмидуллин, Наилә Бинарк, Р. Мөхтәсин һ.б. актив эш җәелдерәләр.

Алар вакытлы матбугатның ватандашларын юкка чыгудан һәм ассимиляцияләшүдән саклап калу функциясен үтәгәнен яхшы аңлыйлар. Бу юнәлештә иҗтимагый-сәяси һәм фәнни-әдәби журнал – «Яңа милли юл»ның роле аеруча зур була.

1931–1945 елларда татар телендә Япониядә айга бер чыгарылган «Яңа япон мөхбире» журналы да зур әһәмияткә ия.

Милли азатлык хәрәкәтенең күренекле вәкилләре, чит илләрдә булганда, төрек-татарларны Төркиядә һәм Европада тупларга омтылалар. Татар мөһаҗирләре, газета һәм журналлар чыгару белән генә чикләнмичә, әдәбият үсешенә дә зур игътибар бирәләр. Шуңа күрә газета яки журнал редакцияләрендә эшләүчеләрнең күп өлеше әдәби иҗат белән дә шөгыльләнәләр, һәм аларның әсәрләре шул ук газета-журналларда басылып чыга. XX йөзьеллыкта чит илләрдәге әдәбиятчыларыбыз саны шактый: Хөсәен Габдүш (1900–1988), Шаһвәли Келәүле (Илдәр) (1900–1970), Минһаҗ Исмагыйли (1910–1955), Гәүһәр Туганай, Исфәндияр Ишгай, Әхмәд Ләбиб Каран, Садрый Хәмид, Гайсә Хәкимҗан, Наилә Бинарк, Мансур Арсланбәк һ.б. [Миңнегулов, 2010, б. 109]. Белгечләр әйтүенә караганда, алар иҗатында үзәк урынны большевиклар сәясәтен һәм совет режимының тискәре якларын тәнкыйтьләү били.

Милләттәшләребез чит илләрдә татарча китаплар да бастырып чыгаралар. Әлбәттә, аларның күбесе гарәп шрифтында басыла. Китаплар нигездә әдәби, фәнни, педагогик, дини, музыкаль юнәлешләрдән гыйбарәт була. Дәреслекләр, сүзлекләр, календарьлар, географик карталар, сирәк кенә булса да җырлар җыентыклары да дөнья күрә. Ерак Көнчыгышта аларның саны 40 лап исәпләнә. Алар нигездә Токиодагы «Матбагаи исламия» нәшриятында дөнья күрә. Әйтик, «Кызларга махсус милли шигырьләр» дигән китап анда 1936 елда бастырыла. Шигырьнең эчтәлегендә Аллаһны олылау, белемгә-мәгърифәткә өндәү, эти-әнине хөрмәт итәргә, үз милләтең өчен көрәшергә чакырулар яңгырый. Харбинда, Мукденда, Кобэда нәшер ителгән китаплар да бар. 1933 елда күренекле татар шагыйре Габдулла Тукайның биш томлыгы, олуг әдип һәм дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов белән профессор Мөхетдин Корбангалиевнең аерым хезмәтләре дөнья күрә. Моннан тыш, Хөсәен

Габдүшнең «Дүрт хикәя»се (Токио, 1931, 83 б.), Г. Батталның «Төрек-татар тарихы» (Мукден, 1938, 155 б.), Солтанның «Шигырьләр» («Харбин, 1929, 27 б.), Исхак Хәйрулланың «Төш» (Харбин, 1922, 20 б.) китаплары басылып чыга.

Финляндиядә китаплар аеруча күп басыла. Кайбер авторлар китапларын үз хисапларына бастыралар, төрле җәмәгатьчелек оешмалары ярдәмендә нәшер ителгәннәре дә аз түгел. Иң актив авторларның берсе – Финляндиядә яшәүче Хәсән Хәмидулла. Ул фольклорчы буларак та танылган шәхес, һәм аның тарихи хезмәтләре дә бар. Аның исеме Финляндия язучылары исемлегенә кертелгән һәм бу аның иҗатының илдә популярлыгы турында сөйли. Х. Хәмидулла 1925 елда «Мәгърифәт» газетасы чыгара, 1945–1977 елларда «Шимал очкыннары» дигән календарь чыгара. 1943–1973 елларда аның шигырь һәм пьесалары җыентыклары дөнья күрә.

Түбәндә Финляндиядәге кайбер татарларның иҗатлары турында китапчылык белгече Ә. Кәримуллин тарафыннан галимнәр, Фин библиографы Гарри Гален белән Анкарадан Мәхмүт Таһир хезмәтләренә нигезләп төзелгән белешмә-мәгълүматлар тәкъдим ителә:

Закир Таһир (1900–1961) – сәүдәгәр. Ташкентта туа, Хельсинкида вафат була. 1955 елда «Финляндия төркиләре» (Хельсинки, 29 б.) дигән китабын чыгара.

Гайсә Хәкимҗан, Хабибрахман Шакир, Якуб Хәлимиләр дә күләме ягыннан әллә ни зур булмаган китапларның авторлары.

Сания Гыйффәт Кадыйри (1899–1957) – «Тормыш көзгесе» драмасы (Хельсинки, 1927, 64 б.).

Закир Кадыйри (1877–1955) Самарада туа, Анкарада вафат була. Һөнәре буенча укытучы. Китаплары: «Төрек тарихы сабаклары», «Дин сабаклары» (Хильсинки, 1938).

Гәүһәр Туганай – шагыйрә. Китабы: «Шигырь мәҗмугасы» I кисәк (Тампере, 1976, 92 б.).

Наилә Бинарк. Юмористик хикәяләре җыентыгы «Бераз уйла, бераз көл» (Хельсинки, 1973, 35+5 б.); «Ана теле һәм уку китабы» өч кисәк (Хельсинки, 1972–1974); «Аталар сүзе». Бу басмада 1500 мәкаль һәм әйтемнәр тупланган [Хельсинки, 1976, 112 б.].

Фәйзи Әхсән Бүре. 1917 елда Финляндиядә туа, 1974 елда Истанбулда вафат була. «Төркичә-финчә, финчә-төркичә чеп (*кесә*) сүзлеге» (Истанбул, 1972) авторы.

Зиннәтулла Имаметдин Әхсән Бүре. 1886 елда Акатук шәһәрендә туа, 1945 елда Тампереда вафат була. Ислам һәм фин татарлары турында Лондонда инглиз телендә басылып чыккан хезмәтләре бар. 1945 елда Тампере шәһәрендә «Төрки теле өчен профессор Садри Максуди вә төркиләр берлекләре хакында уртак фикерләр» дигән хезмәте басылып чыга (19 б.).

Болардан тыш, 1959 һәм 1977 елларда Финляндия төркиләре җәмгыятенең Тампере шәһәрендәге филиалы бастырып чыгарган җыр китаплары да мәгълүм.

Татар китаплары Германиядә дә басыла. Мәсәлән: «Програм.

Русияле ислам шәкертләренә ярдәм җәмгыяте» (Берлин, 1918, 12 б.), Муса Ярулла Бигинең «Исламият әлифбасы» (Берлин, 1920), «Халык моңнары» (Берлин, 1932, 16 б.), Галимҗан Идриснең «Бугаз мәсьәләсе» («Нинди итләр хәләл?») (Берлин, 1933, 16 б.). 1937–1939 елларда күренекле татар язучысы Гаяз Исхакыйның дүрт китабы дөнья күрә: «Дулкын эчендә (70 б.), «Өйгә таба» (88 б.), «Җан Баевич» (70 б.), «Көз» (74 б.). Шунысы да мәгълүм, Германиядә (нигездә Мюнхен шәһәрендә) Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң да татар телендә берничә китап бастырыла. Алар арасында Габдулла Тукайның шигырьләр җыентыгы; Мюнхен институты профессоры, «Советский Татарстан: теория и практика национальной политики» (Лондон, 1974, 392 с.) китабы авторы Тимурбек Дәүләтшинның «Татар әдәбияты», «Татар тарихы», «Татар халык җырлары; Минһаҗның ике бүлектән торган (беренчесе – 1952 елда, икенчесе – 1968 елда) «Шигырьләр китабы»; Ш. Нигъмәтинең «Безнең өмет», «Безнең фикер» җыентыклары; Тамурбек Дәүләтшин, Ирма Дәүләтшина, Салих Тизҗак хезмәте буларак 17 меңнән артык сүзне туплаган «Татарча-немецчә сүзлек (365 б.) дөнья күрә [Миңнегулов, 1993, б. 154–159].

Профессор Миркасыйм Госманов хезмәтләреннән мәгълүм булганча, Көнчыгыш Төркестанда да берничә татар китабы дөнья күрә. Мәсәлән, 1935–1936 елларда Мәлик Биктимеров һ.б. авторларның «Җаграфия» (география), «Туган тел» дәреслек-хрестоматиясе басылып чыга [Госманов, 1992, № 4; Госманов, 1992, б. 38]. Йосыф Акчура, Садри Максуди, Зәки Вәлиди, Габдулла Баттал кебек бер үк вакытта журналистика белән дә, китап нәшер итү белән дә шөгельләнүче танылган галимнәр, Төркиягә килеп урнашкач, үз хезмәтләрен төрек телендә, фәкать берничәсен генә француз һәм немец телләрендә бастырып чыгаралар.

Төркиядә татар китаплары чагыштырмача әз басыла. Анда 1956, 1959–1963 елларда дөнья күргән басмалардан Әсфәндияр Ишгай белән Әхмәт Ләбиб Каранның шигырьләр җыентыкларын һәм монографияләрен әйтеп үтәргә була [Миңнегулов, 1993, б. 159].

Чит илләрдәге татар әдәбиятын өйрәнеп тикшерүчеләр аның совет чоры татар әдәбияты белән генетик һәм типологик бәйләнештә булуын ассызыклыйлар. Мондый бәйләнеш мотивларда, образларда, шул ук вакытта тематиканың үзенчәлекле юнәлешләрендә (милли үзаң, милли үзбилгеләнү хокукы, төрки бердәмлек, татар мөһаҗирләр язмышы) чагыла. Эмиграциядәге язучылар иҗаты үзенә бер аерым шартларда бара. Алар үз юлларын, үз юнәлешләрен эзлиләр, туган телләрен, көнкүрештәге милли үзенчәлекләрен киләчәк буынга саклауны бурычлары итеп саныйлар. Аларның татар халкы тарихы, милләт язмышы, рухи халәтләре турындагы уйланулары, табигый ки, чәчмә әсәрләрендә, шигърияттә, публицистикада чагылыш таба.

Иҗтимагый-сәяси һәм фәнни әдәби журнал «Милли юл» (1928–1939), әдәби-сәяси журнал «Ерак Шәрык» (Харбин, 1923–1925), «Милли байрак» газетасы (Мукден, 1935–1945), Вюндсдорф лагерында хәрби әсирләр өчен чыгарыла торган «Татар иле» (Берлин, 1919), айлык журнал «Яңа япон мөхбире» (Токио, 1931–1945) (1931–1932 елларда ул «Япон мөхбире» исеме белән чыга), «Шималь очкыннары» журналы (Хельсинки, 1945–1977. Нашире – Х. Хәмидулла); әдәби, сәяси һәм фәнни журнал «Казан» (Анкара, Истанбул, 1970–1980. Нашире – Ә. Мәңгәр), «Ак юл» дигән, иллюстрацияләр белән бизәлгән газета-журнал (Финляндиянең Оулу һәм Хельсинки шәһәрләре. 1967–1974. 64 саны мәгълүм) мөһаҗирләр әдәби хәрәкәтләрендә зур роль уйныйлар.

Шуны да истә тоту мөһим, тикшернүчеләр билгеләп үткәнчә, чит илләрдә иҗат ителгән әсәрләр төрле дәрәҗәдә. Әйтик, Гаяз Исхакый, Хөсәен Габдүш, Сания Гыйффәт, Рәшит Рәхмәти, Гәүһәр Туганай, Хәсән Хәмидулла кебек талантлы авторларның хезмәтләре белән беррәттән, идея-художество эшләнеше ягыннан бик үк камил булмаган әсәрләр дә бар, дип күрсәтеп уза галим Мансуров [Мансуров, с. 144–145].

Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдүш, Ләбиб Каран, Исфәндияр Ишгай, Минһаҗ Исмагыйли һәм башка әдәбиятчылар эмиграциядә күренекле фикер иясе Гаяз Исхакыйның иҗат мәктәбен узалар. Гаяз Исхакый татар мөһаҗирләре иҗтимагый тормышында үзенә бер урын били. Ул үзе яшәгән чит илдәге сәяси, әдәби-мәдәни процессларга зур йогынты ясый, татарларның рухи һәм социаль ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, милли җәмәгать оешмалары төзеп, милләттәшләребезне берләштерүче, туплаучы көч буларак чыгыш ясый. Токиога, Кобэ, Харбин, Хайлар, Мукденга, Мисырга, Сүриягә, Фәләстыйнга һәм башка юнәлешләргә юл тотканда, Гаяз Исхакый, урыннардагы җәмәгатьчелек белән очрашып, алар алдында Россиядәге татарларның тарихына, әдәбиятына туктала, аларның үзбилгеләнү хокукына хакы барлыгын аңлата. Гаяз Исхакый – татар милли-азатлык хәрәкәтенең гомум танылган әйдәүчесе һәм идеологы, журналист һәм редактор, төрле жанрдагы хезмәтләр авторы. Алар арасында: «Ул әле өйләнмәгән иде» (1918), «Дулкын эчендә» (1920), «Өйгә таба» (1922), «Көз» (1923), «Җан Баевич» (1923), «Олуг Мөхәммәд» (1944–1947) һ.б. Дәүләтчелек, Идел буе халыклары конференциясен оештыру, шулай ук милли мәсьәлә кебек мөһим проблемалар аның тарихи «Идел–Урал» хезмәтендә күтәрелә, һәм бу әсәр рус, француз, япон, поляк, фин телләренә тәрҗемә ителә. Мукден шәһәрендә чыга торган «Милли байрак» газетасы белән Берлиндагы «Яңа милли юл» журналында гына басылган публицистик мәкаләләре гына да 170 тән күбрәк исәпләнә [Мансуров, с. 21].

Г. Исхакыйның «Ерак Шәрыктагы милли агымның төп максаты вә аның юллары», «Советларның урыслаштыру сәясәте»,

«Ерак Шәрыкта милли матбугат», «Финляндия татарлары», «Милли мәдәни мохтариятнең мәгънәсе нәрсә?», «Киләчәгебезнең нигезе», «Өченче юл юк», «Европаның язмышы» әсәрләрендә Гаяз Исхакый үзе күтәргән проблемаларны тулырак күзалларга ярдәм итә. Шул ук вакытта Гаяз Исхакыйның күп кенә мәкаләләре авторы күрсәтелмичә дә бастырыла [Кәримуллин, б. 92].

Әдип иҗатының күпкырлылыгын аның әйтеп үтелгән хезмәтләре тагын бер кат раслый. Тарихчы И. Таһиров билгеләп үткәнчә, аның милли бердәмлек өчен көрәше 1919 елдан ук башлана. Ул, социализм идеяләре белән мавыккан хәлдә дә, милли омтылыш һәм мөселман принциплары турында онытмый. Социализм шигарьләрендә ул милли азатлык чагылышын тоя.

Чит илдә фән дөньясында һәм иҗтимагый-сәяси тормышта онытылмас эз калдырган эшлекләребезнең тагын берсе – Рәшит Рәхмәти Арат (1900–1964). Ул – фәннәр докторы (1928), профессор, Төркия һәм Германия Фәннәр академияләренең хокукый әгъзасы, Истанбул университеты каршындагы Тюркология институты җитәкчесе. «Ислам энциклопедиясе»нә нигез салучылар сафында да аның исеме бар.

Рәшит Рәхмәти – чыгышы белән Татарстанның Әтнә районыннан. 1919 елның ахырында ул яраланган хәлдә Маньчжуриянең Харбин шәһәренә килеп эләгә. Монда 1921 елда лицейның соңгы курсын тәмамлый. Үзенең дусты Х. Габдүш белән алар шәһәрдәге татарларның мәдәни һәм фәнни тормышында актив катнашалар, атналык «Ерак Шәрык» журналы чыгара башлыйлар (ул 1924 елдан башлап 1925 ел ахырына кадәр басыла).

Идел Болгарстаны дәүләтенең исламны кабул итүенә 1000 тулу уңае белән, 1922 елның 22 маенда Харбинда «Мең ел» дигән газета нәшер ителә башлый. Анда Р. Аратның күп сандагы әдәби һәм публицистик мәкаләләре басыла. Шактый язмалары «Казанлы», «А. Давыд» «Гали Биктимер», «Али Биктимер», «Гали», «М.Х.», «М.Ф.», «М.Х.Ф.», «Шакир Йосыф», «Ш.Й.» тәхәллүсе белән яки имзасыз дөнья күрә [Гайнанова]. Галим, публицист Р. Аратның «Ирек җыры» дип исемләнгән мәкаләсен академик М.З. Зәкиев бәйсезлек гимнына лаек әсәр дип билгеләде [Закиев, с. 31–32].

1922 елда Р. Арат – Берлин университеты, фәлсәфә факультеты студенты. Германиядә оешып эшләп килә торган «Гомумтөрек студентлары берлеге», «Төрки-татар студентлары берлеге» эшчәнлегендә катнаша. 1928 елда аны Берлинга Фәннәр академиясенә хезмәткәр итеп җибәрәләр. 1933 елда Рәшит Аратны Төркиягә чакыралар һәм Истанбул университетының төрек теле һәм әдәбияты кафедрасында профессор дәрәҗәсендә эшли башлый. Бер ук вакытта ул шул университетның Тюркология институтын да җитәкли. 1949–1951 елларда Р. Арат Лондон университеты профессоры вазифасында.

Р. Арат Төркия Республикасында тюркологик тикшеренүләрне оештыруда зур роль уйный. Немец тюркологы V. Banga шә-

керте Арат борынгы төрки, уйгур, немец, рус телләрендә иркен сөйләшә, аралаша ала. Кирәге чыкса, инглизчә дә эшли. Борынгы төрки текстларны уку өлкәсендә дөнья фәнендә аңа тиңнәр булмый. Ул – текстологиядә транскрипциянең төрек алфавитына нигез салучы. Борынгы төрки телдәге бик күп текстлар Арат тарафыннан транскрипцияләнеп басмага әзерләнә. Мәсәлән: Йосыф Баласагуниның «Котадгу белек» (Анкара, 1947–1959), Әхмәт Югнәкинең «Һибәтел Хакани» (1951), «Угызнамә» (1937), «Алтын Ярук», «Ата битик», «Бабурнамә» һ.б. [Сибгатуллина, с. 5–8].

Тюркология өлкәсендә Рәшит Аратның абруе гадәттән тыш югары була. Төрек мәдәниятен фәнни тикшереп өйрәнү институты галимнәре аның истәлеге итеп, 1966 елда Анкарада «Rəsid Rəxməti Arat əçen» дигән 454 битлек китап әзерләп бастыралар. Бу китапта аның 222 хезмәте һәм публикациягә әзерләнеп тә үзе исән чакта басылып өлгермәгән алты язмасы галимнәр Мөхәммәт Эргин белән Әхмәт Тимер тарафыннан системалаштырылып бирелә. Аратның хезмәтләре библиографиясендә шулай ук 38 шигъри һәм 56 проза әсәрләре дә исәпләнә. Шулардан 26 шигыре 1920–1925 елларда «Ерак Көнчыгыш», калганнары «Яңа милли юл» журналларында дөнья күрә [Зәкиев, б. 36].

Әдәбият белгечләре билгеләп үткәнчә, Рәшит Рәхмәти хезмәтләре бу журналларның идея юнәлешләренә тәңгәл була. Аларда туган ил, милләт, бердәмлек, азатлык өчен көрәш, шулай ук болгар һәм башка дәүләтләрнең тарихы, вакытлы матбугат тарихы өстенлек итә. Күпсанлы хезмәтләре арасында аның рецензияләре дә бар. Мәсәлән, Арат Л. Троцкийның «Истинное положение в России» дигән китабын анализлый, Троцкийның, Сталин җинаятьләрен санап китү белән бергә, Россиядәге руслаштыру сәясәтен дә күрсәтүен билгеләп үтә. Әмма рус булмаган милләтләрне кысрыклау максатыннан учреждениеләр оештыруда Троцкийның үзенең дә катнашуын ассызыклый. «Бер тарихи драма» мәкаләсендә Россиядәге репрессияләр, шул исәптән Солтангалиев «эше», язучы һәм галим Гали Рәхимне кулга алу турында яза.

Берничә хезмәтендә Р. Арат яшьләргә мөрәҗәгать итеп, аларны үз программалары булган көчле оешма төзергә чакыра [Гайнанова]. Авторның Г. Тукайга багышланган хезмәтләре аеруча көчле яңгырый. Ул Г. Тукайны, ятимләндерелгән татар халкының ятим калган улы, дип атый.

Рәшит Рәхмәтинең, филологик һәм тарихи хезмәтләреннән чыгып, татар халкының актуаль һәм үзенә кадәр өйрәнелмәгән проблемаларын күтәрүенә инанасың. «XX гасырның күренекле тюркологы Рәшит Рәхмәти Арат» китабына (2001, Казан, латин шрифтында) кертелгән «Төркиләр яшәгән җирләр һәм аларның саны», «Тел мәсьәләләре һәм төрки телләр», «Төрки телләрне классификацияләү», «Төрки халыклардагы 12 еллык хайван циклы мәсьәләсенә карата», «Борынгы Турфан җырлары», «Габдулла Тукай», «Финляндия төркиләре» һәм башка язмалары әнә шул хакта сөйли. Галимнәр аның язма-

ларының фәнни һәм әдәби яктан югары кимәлдә эшләнүен билгеләр. Шушындый мөһим хезмәтләр авторы, профессор Р. Аратны Россиянең гыйльми даирәсендә XXI гасыр башына кадәр белмәү кызганыч күренеш әлбәттә. Ул бит инде 1946 елда ук барлык төрки халыклар куллана алырлык фәнни транскрипцияләүне эшләгән. Латин графикасына нигезләнгән аныңча транскрипцияләүне барлык илләрнең тюркологлары бик теләп кулланган. Бу юл белән эшләү өстенлеге бигрәк тә гарәп графикасыннан латин графикасына күчергәндә күренә. Академик М. Зәкиев раслаганча, Р. Арат төрки телләрне классификацияләүне үзенчә тәкъдим итә. Ул, моңа фонетик принциплардан чыгып якын килү дөресрәк булыр, дип саный.

Р. Арат Алтай телләрен өйрәнүгә багышланган һәм төрки телләрнең төзелеше, аларның грамматик үзенчәлекләре дигән хезмәтләрендә дә актуаль мәсьәләләрне күтәрә [Зәкиев, б. 38].

Истанбул университеты профессоры Сәгадәт Чагатай Р. Арат хезмәтләрен фәнни яктан түбәндәгечә классификацияли:

1. Уйгур телендәге текстларны фәнни эшкәртү һәм аларны Европада бастырып чыгару.

2. Төркиядә табылган уйгур текстларын төркемләү һәм аларны нәшер итү.

3. «Kutadgu Bilig», «Atəbətül – Xaqqayig» həm «Iske türek şigire» («Борынгы төрки поэзия»).

4. Борынгы төрек әдәби теленең барлыкка килү тарихы турында мәкалә.

5. Тарихка караган хезмәтләр.

6. «Ислам энциклопедиясе» өчен язылган хезмәтләр.

7. Мәгърифәтчелек максаты белән язылган хезмәтләр.

Профессор Чагатай раславынча, Р. Арат үз кулына кергән кулъязма хезмәтләрдәге һәм Урта Азия галим-филологы Мәхмүт Кашгариның (XI гасыр «Диване лөгатет-төрк» сүзлегендәге телләрнең тәңгәллеген (охшашлыгын) дәлилли, һәм бу фән өчен зур ачыш була. Галим Р. Арат Фатыйх Солтан Мәхмүдинең үз фәрманнарын уйгур телендә белдерүенә игътибар итә. Димәк, Анатологиягә килгән төрекләр уйгур телендә сөйләшкән. Р. Аратның «Уйгур алфавиты» белән «Фатыйх солтан Мәхмүд фәрманнары» зур фәнни казаныш буларак кабул ителә.

Р. Арат филология өлкәсен өйрәнү ысулларын тарих өлкәсендә дә куллана. Аның «Isge türeg şiire» (борынгы төрки шигырьләр) монографиясе төрки әдәбият тамырларын өйрәнүдә алыштыргысыз чыганак ролен үти [Чагатай, б. 22-23].

Башка илләрдәге татарларның интеллектуаль тормышында Россия татарлары да катнаша. Язучы һәм мәгърифәтче Муса Акъегетзадә (1864–1923) шундыйлардан була. Ул, шәхес иреге һәм татар халкының рухи үсешендә мәгърифәтчелекнең роле проблемасын күтәргән романнарның беренчесе буларак, «Хисаметдин менла»ны (Казан, 1886) иҗат иткән автор. 1888 елда Акъегетзадә белемен күтәрүне дәвам итү максаты белән Төркиягә китә, анда укытучылык, наширлек һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеге бе-

лән шөгыльләнә. Хәрби командованиенең югары мәктәбендә дәресләр алып бара һәм сәяси икътисад (политэкономия) буенча зур-зур хезмәтләр яза. Фәнни тикшеренүләр үзәгенең французлар бүлеге (Париж) җитәкчесе Франсуа Жоржон, Оттоман империясенең милли икътисадында Фредерик Лист идеяләрен тарату турында чыгыш ясаучы икътисадчыларның берсе Казан татары Муса Акъегетзадә булды, дип яза [Жоржон, с. 195].

Франсуа Жоржон Йосыф Акчура хакында да югары фикердә була. Ул аңа нигез итеп, Төркиядә нәшер ителгән, баш мөхәррире Йосыф Акчура булган «Тюрк юрду» журналын күрсәтә. Андагы идея һәм концепцияләрне өйрәнеп, Париж галиме «татар моделе» турында яза. Йосыф Акчураны ул Россия чыгышлы иң фикерле төрки зыялылардан саный. Шунысы да мөһим, бу журнал Оренбург татарларыннан эре сәнәгатьче Мәхмүд Хөсәеновның финанс ярдәме белән (беренче взносны ул кертә) чыга башлый. Галим, мәкаләсе ахырында, Россиядән чыккан төрек зыялылары бүгенге Төркия тормышында зур роль уйныйлар, дип яза [Жоржон, с. 197].

Гомеренең 32 елын Төркиядә яшәгән Садри Максуди да күренекле иҗади шәхесләрнең берсе. Ул Санкт-Петербург һәм Сорбонна университетларында белем ала, Кемаль Ататөрк вакытында Төркия парламенты депутаты. Садри Максуди – «Төрек теле өчен» китабы авторы, хокук тарихы буенча татарлардан беренче белгеч. Үзенең «Хокук тарихы» монографиясендә дәүләтчелек мәсьәләсен беренче урынга куя. Фән дөньясында С. Максудиның төркиләрнең Европада иң борынгы заманнардан ук яшәвен раславы һәм моны этруслар белән бәйләп дәлилләве дә мәгълүм. Мондый нәтиҗә, әлбәттә, фән өчен зур әһәмияткә ия.

Гомумтатар мәдәниятенең мөстәкыйль өлешен тәшкил иткән эмиграциядәге татарларның фәнни һәм әдәби иҗатлары Муса Акъегетзадә, Гаяз Исхакый, Рәшит Рәхмәти Арат, Тамурбәк Дәүләтшин, Садри Максуди, Әхмәт Тимер, Наилә Бинарк, Ләбиб Каран, Гали Акыш, Хөсәен Габдүш, Надир Дәүләт, Мәхмүт Таһир һ.б.ның хезмәтләре белән генә чикләнми. Инкыйлабтан соңгы мөһаҗирлек дулкыны милләтнең юкка чыгуыннан куркып калу белән бәйле, бу аларның эшчәнлеген татарларны берләштерүгә, туган телне, чит җирләрдә традицион үзенчәлекләрне саклау, милли мәктәпләр системасын, вакытлы матбугатны, китап басучылыкны (үз хисапларына) оештыру чараларына юнәлтә. Һәм татар мөһаҗирләре шушы юллар белән татарларның милли йөзен саклап кала, иҗтимагый прогресска ирешү юлында үзенең өлешен кертә ала. Ә аның дәрәҗә һәм масштаблары эмиграциядәге татарларның хокукый статусы дәрәҗәсе белән турыдан-туры бәйле. Аларга матди һәм юридик яклау күрсәтүче халыкара оешмалар булды микән? Бу проблема да җитди өйрәнүне таләп итә.

**Әдәбият**

*Кәримуллин Ә.* Язмыш, язмыш… Казан: татар. кит. нәшр., 1996. б. 21–36.

*Адутов Рафаэль*. Япониядәге кардәшләребез // Татаро-башкирская эмиграция в Японии. Яр Чаллы, 2001.

*Хилми Зыя Өлкән*. Муса Акъегет // Казан утлары. 1996. № 4.

*Насыров Т.* Татарская эмигрантская пресса // Гасырлар авазы = Эхо веков, 2004. №2.

*Гарифуллин Д*. Алман җирендә «Татар иле» (Газета «Татар иле» в Германии) // Гасырлар авазы = Эхо веков. 1996. №1/2.

*Госманов М.* Шәркый Төркестан һәм Голҗа татарлары // Йөртә безне язмышлар... Казан: татар. кит. нәшр., 1992.

*Насыйров Т.* Татар мөһаҗирләре матбугаты //Казан утлары. 2001. №7.

*Миңнегулов Х.* Дөньяда сүземез бар. Казань, 1999.

*Таһир М.* Чит илләрдә татар вакытлы матбугаты // Казан утлары. 1990. №10.

*Мансуров И.С.* Татарская литература зарубежья и творчество Гаяза Исхаки периода эмиграции. Канд. дис. филол. наук. Казань, 2005.

*Акчура З.И.* Мукден шәһәрендәге татарларның дини һәм милли җәмгыяте. Kazan – Istanbul – Ankara – Ayyildiz Matbaasi A.S. 1972, №7–8.

*Миңнегулов Х.Й*. Мөһаҗирлектәге татар әдәбияты: аны өйрәнү, тарихи ватанга кайтару мәсьәләләре // Первый всемирный форум татарских ученых. Казань, 2010.

*Кәримуллин Ә.* Суоми иленең татар китаплары // Казан утлары. 1990. №9.

*Миңнегулов Х.* Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты. Казан утлары, 1993, №7.

*Госманов Миркасыйм*. Чәчелгән орлыклар: Голҗа татарлары. «Казан утлары». 1992, - №4.

*Госманов М.* Шәркый Төркестан һәм Голҗа татарлары // Йөртә безне язмышлар. Казан, 1992.

*Мансуров И.С*. Татарская литература зарубежья и творчество Гаяза Исхаки периода эмиграции. Канд.дис. филол. наук. Казань, 2005.

*Гайнанова Л.* Рәшит Рәхмәти һәм Гаяз Исхакый // Казан утлары. №3. 2001.

*Закиев М.З.* Төркия аша тюркологиягә (В тюркологию через Турцию) //Рашит Рахмати Арат (на латыни). Казань, 2001.

*Сибгатуллина А.Т.* Выдающийся тюрколог Рашид Рахмати Арат (к 105-летию со дня рожд.) // Тюркологик мәҗмуга. II кисәк. Халыкара тюркологик конференция материаллары. Алабуга, 2004.

*Чагатай С.* Рәшид Рәхмәти Арат // XX гасырның күренекле тюркологы Рәшит Рәхмәти Арат. Казан, 2001.

Жоржон Франсуа. Тюркские интеллигенты России в Оттоманской империи и их влияние в эпоху младотурков // Ислам в татарском мире: история и современность. Казань, 1997.

***Гарипова Зөбәрҗәт Газиз кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты*

УДК 94(47)

***И.К. Заһидуллин***

## ХӘСӘНГАТА ГАБӘШИ ХАТИРӘСЕ

Статья посвящена общественной, научной и педагогической деятельности видного просветителя, педагога и имама Хасангаты Габаши.

**Ключевые слова:** Габаши, модернизация, джадидизм, мусульманская община г. Уфы, Оренбургское магометанское духовное собрание.

Беренче рус инкыйлабы йогынтысында Россия империясендә хөррият чоры башлану, татар матбугаты аваз салу, "Иттифак әл-мөслимин" партиясе оешу, Дәүләт думасына сайлаулар игълан ителү һәм башка факторлар татар милләте лидерлары төркеме формалашуга китерә. Моңарчы авыл, волость һәм шәһәр кысаларында милли һәм дини тормышка зур йогынты ясаучы төбәк лидерларының кайберләре яңа сәяси һәм иҗтимагый шартларда гомуммилләт әйдаманнарына әвереләләр. Дөрес, бу процесс Беренче рус инкыйлабына кадәр модернизация елларында ук үзен сиздерә – җәдитчеләрнең үз әйдәманы пәйда була. Мәсләктәшләр-фикердәшләрне И.Гаспралы һәм ул нәшер иткән "Тәрҗеман-Переводчик" туплый: газета аша язышу, фикере алышу бара.

Хәсәнгата Габәшинең китаплары һәм мәктәп-мәдрәсәләр өчен язган дәреслекләре, казыйлык эшчәнлеге аны XIX гасырның азагында Идел – Урал төбәге мөселманнары, зыялылар арасында төбәкнең интеллектуаль лидеры итеп таныта. Гыйлем иясе һәм халык хезмәтчесе буларак танылып өлгергән Х. Габәшинең 4 нче чакырылыш Дәүләт думасына Уфа губернасы мөселманнары тарафыннан депутат итеп күрсәтелүе аның гомуммилләт әйдәманына әверелүе турында сөйли. Ләкин ул, милләт өчен файдасы зуррак булыр, дигән фикер белән, урынын юрист Ибнеәмин Әхтәмевкә бирә [Габәши, 1928, б.13].

Х. Габәшинең милләткүләм әһәмиятле вакыйгаларда катнашу хроникасы шактый дәвамлы: Санкт-Петербургта уздырылган IV мөселман съездына чакырылу (1914 елның 15–25 июнь көннәре); 1917 елның 1–11 маенда Мәскәүдә узган Беренче Бөтенроссия мөселманнарының съездында президиум әгъзасы буларак катнашып, кандидатурасын мөфтилеккә тәкъдим итү; Казанда 1917 елның июль аенда булган Бөтенроссия мөселман руханилары съездында Мөселман руханилары союзының рәисе итеп сайлану; 2 нче Бөтенроссия мөселман съездында федералистик проектны яклап чыгышлар ясау; Уфада җыелган Милләт мәҗлесендә катнашып, туфракчыларны як-

лау; Милли идарәнең мәгариф бүлегендә хезмәт кую һ.б.

Бүген күренекле җәмәгать эшлеклесе, галим һәм рухани Хәсәнгата Габәшинең (1863–1936) мирасы, иҗтимагый эшчәнлеге галимнәрнең күз уңында. Аңа багышланган мәкаләләр басыла [Салихов, с. 94–100; Тухватулин, 1998, б. 120–122; 2000, с. 76-77; 2001, с. 65–69 һ.б.], А.Х. Төхвәтуллин тарафыннан галим эшчәнлеге буенча кандидатлык диссертациясе якланды [Тухватулин, 2003]. Кайбер кулъязмалары һәм атаклы «Мөфассал тарихе кауме төрки» («Төрек кавеменең җентекле тарихы») китабы кабат укучыга барып иреште[1].

Х. Габәшинең укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган хатирәләрендә[2] тормышының иң мөһим, якты мизгелләрен, вакыйгаларын бер җепкә тезәргә омтылыш сизелә. Мондый кыйммәтле мәгълүматларны жандармнарның рапортларында да, НКВД протоколларында да, вакытлы матбугат битләрендә дә, замандашлары истәлекләрендә дә, хәтта аның фәнни һәм публицистик язмаларында да табып булмый. Шуңа күрә бу документ Х. Габәшинең тормыш сәхифәләреннән кайберләрен төгәлләштерергә яки ачыкларга, яңаларын өстәргә мөмкинлек бирә, авторның узган вакыйгаларга шәхси карашын белергә ярдәм итә.

1828 елның 17 гыйнварында Кече Солабаш авылында тәмамланган «Тәрҗемәи хәлемнән (*биографиямнән*) гыйльми һәм иҗтимагый хезмәтләремнән беркадәресе» истәлекләренең бер өлешен Рамил Миңнуллин «Гасырлар авазы» журналында «Минем тәрҗемәи хәлем» исеме белән бастырды [Габәши, 1997, б. 194–204].

КФУ Фәнни китапханәсенең Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге хезмәткәре Рәисә Шәрәфиева тарафыннан басмага әзерләнгән «Тәрҗемәи хәлемнән, гыйльми һәм иҗтимагый хезмәтләремнән беркадәресе» кулъязмасында Х. Габәши иҗтимагый эшчәнлегенең бер өлешен генә искә төшерә, авыл мулласы һәм Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыядә казый буларак башкарган хезмәтләре турында сөйләми диярлек. Күрәсең, Х. Габәшинең фикер сөрешенә совет хакимиятенең диннәргә, шул исәптән исламга, руханиларга каршы алып барган сәясәте йогынты ясамый калмагандыр. 1927 елда инде Республикада яңалиф (латин алфавиты) гарәп шрифты урынына рәсми алфавит дип игълан ителә. Автор тагын бер елдан авыл мәчете ябылачагын әле белми...

Хәсәнгата Габәшинең гомер иткән һәм эшләгән урыннары берничә өлешкә бүленә:

1) 1874–1889 еллар – 11 яшеннән Казанда, Әҗем мәчете каршындагы «Гаффария» мәдрәсәсендә уку, укуының соңгы 5 елында хәлфәлек итү;

2) 1890–1894 еллар – Казан өязенә караган туган авылы Кече Солабашта имамлык һәм мөгаллимлек хезмәте белән шөгыльләнү;

3) 1895 елның 10 феврале – 1899 елның 6 марты – беренче тапкыр казыйлыкка сайлану чоры (Уфа шәһәре);

4) 1899–1908 еллар – икенче тапкыр муллалык һәм мөгаллимлек итү чоры;

5) 1908 елның 21 марты – 1914 ел – икенче тапкыр казыйлыкка сайлану чоры (Уфа шәһәре);

6) 1914–1932 еллар – туган авылына кайтып, кабат муллалык һәм мөгаллимлек белән шөгыльләнү чоры;

7) 1932–1936 еллар – Совет хакимияте тарафыннан «кулак» дип гаепләнеп, Архангельск өлкәсенә сөрелү һәм авыру сәбәпле туган авылына кайту, шунда 7 август көнне вафат булуы [Тухватуллин, 2003, с. 41].

Габәшинең хатирәләрендә югарыда санап үтелгән гомер тәлгәшләренең алтысы, тормышының иң нәтиҗәле еллары хакында бәян ителә.

Хәсәнгата шәкертлек елларында үзлегеннән, шәһәр мөмкинлекләрен файдаланып, рус телен өйрәнә, хисап, география, геометрия, табигыять, тарих өлкәләрендә, мөмкин булган юллар белән, гыйлем эстәргә тырыша. Аның дөньяга карашы формалашуда һәм системалы белем туплавын тәэмин итүдә Казан каласында яшәп иҗат иткән күренекле шәхесләр, галимнәр белән аралашу мөһим роль уйный. Сүз, беренче чиратта, татар мәгърифәтчеләре, гыйлем ияләре Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Гали Мәхмүдев, Шаһбазгәрәй Әхмәрев, Галимҗан Баруди, шулай ук университет галимнәре Иосиф Готвальд, Николай Катанов һәм башкалар турында бара. Исмәгыйль Гаспралы белән очрашу, фикер алышу да аның дөньяга карашын киңәйтеп җибәрә.

Хәсәнгата Габәши үзенең истәлекләрендә язып тәмамлаган китапларын атап чыга. Аларны ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин: басылып чыкканнары һәм төрле сәбәпләр белән басылмый калган хезмәтләр.

Мәгърифәтле яшь хәлфәнең беренче әсәрләре шәкертләр, укучы балалар өчен иң мөһим саналган темалар – педагогика һәм балаларның шәхси гигиенасы буенча «халык телендә» язылган. 1889 елда Габәшинең «Тәрбияле бала» исемле китапчыгы дөнья күрә. «Басыйрәт» («Аңлылык») [Габәши, 1889] исемле әсәрендә мөселманнарның урта гасырларда ирешкән ачыш-казанышларының, фикерләренең Европа гыйлемен үстерүгә тәэсир иткәнен ассызыклап, бүгенге Урта Идел төбәгендә яшәүче милләттәшләренең мескен хәленә ишарә ясый һәм узган заман мөселманнарының уңышларын үрнәк итеп, гыйлем ияләре Ибне Сина, Фәраби һ.б. турында яза.

Тагын бер иҗат җимеше – «Сагълык» (1890) – сау-сәламәт булыр өчен яшь кешегә ничек итеп төрле авыруларга каршы торырга өйрәтеп, шәхси гигиена кагыйдәләрен аңлатып, русча китаплардан тәрҗемә итеп әзерләнгән була. Х. Габәши укучылар арасында басманың дәрәҗәсен һәм тәэсирен арттыру өчен авторы итеп фәнни-популяр хезмәтләре белән халык арасында танылу алган мәшһүр төрек мөхәррире Әхмәд Мидхәтнең исемен куя, үзен исә тәрҗемәче дип белдерә. Биредә аның татар укучысының менталитетын яхшы белүе күзгә ташлана.

Габәши, шулай ук, 1890 елда күренекле шәрык галиме Александр Казимбәкнең (1802–1870) [Казембек, с. XCII] Бөкәй урдасы ханы Җиһангирга бүләк йөзеннән язылган һәм 1845 елда Казанда дөнья күргән «Мюхтесерюльвигкает или сокращенный вигкает; курс мюсюльманского законоведения по школе ханефидов» исемле хезмәтен, шәкертләргә фикъһе фәне үсешен аңлату ниятеннән, татарчага тәрҗемә итеп һәм үзеннән шәрехләүләр өстәп («Тәрҗемә әр-рисалә әл-махика ли-әүвәл мохтәсар әл-викая») бастыра.

1880 елларда Казан миссионеры протоиерей Евфимий Малов, мөселманнар белән бәхәс осталыгын чарлау һәм әңгәмәдәшләрен православие диненә тартып кертү максатыннан, өендә Казан мәдрәсәләре шәкертләре белән даими рәвештә очрашулар уздыра. Х. Габәши, үзе язып калдырганча, Е. Маловның «чукынчык Гәрәй» белән бергә төзегән миссионерлык китабына каршы, анда китерелгән дәлилләрнең дөрес булмавын раслап, Габдерахман Ильяси белән берлектә, 1886 елда «Нур әл-хакыйкать» исемле хезмәтен тәмамлый. Кульъязма мәдрәсәләрдә кат-кат күчерелеп, күбәйтелеп, Казанда һәм шәһәр яны татар авылларында киң тарала. Ш. Мәрҗани, кульъязма белән танышкач, хезмәткә уңай мөнәсәбәтен белдерә. Ләкин бу текст бастырылмый кала – цензор В.Д. Смирнов рөхсәт бирми [Габәши, 1928, 30 б].

Х. Габәши 1893 елда, татар игенчеләренең, җирбиләмә планын сызу, җир үлчәү буенча белемнәре булмау сәбәпле, күршеләре – алпавытлар яки крестьян җәмгыятьләре – белән килеп чыккан гаугалы низагларга таруларын, алдануларын, мәхкамәгә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булып һәм адвокат яллап, бурычка батып, ришвәтләр биреп, дистә еллар буе судлашып дөреслеккә ирешә алмауларын, ахыр чиктә, көч кулланып, сугышып, имгәнешеп җәзага тартылуларын, хәтта төрмәгә ябылуларын күреп һәм рәнҗеп, аларга ярдәм йөзеннән «Мәсахәтел әрз» («Җирнең киңлеге») исемле китапчык яза. Аны бастыру өчен Кырымда, Бахчасарайда үз нәшрияты булган Исмәгыйль Гаспралыга мөрәҗәгать итә. Ләкин бу хезмәт тә укучы кулына барып ирешми кала [Габәши, 1928, б. 24–28]. Күрәбез, Х. Габәши берничә елда педагогика, шәхси гигиена һәм җир үлчәү һәм план сызу гыйлемнәре һ.б. хакында китаплар язган. Бу факт авторның киң эрудициясен, фәннең төрле өлкәләренән хәбәрдар булуын раслап тора[3]. Шулай итеп, Х. Габәши 1890 елларда, китаплары аша, мөселманнар арасында танылу ала.

Х. Габәшинең тарих буенча уку китаплары эшләве махсус тукталуны сорый. Ш. Мәрҗанинең вафатыннан соң, Казанда татар тарихы белән шөгыльләнүче мөселман кешесе калмый. Х. Габәшинең нәкъ менә 1890 елдан ныклап тарих фәне белән шөгыльләнә башлавын олуг тарихчы Ш. Мәрҗанинең вафаты һәм ул вакытта җәдит мәктәпләрендә тарих дәресләкләренә ихтыяҗ белән аңлатсак, хилафлык булмас төсле. Х. Габәши,

Г. Ибраһимовның үзе хакында әйткән сүзләре белән килешеп, тарих фәне өлкәсендә башлаган эш-гамәлен «Мәрҗани корган тарих нигезенә бина үстерергә, аны киңәйтергә һәм бөтенәйтергә тотындым», дип бәяли.

Аның тарих буенча беренче хезмәте – «Төрек ыруглары» [Габәши, 1897] – 1897 елда башлангыч (ибтидаи) мәктәпләргә атап язылган, кыскача, энциклопедик планда мәгълүмат бирүче китапчык. 1898 елда (һәм кабат 1907 елда) бастырылган «Мохтасар тарихе кауме төрки» («Кыскача төрек кавеме тарихы») [Габәши, 1897] исемле китабы исә рөшди (урта) мәктәп шәкертләре өчен мөдәррисләр, шул исәптән Галимҗан Баруди үтенече буенча әзерләнгән.

Авторга танылу һәм шөһрәт китергән «Мөфассал тарихе кауме төрки» («Төрек кавеменең җентекле тарихы») китабы 1909 елда Уфада «Шәрекъ» матбагасында басыла. Татар халкының этногенезы мәсьәләсендә Ш. Мәрҗанинең болгар концепциясе тарафдары булган Х. Габәши, татар тарихчылары арасында беренче булып, төркиләр тарихының төп этапларын аерып чыгара. Аныңча, «Борынгы чор» Идел буе Болгар дәүләтен монгол гаскәрләре 1236 елда җимерү белән тәмамлана, «Урта гасырлар» 1552 елда Казан ханлыгы егылганга кадәр дәвам итә, руслар кулындагы чор «Яңа тарих» була [Тухватулин, 2009, с. 6, 9, 10, 12].

1910 елда Мәхкәмәи шәргыягә ревизия белән килгән Эчке эшләр министрлыгының чиновнигы И.М. Платонников Х. Габәшине, сәяси яктан пантюркизм идеяләрен таратучы һәм, кайбер ишетелгән сүзләргә караганда, бу өлкәдә актив эшчәнлек алып баручы, дип атый. Дәлил итеп 1909 елда басылган «Мөфассал тарихе кауме төрки» исемле китабында госманлы төрекләрнең, татар, башкорт, мещеряк, мордва, чувашларның бер төрки кавемнән чыккан дип язуын, бу хезмәте өчен төрек солтаны тарафыннан алтын сәгать, кыйммәтле ташлардан эшләнгән тәсбих һәм мактау кәгазе белән бүләкләнүен күрсәтә [Россия дәүләт..., 625 нче архив эше, б. 15–16].

Х. Габәши китабының үзенчәлеге шунда – ул шәкертләргә дәреслек буларак язылган, хәзергечә әйтсәк, компилятив характерда. Бу хезмәт тулы бер буын татар яшьләренә тарихи белем бирүгә хезмәт итә, ләкин татарларда бердәнбер дәреслек булып калмый. Зәки Вәлиди Казанда 1912 елда «Кыскача төрек-татар тарихы»н бастыра, 1915 елда аның «Кыскача рәсемле төрек-татар тарихы» дөнья күрә, 1917 елда бу хезмәтнең рөшди (урта) мәктәпкә адресланган икенче басмасы шәкертләр кулына барып ирешә [Әмирхан, 1992, б. 142–161]. Зәки Вәлиди, Х. Габәшидән аермалы буларак, урта гасырлар төркиләр тарихын этапларга башкача бүлә: һуннардан Төрки каганатка кадәр булган чор; аннан соңгы биш гасырны төркиләр арасында ислам дине таралу принцибы нигезендә аерып чыгара, биредә уйгырлар, тукызугызлар, болгарлар, хәзәрләр

тарихы, көнкүреше бәян ителә; өченче бүлекне – «Төрек иле магулларның шәүкәте дәверендә», дүртенчесен – «Вак ханлыклар һәм төрек иле шәүкәте төшүе» дип атый [Вәлиди, б. 179–181].

Х. Габәшинең казый итеп чакырылуына аның язган китаплары һәм иҗтимагый активлыгы сәбәп була. Кече Солабашта мулла булып торганда мөфти М. Солтановка Мәхкәмәи шәргыянә реформалаштыру турында проект төзеп җибәрә. Бу мәсьәлә М. Солтановны нык кызыксындыра: ул 1891 елны казый итеп чакырган Ризаэддин Фәхретдиннән дә, 1892 елда казый булган Габдерәшит Ибраһимовтан да шундый проектлар эшләтеп ала. Габдерәшит Ибраһимов, 3 ел срогын тутырмыйча, казыйлыктан киткәч, аның урынына Хәсәнгата чакырыла [Габәши, 1928, б. 44–45].

Беренче казыйлык чорында (1895–1899 еллар), Габәшинең Ризаэддин Фәхретдин (1891–1906 елларда казый булып тора) белән фикердәшләр, мәсләктәшләр – җәдитчеләр булуы Мәхкамә-и шәргыя эшчәнлегенә яңа сулыш өреп генә калмый, сыйфат ягыннан да зур үзгәрешләргә китерә. Мөфти М. Солтанов рөхсәте, казый Хәсәнгата Габәши инициативасы һәм Ризаэддин Фәхретдин ярдәме-тырышлыгы белән чакырылган Казан, Оренбург, Троицк, Петропавловск, Җиде пулат һәм башка татар шәһәр җәмгыятьләре вәкилләре: әдипләр, мөхәррирләр, яңа фикерле имамнар, мөдәррисләр, мөгаллимнәр, педагоглар, гимназистлар, студентлар – һәммәсе 30 кеше[4] – 1898 елда Уфа шәһәрендә «Ислах лисан төрки, ислах мәктәп һәм нәшир мәгариф әлмөслимин» иҗтимагый оешмасының җыелышын уздыралар. Ризаэддин Фәхретдин бу хакта, «Русча укыган интеллигентлар, Стамбулда укыган шәкертләр, үзебезнең олы мәдрәсәләребез белән тулган Бохарада торып кайткан муллалар һәм дамуллалар, учительләр белән карт хәлфәләр, студентлар белән сәүдәгәрләремезнең, беренче мәртәбә булarак, башка баш орып милли эш эшләргә ошбу җәмгыятьнең олы бер артыклыгы бар иде», – дип искә ала [Фәхретдин, б. 114].

Җыелышта халык өчен кирәкле һәм файдалы китапларны туган телдә, «төрки» телдә бастыру өчен әзерләү, кайбер дәрес язу кагыйдәләрен, 4 еллык җәдит башлангыч мәктәбендә укытылырга тиеш предметларны раслау, кирәк булган уку-укыту әсбапларын һәм аларның авторларын ачыклау кебек көнүзәк бурычларны билгеләү зур вакыйга була. Ибтидаи мәктәп өчен кирәк булган ун дәреслек тәгаенләнеп, аларның авторлары билгеләнә [Габәши, 1998, б. 125–126; Кәрими, 1907, б. 33–37]. Төрки кавемнең тарихын язу Хәсәнгата Габәшигә йөкләнә. Утырыш карарларының проектларын да Габәши әзерли. Карарлар тавышка куелып раслана, күбәйтелеп, һәр катнашкан кешегә җиткерелә.

Шундый зур рухи күтәренкелек шартларында үткән җыелышның кабат уздырылмавын Х. Габәши Уфа шәһәрендәге искелек яклы имамнарның һәм, бигрәк тә, алдынгы мөселман җәмәгатьчелеге – фанатик, ә кадим-

че муллалар шәригать өлкәсендә «иң зур гыйлем иясе» дип атаган, Кышкар мәдрәсәсен тәмамлаган һәм 1893 елдан казыйлык итүче Гыйниятулла Капкаевның баштан ук бу чараны булдырмау өчен тырышуына, барып чыкмагач, кабул ителгән карарларны карага буяп, шәһәр мөселманнарына куркыныч сурәттә күрсәтеп, кадимче фикердәшләре белән «кара агитацияләр» ясавына бәйләп аңлата. Җыелышның рухи җитәкчесе булып танылу алган Х. Габәши, Уфа шәһәре кадимчеләренең мәкерле гамәлләренә, төрле яла ягуларына, зәһәрле сүзләренә чыдый алмыйча, авыруга сабышып, табипларның киңәше белән укуязуны туктатып торырга мәҗбүр була. Һәм, вакыты тәмамланганчы ук казыйлык вазифасын калдырып, гаиләсен алып, кыш уртасында туган авылына кайтып китә (рәсми рәвештә эшеннән 1899 елның 13 февралендә азат ителә). Х. Габәши, бераз үпкәсен белдереп, фикердәше казый Р. Фәхретдиннең, оратор түгеллеген һәм тавышы зәгыйфьлекне сылтау итеп, мондый көрәшүләрдән читтә калуын, кабат кабинетына кереп бикләнеп, язу эшенә өстенлек бирүен, нәтиҗәдә 1899 елда Уфада, Мәхкәмәи шәргыйдә, җәмгыятьнең икенче җыелышын уздыру белән шөгыльләнүче шәхес калмавын хәбәр итә [Габәши, 1928, б. 44–45]. Р. Фәхретдин исә башкарак фикер әйтә: «Чиновникларның гадәттән тыш тикшереп торулары сәбәбеннән ошбу җәмгыять моннан соң кабат җыелмады, һәм идарәсе һичбер эш эшләмәде» [Фәхретдин, 1998. б. 114]. Хаклык кайдадыр уртада, күрәсең. Чөнки Х. Габәши 1908 елда кабат казыйлык вазифаларына керешкәч тә җәмгыять эшләп китми. Күрәсең, ул вакытка алга куелган максатларның күбесе үтәлгән булып, хакимиятнең татарларны пантюркизмда, панисламизмда гаепләве бу мәсьәләгә кире әйләнеп кайту юлын кыенлаштырган. Р. Фәхретдин Гани байның үлеменә 10 ел тулу уңаеннан язган истәлекләрендә [Фәхретдин, 1998. б. 113] бу җәмгыять рәсми статуста торгызылган очракта, аның мәдәният, тел һәм мәгариф өлкәсендәге реформаларны координацияләү өлкәсендә кирәкле булуын искәртә [Заһидуллин, б. 117–139].

Император Николай II нең 1904 елгы 12 декабрь указы нигезендә хөкүмәткә, Россия законнары белән беркетелгән дини принцип буенча, рус булмаган халыкларны кимсетү белән бәйле маддәләрне юкка чыгару турында фәрман җиткерелә. Шуның нигезендә мөселманнар үзләренең зарларын һәм тәкъдимнәрен хөкүмәткә юллый алалар. Шушы уңай белән һәм, премьер-министр С.Ю. Витте тәкъдиме һәм рөхсәте буенча Мәхкәмәи шәргыйдә 1905 елның 10–15 апрелендә руханилар корылтае уздырыла. Ләкин Х. Габәши ниндидер сәбәпләр белән анда бара алмый кала, шулай да элек төзегән проектын, яңартып, Уфага юллый. Җыелышның рәисе, Казанның Печән базары мәчете имамы Габдулла Апанаев әйтүенчә, аның кәгазенә игътибар зур булып, уртак проектны әзерләгәндә Х. Габәши фикерләреннән киң

файдаланыла. 49 маддәдән торган проектны Муса Бигиев сорап алып, «Исляхат әсаслары» («Реформа нигезләре») исемле китабында бастырып чыгара [Муса, б. 99–105].

Х. Габәши проектында күтәрелгән мәсьәләләрне ике зур төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Беренчесе – мөселманнарга, Россиядә яшәүчеләр буларак, русларныкы кебек үк тигез хокук бирү һәм ислам институтларының хокукларын Рус православие чиркәвенеке белән тигезләү; икенчесе – ислам институтларының эшчәнлеген камилләштерү.

Әйтеп үтелгән беренче төркем мәсьәләләр буенча Х. Габәшинең түбәндәге фикерләре игътибарны җәлеп итә (җәяләрдә ул күрсәткән матдәләрнең тәртип саны бирелә): шәһәр думаларына сайланганда (христиан динендә булмаган дума әгъзаларының саны ¼ артык булмасын, чикләүләрне бетерү (39); гаскәри муллаларның хокукларын һәм матди тәэмин ителешен гаскәри попларныкы дәрәҗәсенә күтәрүгә ирешү; мөселман гаскәриләренең билгеле бер урыннарга тупланып, аларга дини ихтыяҗларын үтәү өчен муллалар билгеләп кую (35); гаскәриләргә, рус мәктәпләрендә укучыларга дин сабагын христианнарга укытылган кадәр күләмдә укыту (32, 36); мөселман китапларына махсус цензура бетерелеп, аларны бастыруны гомуми цензура уставына буйсындыру (37); мөселман балаларына чиркәүнең миссионерлык эшчәнлеген (42), миссионерлык итүчеләрнең ислам диненә яла ягуын, кимсетүен туктату (45); мәчет, мәдрәсә бинасы төзер өчен Синодтан рөхсәт сорау тәртибен бетерү (46); чиркәү метрикәләренә язылмаган, яшерен рәвештә ислам динен тотучыларга, «отпавший от православия» дип аталучыларга мөселман дип язылырга рөхсәт бирү (44); мәдрәсәләрне тәмамлап, Мәхкамәи шәргыя шәһадәтнамәсе алган һәм мулла булырга җыенган кешеләрне хәрби хезмәттән азат итү, һич булмаса, студентлар кебек, армиягә кыска вакытка алу (22), иң мөһиме – Мәхкамәи шәргыяне «түбәнәйтелгән хәленнән» чыгарып һәм хокукларын киңәйтеп, мөселманнарның барлык дини һәм мәдәни эшчәнлекләре буенча җаваплы һәм җитәкче институтка әйләндерү.

Мәхкамәи шәргыянең һәм ислам институтларының эшчәнлеген камилләштерүне күздә тоткан маддәгә нигезләнеп, мөфтинең мөселманнар тарафыннан дин гыйлемле шәхесләр арасыннан сайлануына ирешү, аның абруен, дәрәҗәсен күтәрү (3, 4); казыйларга, Мәхкамәи шәргыянең өстәл башлыкларына, канцелярия хезмәткәрләренә хезмәт хакларын арттыру (5, 6), моның өчен, мөселманнардан никахлар өчен җыела торган салымнан тыш, һәр яңа туган бала башыннан һәм мирастан беркадәр салым алу (бу вакытта хөкүмәт казна хисабыннан Мәхкамәи шәргыянең чыгымнары өчен өстәмә түләми, бердәнбер чара – мөселманнар хисабына гына эшне яхшыртырга мөмкин була. – *И.З.*); Мәхкамәи шәргыянең үз типографиясен булдырып, барлык

нәсыйхәт-инструкцияләрне (7), шулай ук, имамнарга һәм мәктәп-мәдрәсәләр укытучыларына атап, айлык журнал бастыруны җайга салу (10).

Х. Габәшичә, имамнар православие руханилары кебек хокукларга ия булырга: аларның җинаятьләре крестьяннарның волость судларында каралмаска, үзләре гаскәри хезмәткә алынмаска, дәүләт, земство, мирский (авыл халкыннан җыя торган) салымнар түләмәскә тиеш (13). Авыл җәмгыятьләре руханиларны тиешле мәйданда җир һәм печәнлек белән, шәһәрләрдә исә фатир белән тәэмин итәргә тиеш. Аларга, шулай ук, шәригать нигезендә алып барылган никах, талак кебек гаилә йолаларын үтәгән өчен күпмедер күләмдә акча бирелүе шарт.

Х. Габәши уку-укытуны камилләштерүгә, шәкертләргә белем алыр өчен тиешле шартлар тудыруга зур игътибар бирә. Әйтик, мәктәп-мәдрәсәләрнең эшчәнлеген тәэмин итү, Мәхкәмәи шәргыядә хисап бирү өчен һәр мәхәлләдә сайлап куелган 3–4 кешедән торган совет оештырып, шуларның берсен рәис итеп кую лазем, дип яза (20). Һәр мәктәп, һәр мәдрәсә үзенең шәкертләренә шәһадәтнамә бирергә тиеш, дип саный (25). Х. Габәши, аларның чыгымнарын каплау өчен өчен земстволар христиан мәктәпләренә биргән кадәр күләмдә пособие бирергә, укучыларның ата-аналары да түләргә тиеш, дип яза. Шулай ук, җәмгыять җирләреннән (андыйлар булса) кергән табыштан һәм, булган очракта, вакыфлардан файдаланырга мөмкин, дип ассызыклый (24) (соңгы ике чыганак турындагы җөмләләр куш җәяләрендә сорау билгесе белән тәмамлана). Проектта башка кызыклы тәкъдимнәр дә урын алган.

Х. Габәшинең икенче тапкыр Мәхкәмәи шәргыягә чакырылуына, Оренбургка күченеп киткән Р. Фәхретдинне алыштырган, Уфа шәһәре ахуны Хәйрулла Госмановның вафаты сәбәп була. Мөфти М. Солтанов 1907 елның 10 декабрендә казый итеп Хәсәнгата Габәшине билгеләүне сорап, эчке эшләр министрына хат юллый. Рөхсәт 1908 елның 21 мартында бирелә [Россия дәүләт..., 622 нче архив эше, б. 134, 145].

Габәши Уфада гаиләсе белән арендага фатир алып яшәгән. Казыйларның еллык жалованьясы 800 сум булып, шуның 214 сумы казнадан, калган 586 сумы өстәмә рәвештә Мәхкәмәи шәргыядә тупланган мөселманнарның никахлары өчен җыелган акчадан түләнгән. Ул Гыйниятулла Капкаев һәм Уфа татар укытучылары мәктәбен тәмамлаган, 1903 елдан казый булган дворян Нурмөхәммәт Мәмлиев белән бергә Мәхкамәи шәргыя эшләрен алып барган [Россия дәүләт..., 625 нче архив эше, б. 15–16]. Үз араларында иң төплесе һәм йогынтылысы санап, мөфти М. Солтанов 1914 елның 29 апрель – 16 май көннәрендә булачак мөселманнар мәсьәләсенә багышлынган хөкүмәт киңәшмәсенә, үзе урынына, нәкъ менә Х. Габәшине тәкъдим итә, башкалага барырга казый ныклап әзерләнә. Ләкин хакимият Х. Габәшинең сәяси карашларын өнәми, шул

сәбәпле хөкүмәт киңәшмәсендә русча начар белүче Гыйниятулла Капкаев катнаша, аңа тәрҗемәче итеп Санкт-Петербургтагы 2 нче мәхәллә имамы Сафа Баязитов чакыртыла.

Россия дәүләт тарих архивы фондларында шушы киңәшмәгә кагылышлы русча язылган бер документка тап булдым. Аны Х. Габәши әзерләгән булуына шигем юк. Документның исеме – «Программа мечетских школ, проектированных духовенством, участвовавшим в заседаниях совещания по мусульманским делам в 1914 г.». Анда башлангыч мәктәптә һәм мәдрәсәдә укытылырга тиешле уку предметлары күрсәтелгән. Әйтик, башлангыч мәктәп өчен зарури рәвештә ана теле, гарәп теле, Корьән укый белү (тәҗвид), дин кагыйдәләрен һәм кәләмне башлап өйрәнү, әхлак, шәригать буенча беренчел белемнәр, ислам тарихы, хисап (математика) укыту карала. Мәдрәсәләр өчен программа шактый катлаулы булып, һәммәсе уннан артык укыту предметы санала: 1) гарәп теленең этимологиясе һәм синтаксисы, 2) Корьән һәм тәфсир, 3) хәдисләр, 4) фикъһы; 5) логика, 6) ислам тарихы һәм географиясе, 7) милек булу турындагы гыйльме фараиз, 8) гыйльме хикмәт (ислам фәлсәфәсе), 9) кәләм, 10) фарсы теле, 11) астрономия [Россия дәүләт..., 628 нче архив эше, б. 64].

Х. Габәшинең оештыру таланты 1911 елда Мөхәммәдъяр Солтановның мөфтилек хезмәтенә егерме биш ел тулу уңаеннан оештырылган тантаналы чараларны уздыруда калку күренә. Ул мөселманнар арасында да, рус зыялылары арасында да ихтирам казанган шәхес була. Алдынгы карашлы мөселманнар юбилей җыелышын Уфада дарелмөгаллимин ачтыру өчен файдаланырга тырышалар. Тантаналы олы җыелыш Хәсәнгата Габәши рәислегендәге уза. Аның тырышлыгы белән җыелышта, шәһәрдә дарелмөгаллимин ачарга кирәк, дигән карар кабул ителә.

Икенче көнне шушы ук бинада 500 кеше катнашында кунак мәҗлесе уздырыла. Чакырылган гаскәри оркестрга кушылып, Габәшинең улы, булачак композитор Солтанәхмәднең, ноталарга салган «Ашказар», «Тәфтиләү», «Пороховой Хатиҗә», «Баламишкин» көйләрен башкаруы тантанага милли төсмер бирә, бәйрәм рухы өсти. Өченче көнне шәһәрдә, тәүге тапкыр, 5 меңләп кеше катнашында Сабан туе уздырыла. Шулай итеп, Уфада яңа милли бәйрәм традициясенә нигез салына.

Юбилей комитеты, ике ай дәвамында юристлар һәм педагоглар белән киңәшләшеп, дарелмөгаллимин проектын әзерләүне тәмамлый, аны мөфти Петербургка алып барып тапшыра. Башкала хакимияте башлангычны яklamый – куелган хезмәтләр җилгә оча [Габәши, 1928, б. 46–48].

Хатирәләрдән аңлашылганча, Х. Габәши өчен Уфада яшәгән чоры иң якты, башкарган эшләреннән тәм, ләззәт һәм зур канәгатьлек алган еллар була. Бу нәүбәттән шәһәрдәге мөселман җәмгыяте турында берничә сүз әйтеп китү урынлы булыр. Өяз каласы булган Уфа 1865 елда

губерна шәһәре статусы ала, 1870 елда Агыйдел буйлап пароходлар йөри башлау һәм, бигрәк тә, 1888 елда Самара–Златоуст тимер юлы килеп җитү шәһәрне Көньяк Урал төбәгенең транспорт үзегенә әверелдерә, халык саны артуга уңай йогынты ясый.

1897 елгы статистика мәгълүматлары буенча Уфа губернасында Идел–Урал төбәгендәге мөселманнарның иң зур төркеме тупланган була – 1098982 кеше, алар губерна халкының яртысыннан артыгын тәшкил иткәннәр [Первая..., XLV, с. 44–45]. (Икенче урында Казан губернасы – 625847 мөселман [Первая..., XIV, с. 106–107]). Уфа мөселман җәмгыятенең башка этник шәһәр җәмгыятьләреннән аермасы – аның составында дворяннарның күп булуы (8,1%) [Первая..., XLV, с. 174–175], дворяннарның, шул исәптән хатын-кызларның да, мөселман җәмгыятенең мәдәни тормышына һәм көнкүрешенә тәэсир итүләре, дияргә мөмкин.

Авыллардан күченүчеләр хисабына 1910 елга Уфада мөселманнарның саны зур тизлек белән артып (32 мең кеше), шәһәр халкының өчтән берсен тәшкил иткән. Алай гына да түгел, Уфа, Казанны да узып китеп, иң күп мөселман яшәгән шәһәргә әверелгән. 1915 елда югары мәдрәсә «Галия», 4 урта мәдрәсә һәм 10 башлангыч мәктәп уңышлы эшләп килгән [Вильданова, с. 223]. Мөселманнар шәһәр үзидарәсендә йогынтыга ия булганнар, шәһәр хуҗалыгы һәм мәдәнияте өлкәләрендә активлык күрсәткәннәр. Әйтик, 1915 елда шәһәр думасына сайланган 61 кешенең 11 е мөселман булган [Справочник..., с. 6–9].

Шәһәрдә беренче рәсми теркәлгән иҗтимагый оешма – мөселман хәйрия комитеты[5] (1898 ел) Бигрәк тә 1907 елда теркәлгән Уфа мөселман хатын-кызлар җәмгыятенең эшчәнлеге нәтиҗәле була. Хатын-кызлар Мәрьям Солтанова җитәкчелегендә кыз балалар өчен приют оештыра һәм берничә йөз кыз балага милли мәктәпләрдә белем алырга мөмкинлек тудыра. Бер сүз белән әйткәндә, 1908 елда Х. Габәши Уфага килгәндә шәһәр иң эре татар-мөселман мәдәни үзәкләренең берсе була.

Бирелә 1906–1907 елларда «әл-Галәмел-ислами» («Мөселман дөньясы», беренче редакторы Д. Әбезгыйлдин), 1913–1918 елларда «Тормыш» газетасы яшәп килә. 1908–1911, 1916–1917 елларда нәшер ителгән «Мәгълумате мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя», 1911–1912 елларда басылган «Мәгълумате җәдидә», 1914–1917 елларда чыккан «Уфаның авыл көнкүреше журналы» үзләренең даими укучыларын табалар. Татарча газета-журналлар типография базасы, нәшриятлар булдыруны көн тәртибенә куя. 1908 елда оешкан «Шәрекъ матбагасы» Оренбургтагы Кәримов һәм Хөсәенов матбагасының филиалы була, анда 200 ләп татар китабы бастырыла [Каримуллин, с. 165–168]. Икенче шәхси типография Госмановныкы була. Ул 1911 елда ачылып, ике ел гына эшләп кала [Хайруллина, с. 207]. Уфада яшәгән елларын шәрехләп, Х. Габәши болай дип яза: «Уфада мине тулы мәгънәсе бе-

лән гыйлем әһеленнән вә халык хезмәтчеләреннән һәм тарих мөтәхассыйс (*белгече*) саныйлар. Кирәк татар-башкорт, кирәк урыслар арасында нинди генә гыйльми һәйәтләр (*комиссия*) вә җәмгыятьләр гаммәид халык хезмәтләре булмасын, мине әгъзалыкка чакыралар, хәтта тартып кертәләр диярлек иде» [Габәши, 1928, б. 14 ].

Чыннан да, югарыда аталган матбугат органнары эшчәнлегенә булсынмы, җәмгыятьләргә булсынмы, Х. Габәшинең роле һәм йогынтысы әйтеп бетергесез. Ул «Тормыш» газетасын оештыруда катнаша, атна саен басыла торган «Мәгълумате мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя»дә рәсми булмаган бүлек редакторы вазифасын башкара.

Истәлекләрдән күренгәнчә, әле беренче казыйлык чорында Х. Габәши, «Уфимские губернские ведомости» мөхәррире И.А. Озеров белән бергә, фәкыйрь мөселман һәм рус балаларына уртак «Дом трудолюбия» исемендә һөнәр мәктәбен нигезли (1897), шунда утыздан артык татар баласын урнаштырып, аларга һөнәр өйрәтүне оештыра. Бу балалар туган телләрендә башлангыч белем алсыннар, ислам дине нигезләрен өйрәнсеннәр дип, якындагы бер шәхси йортта мәктәп ачып, «Госмания» мәдрәсәсе мөгаллиме Гариф хәлфәне укытучы итеп билгеләүгә ирешә.

Бертуган сәүдәгәр Хөсәеновлар кадимчеләрнең йогынтысын киметү һәм каршылыгын җиңү өчен Мәхкәмәи шәргыя казыйларының авторитетыннан һәм дини гыйлемнәреннән мөмкин кадәр тулы файдаланырга омтылалар. Әйтик, Х. Габәши, Р. Фәхретдин белән бергәләп, берничә тапкыр Оренбург һәм Каргалы мәдрәсәләренә баруы, халык белән очрашуларда, мәҗлесләрдә яңача укытуның кирәклеген, яңарышка омтылуның мәҗбүрият булуын изге китап сүзләре белән раслап, каршы әйткән кыюрак кадимче муллаларга «тиешле җавапны» бирүе турында яза [Габәши, 1998, б. 122–123]. Билгеле, мондый фикер көрәшләрендә башка зыялылар да катнашканнар [Кәрими, 1998, б. 139–147].

«Гаффария» мәдрәсәсендә укыганда остазы урынына Казан шәһәр төрмәсенә баруы, мөселман тоткыннар белән аралашу тәҗрибәсе Габәшигә Уфада икенче тапкыр казыйлык иткән чорда ярап куя. Ул губерна төрмәсендәге берничә йөз тоткын мөселманнар өчен башлангыч мәктәп ачтыра, казна хисабына дәреслекләр алдыртып, укытучы билгеләтеп, үзе дә, атнага ике тапкыр килеп, дәресләр бирә. Белем алучы тоткыннарны төрмәдә урнашкан сәнәгатьханәдә һөнәр үзләштерергә күндерә. Х. Габәши җәмәгать нигезендә башкарган шушы гамәлен «үз гомеремдәге халык хезмәтләремнән зурысы итеп карыйм», дип билгели.

Х. Габәши туберкулез авыруына каршы көрәшүче Бөтенрусия җәмгыятенең Уфа бүлегендә татарлар һәм башкортлар арасында куркыныч авырудан саклану чараларын аңлату һәм мөселман табипларын чакыртып, авылларда халыкны тикшертү һәм аңлату эшләре алып баруны оештыруда зур нәтиҗәләргә

ирешә [Тухватулин, 2003, с. 33]. Казый «Галия» мәдрәсәсенең попечительләр советы идарәсендә әгъза булып тора. «Госмания» мәдрәсәсе бинасында һөнәр мәктәбе ачуга булышлык күрсәтә. Уфа губерна земствосы управасының мәгариф бүлегендә хезмәт куеп, мөселман мәктәпләренә матди һәм ана телендә укыту өчен уку әсбаплары бастырып чыгаруда ярдәм итә.

Уфа губерна земствосы каршындагы Мәскәү авыл хуҗалыгы җәмгыятенең филиалында әгъза булып тору исә Х. Габәшигә губернада мөселманнардан бер агроном билгеләү өчен штат алырга, земство хисабына авыл хуҗалыгында яңа технологияләр турында агрономнарга атап язылган китапларны земство хисабына татар теленә тәрҗемә иттереп бастырырга мөмкинлек бирә. Әйтергә кирәк, бу юнәлештә Уфа земствосының уңышлары зур була.

Казый Уфа өяз земствосы каршындагы «Кортчылык (умартачылык), түтәл һәм җимеш бакчачылык җәмгыяте»ндә әгъза итеп сайлангач, алдынгы алымнарга өйрәтүне җайга салу, мөселманнарга туган телләрендә китаплар тараттырып, авылларга инструктор йөртү өмете белән яши башлый. Язуына караганда, яхшы гына алга китеш тә күренә башлый, тик 1914 елның җәендә башланган Беренче Бөтендөнья сугышы якты планнарны челпәрәмә китерә [Габәши, 1928, б. 9].

Улы укый торган реальный училищеда «Аталар җәмгыятенең» идарәсенә сайлану Х. Габәшигә ярлы мөселман укучыларга матди ярдәм оештырырга мөмкинлек бирә. Уфадагы «Педагоглар җәмгыяте»ндә әгъза булгач, аның җыелышларына мөгаллим милләттәшләрен дә китертә, тарихи темаларга лекцияләр укый. Үзе катнашында шәһәрдә «Народный университет» ачылгач, аның мөселман секциясендә шулай ук, еш кына, лекцияләр белән чыгыш ясый [Тухватулин, 2003, с. 30, 32, 33].

Х. Габәши Уфа мөселман хәйрия җәмгыятендә дә актив хезмәттәшлек итә. Милли һәм дини җәмгыять тормышын яңача кору омтылышы искелек тарафдарлары каршылыгына очрый, мондый чакларда Х. Габәшинең дәлилле төзелгән фәтвалары зур әһәмияткә ия була. 1914 елда Уфадан туган авылына кайтып китәр алдыннан шәһәр зыялылары, Х. Габәшигә олы ихтирамнарын белдереп, изге гамәлләре язылган адрес бүләк итәләр. Анда түбәндәге юллар бар: «Һәрвакыт җәмгыяте хәйрия мәҗлесләрендә ак вә изге юллар күрсәттегез. Зәкят сандыклары тәэсис (*оештыру*) итү хакында мөһим булган фикерләрегезне җәмгыятьтә ашкярә (*ачыктан-ачык*) сөйләдегез. Милли хәятыбыз өчен бик мөһим булган әдәбият вә музыкабызга кылынган һөҗүмнәргә каршы мөдафәгада (*каршылык күрсәтүче*) булындыгыз. Һәм шуның мөбах бер эш икәнен гамәлегез белән күрсәттегез. Җәмәгатькә гаид нинди генә эш булса да, армый-талмый шул изге эшләрнең эчендә булып, хезмәт итә килдегез. Рус зыялылары вә җәмәгать хадимнәре тарафыннан җәмгыятьләрдә әгъза булып, шулардан Уфа мөселманнарының

истифада итүләренә васитачы (*арадашчы*) булдыгыз» [Габәши, 1928, б. 15–16].

Әлбәттә, Х. ,Габәшинең оештыру өлкәсендәге уңышлары ул вакыттагы шәһәр мөселман җәмгыятендәге мәдәни һәм иҗтимагый барыш, шушы юнәлештә эшләүче башка җәдитчеләр, мәгърифәтчеләр, язучылар – зыялылар һәм интеллектуаллар булу белән дә аңлатыла. Шулар арасыннан, 1887 елда ачылган вакытыннан «Госмания» мәдрәсәсе мөдире, ахун Хәйрулла Госманов (1846–1907), аннан соң «Госмания»не җитәкләгән имам Җиһангир Әбезгыйлдин (1875–1938), «Галия» мәдрәсәсе мөдире, имам Зыя Камали (Пәрвазетдин Камалетдинов) (1873–1942), «Тормыш» газетасында 1913 елда редактор булган Вагыйз Нәүрузов, теолог, мөгаллим һәм публицист Закир Кадыйри, 1911–1917 елларда Уфа губерна земство управасының мәгариф бүлеген җитәкләгән юрист Гомәр Терегулов, җәмәгать эшлеклесе Салимгәрәй Җантурин (1864–1926), «Галия» мәдрәсәсе укытучылары һәм җәдитчеләр, хатын-кызлардан Мәрьям Солтанова (Акчурина), Суфия Җантурина, шагыйрә Сания Гыйффәт һ.б.лар татар җәмгыятенең мәдәни тормышында мөһим роль уйныйлар.

1911 елның 23–25 май көннәрендә Уфа мөселман гомумбелем бирү мәктәбе мәсьәләсе буенча Уфа губерна земство управасында киңәшмә уздырыла. Анда бу мәктәпнең 5 еллык укыту программасы раслана (уку предметлары: туган тел һәм рус теле, дин белеме, арифметика, география, тарих, табигать белеме, геометрия, рәсем, гимнастика, хезмәт дәресләре – малайлар өчен һәм тегүчелек дәресләре – кызлар өчен). Җәдит уку йортлары өчен уку әсбапларын Х. Габәши җитәкчелегендәге комиссия, экспертиза уздырып кулланугa тәкъдим итәргә тиеш була [Тухватулин, 2003, с. 53–55].

Габәшинең Уфа мөселман җәмгыяте алдында тагын бер игелекле хезмәте – Корьән һәм хәдисләргә, Мәрҗани хезмәтләренә таянып, музыканың ислам дине өчен язык булмавын раслау, бу мәсьәләдә кадимчеләрне бәхәскә чакырып, соңгылары килмичә, яңа фикерне шәһәрдә дин кардәшләре арасында таратуы. Шулай итеп, Уфада «Галия», «Госмания» кебек мәдрәсә шәкертләре катнашында музыкаль, әдәби кичәләрне уздыруга дини хокукый нигез калыплаша.

Мәхкәмәи шәргыя казыеның балаларын – улы Солтанәхмәд һәм кызы Рокыяне – музыкага сәләтләре барлыгын белгәч, репетитор яллап музыка белеме бирүе, улының Уфада фортепьянода уйный белгән бердәнбер мөселман булуы схоластик күзаллауларны җимерүгә хезмәт итә.

Х. Габәши, ихлас кеше буларак, үзен кадимчеләрнең хаксыз сүзләре, рәнҗетүләре, интригалары алдында көчсез итеп сизә, мондый мөгамәләне бик авыр кичерә. Аның казыйлыктан баш тартуы һәм Уфадан туган авылына кайтып китүе, А.Х. Төхвәтуллин мәгълүматларына караганда, кадимчеләр белән барган бәхәсләрдә төрле нахак гаепләүләргә

түзә алмаудан килеп чыга [Тухватулин, 2003, с. 38].

Х. Габәшинең мөгаллимлек хезмәтенә аерым тукталу сорала. Ул 1893–1894 уку елыннан үз йортында җәдит ысулы белән укыта башлый. Беркадәр еллардан соң, Әхмәд бәй Хөсәеневтән, үтенеп, зур якты мәктәп салдыра, бай хисабына үз янына тагын бер мөгаллим ала. Х. Габәши язуынча, «янәшә-тирә халкының каршы торулары белән көрәшеп, каты һөҗүмнәренә күкрәк киереп утыз елдан артыграк инкыйлабка кадәр дәвам иттердем» [Габәши, 1928, б. 2]. Волостьта иң яхшы уку бинасына ия булган Кече Солабаш авылында барча кеше белемле, укый-яза белә. Эшләгән дәверендә мәктәп 50 ләп мөгаллим әзерләп чыгара, шуларның яртысы педагогик эшчәнлекләрен совет мәктәпләрендә дәвам итә. Гомумән алганда, төбәк ихтыяҗын күздә тотып һәм имамлык шөгыленә бәйле рәвештә мөгаллимнең хезмәте һәм мәгариф өлкәсендә башкарган оештыру эшләре шулай ук игътибарга лаек. Ул, Арча кантон мәгариф бүлеге үтенече буенча, үз йортында 2 нче баскыч совет мәктәбе ачып, анда мөгаллим һәм мөдир булып эшли башлый. Алат волосте укытучыларына тарих һәм төбәк тарихы буенча дәресләр бирә, волость укытучылары белән Себергә, Урал тауларына, Свердловскига һәм Омскига экскурсияләргә бара. Габәши 1928 елда үзенең татар тарихын өйрәнү буенча эзләнүләрен дәвам итәргә җыенуы хакында яза, ләкин совет хакимияте елларында оешкан «Татароведение җәмгыяте» белән хезмәттәшлеге сизелми – һәрхәлдә, бу җәмгыять басмаларында аның мәкаләләре юк.

Йомгаклап әйткәндә, укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган кульъязма XIX гасыр азагы – XX гасыр башында татар җәмгыятендәге яңарышны, милләтнең киләчәге турында төрле фикердә торган шәхесләрнең көрәшен күзәтергә, Уфа шәһәре мөселман җәмгыяте тормышының яңа сәхифәләре белән танышырга, яңалыкны тормышкөнкүрешкә кертүдә гомуммилләт әйдәманы булып җитешкән төбәк лидеры – талантлы оештыручы һәм мәгърифәтче-галимнең күпкырлы эшчәнлеген бәяләргә мөмкинлек бирә. Шунысы кызык, Х. Габәши үзенең язганнарын Уфада чакта якыннан аралашкан педагог Габдулла Шенасидан укытып, аннан «дөрес, хакыйкатькә муафыйк» дигән раслау да ала. Автор, шул рәвешле, хакыйкатьне язганын киләчәк буыннарга әйтергә омтыла сыман.

**Әдәбият**

*Әмирхан Р.* Халыкка әйләнеп кайткан мирас (Зәки Вәлидинең тормыш юлы һәм иҗаты турында) // Вәлиди Әхмәд-Зәки. Кыскача төрек-татар тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. б. 142–161.

*Вильданова Р.К.* Закир Кадыри (1878–1954): общественно-политическая и журналистская деятельность»: дис.... канд. ист. наук. Казань, 2013. 268 с.

*Габаши Х.Г.М.* Всеобщая история тюрков. Казань: Фэн, 2009. 248 с.

*Габаши Х.Г.* Подробная история тюрков (Муфассал тарих каум турки). Перевод с татарского языка Р.К. Адыгамова. Казань: Иман, 2006. 180 с.

*Габәши Хәсәнгата.* Басыйрәт. 1 кис. Казан, 1889. 104 б.

*Габәши Хәсәнгата.* Минем тәрҗемәи хәлем / басмага Р. Миңнуллин әзерләде // Гасырлар авазы = Эхо веков. 1997. № 3/4. б. 194–204.

*Габәши Хәсәнгата.* Төрек ыруглары. Төрек вә татар кавемнәрендән барчасының нәсел, ыругларыны вә тереклек рәвешләрене кыскалык илә бәян итәр. Ибтидаи мәктәб балаларына укылдырылмак өчен тәэлиф ителмешдер. Казан: «Милләт» нәшере, 1897. 20 б.

*Габәши Хәсәнгата.* Мохтасар тарихе кауме төрки. Уфа: «Шәрекъ» матбагасы, 1909. 56 б.

*Габәши Хәсәнгата.* Әхмәд бай һәм Габделгани бай Хөсәеновларны искә төшерү // Гани бай: Гани байга 160 яшь тулу мөнәсәбәте белән (1839–1902) / төз. М.Ф.Рәхимкулова. Оренбург, 1998. б. 122–127.

*Габәши Х.* Тәрҗемәи хәлемнән, гыйльми һәм иҗтимагый хезмәтләремнән беркадәресе // Казан федераль университеты Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге. 1542 т., 65 б.

*Габәши Х-Г.* Мөфассал тарихе кауме төрки // Мирас. 1994. № 3. Б. 106–113.

*Казембек А.К.* Мюхтесерюль-вигкает или сокращенный вигкает; курс мюсюльманского законоведения по школе ханефидов. Казань: Университет. типогр., 1845. с. XCII.

*Каримуллин А.Г.* Татарская книга начала XX века. Казань: Таткнигоиздат, 1974. 319 с.

*Вәлиди Әхмәд-Зәки.* Кыскача төрек-татар тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 181 б.

*Кәрими Фатих*. Аннан моннан. Оренбург: Кәримов, Хөсәенов һәм ширкәте матбагасы, 1907. 90 б.

*Кәрими Фатих.* Караңгы татар күгенең якты йолдызларыннан берсе мәрхүм Габделгани бай Хөсәенов //Гани бай: Гани байга 160 яшь тулу мөнәсәбәте белән (1839–1902) / төз. М.Ф. Рәхимкулова. Оренбург, 1998. Б. 139–147.

*Заһидуллин И.К.* Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя – XIX гасыр азагы мөселман җәмгыятенең реформалар үзәге // TATARIKA. 2014. №4. б.117–139.

*Муса Җарулла*. Исляхат әсаслары. Петроград, 1915. 289 б.

Первая всеобщая перепись населения Российской империи, 1897 г. / под ред. Н.А. Тройницкого. XIV. Казанская губерния. СПб., 1904. 284 с.

Первая всеобщая перепись населения Российской империи, 1897 г. / под ред. Н.А. Тройницкого. XLV. Уфимская губерния. СПб., 1904. Тетрадь 2. 210 с.

Россия дәүләт тарих архивы, 821 нче фонд, 8 нче тасвирлама, 622 нче архив эше.

Россия дәүләт тарих архивы, 821 нче фонд, 133 нче тасвирлама, 625 нче архив эше

Россия дәүләт тарих архивы, 821 нче фонд, 133нче тасвирлама, 628 нче архив эше.

*Салихов Р.Р.* Хасан-Гата Габаши // Духовная культура и татарская интеллигенция: исторические портреты: сб. статей для учителей и учащихся старших классов. / сост. Р.М. Мухаметшин. Казань: Магариф, 2000. С. 94–100.

Справочник по Уфимскому городскому общественному управлению. Уфа, 1915.

*Тухватулин А.Х.* Ш. Мәрҗанинең Х.-Г. Габәши иҗатына тәэсире // Ш. Марджани: наследие и современность. Материалы международной научной конференции. Казань, 1998. Б. 120–122.

*Тухватулин А.Х.* Пантюркистские идеи в исторической концепции Х.-Г. Габаши // История государственности Республики Татарстан и современность. Материалы Республиканской научной конференции. Казань, 2000. С. 76–77.

*Тухватулин А.Х.* Хасан-Гата Габаши (1863–1936) как общественный деятель и историк: дис. ... канд. ист. наук. Казань, 2003. 158 с.

*Тухватулин А.Х.* Педагог и историк // Габаши Хасан-Гата. Всеобщая история тюркских народов. Казань: Фэн, 2009. С. 3–22.

*Фәхретдин Р.* Хаҗи Габделгани әфәнде хакында булган хатирәләремнән бәгъзеләре // Гани бай: Гани байга 160 яшь тулу мөнәсәбәте белән (1839–1902) / төз. М.Ф. Рәхимкулова. Оренбург, 1998. Б. 122–127.

*Хайруллина Г.Х.* Издательское дело в Уфимской губернии во второй половине XIX – начале XX вв.: дис. … канд. ист. наук. Уфа, 2004. 242 с.

## Искәрмәләр

[1] Китап үзбәк телендә кабат нәшер ителә (Габәши Х.-Г. Мөфассал тарихе кауме төрки. Ташкент, 1994). Шул ук 1994 елда аның кайбер урыннары М. Әхмәтҗанов тарафыннан гарәп имлясыннан кирилл язуына күчерелеп, «Мирас» журналында дөнья күрә [Габәши, 1994, б. 106–113]. 2006 елда «Иман» нәшрияты аны рус телендә Р.К. Адыгамов тәрҗемәсендә бастыра [Габаши, 2006, 180 с.]. 2009 елда Татарстанның максатчан комплекслы мәдәни мирасны саклау «Мирас-Наследие» программасы кысаларында хезмәт А.Х. Төхвәтуллин тарафыннан «Всеобщая история тюрков» исеме белән басылды [Габаши, 2009, 248 с.]. Соңгы басмада «Педагог и историк» дигән әтрафлы кереш сүз һәм текстта искә алынган шәхесләр һәм вакыйгалар турында кайбер искәрмәләр урнаштырылган.

[2] Бер рәхимле бәндә, 1932 елда Х. Габәшинең өендә тентүдән соң урамга атылган кәгазьләрен җыеп, Казан университеты китапханәсенә тапшыра [Тухватулин, 2003, с. 40–41]. Габәшинең шул күпсанлы кәгазьләре арасында «Тәрҗемәи хәл»е дә КФУ Фәнни китапханәсенең Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә 1542 т. номерлы кульязма буларак урын алган. Текст юллы гадәти өч дәфтәрне (22,5×17 см) бергә тегеп эшләнгән битләргә язылган. Беренче дәфтәр 5 куш биттән, 2 нче дәфтәр 6 куш биттән, соңгы өченче дәфтәр 3 куш биттән тора, тагын 49–54 номерлары салынган, ертып алынган өч дәфтәр бите бар. Дәфтәр шәмәхә төстәге рәсемсез мәктәп дәфтәр бите белән «тышланган», бу тыш икегә аерылган. Текст дәфтәрнең соңгы битендә тәмамлана. Автор шәмәхә кара белән язган. Язганын укыганда текст астына йолдызчыклар ясап, аңлатмалар биргән, кайбер урыннарда матур, тигез почеркы белән аерым сүзләр яки җөмләләр өстәп куйган, алары кара төстәге кара белән язылган. Һәр биткә өстә номер сугылган. Номердан соң нокта куелып, цифр астына сызылган. Алгы биттәге форзацка кара төстәге кара белән (димәк, соңыннан. – *И.З.*) «1 нче кисәк» дип язылган. Күрәсең, хатирәләрнең икенче кисәген язу турында фикер туган.

Автор аерып чыгарган бүлекләр кызыл юлдан башланып, юлның уртасына язылган, аларның исемнәре астына ике сызык сызылган. Яңа темага күчкәндә, аерым җөмләләргә, сүзләргә астына бер сызык сызылган.

Ике янәшә биттә, замана шаукымы билгесе – кечкенә мәктәп баласы кулы белән яңалифтә язылган берничә сүз очрый («babai» h.б.)

[3] Х. Габәшинең тәмамланмыйча, кульязма хәлендә калган хезмәтләрен санап чыгуы аның галим буларак эзләнү юнәлешләрен ачыкларга мөмкинлек бирә: «Тәмамга якын булып та бәгъзе сәбәпләрдән басылмый калган «Тәдбир мәнзәл» (икътисади сәясәт), «Вазаиф әтфаль (балаларның вазыйфалары), «Мизанелхак фи ихтиярелхак» материаллары беркадәр җыелып та, төрле сәбәпләрдән эшләнеп бет-

мәгән «Гомәр бабай», «Болгар шәһәрләре»«, шулай ук «Мөфассал тарихе кауме төрки»нең Алтын Урда һәм Казан ханлагы чорларына багышланган икенче өлеше...

[4] Уфа шәһәре ахуны Хәйрулла Госманов, Казаннан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөдәррисе Галимҗан Баруди, яшь булуына карамастан, мөгаллим, мөдәррис, мөхәррир, педагог буларак шөһрәт алган Әхмәтһади Максуди, Казан татар укытучылар мәктәбенең дин сабагы укытучысы Шакирҗан Таһиров, Самара губернасы Бөгелмә өязеннән ахун Гыйльман Кәрими һәм аның улы мөгаллим Фатыйх Кәрими, Бозаулык (Бузулук) шәһәреннән мөгаллим Галиәсгар Гафуров, Оренбургтан беренче дәрәҗәдәге сәүдәгәр Габделгани Хөсәенев, Оренбург «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллиме Габдеррәхим Дәминов, Оренбург губернасы Сәгыйд бистәсеннән Гомәр хәлфә Дәүләтьяров, данлыклы Буби мәдрәсәсе мөдәррисе Фәйзи Нигъмәтуллин, Орск шәһәре мәдрәсәсе мөдәррисе Әхмәтфаиз Даудов, Уфадан дәгъва вәкиле Әбүсәгыйть Әхтәмев, Саратовтан мөгаллим һәм имам Садыйк әфәнде, юрист булырга укучы студент Искәндәр Солтанов, студент Дәүләтгильдиев һ.б. [Кәрими, 1907, б. 39–41].

[5] 1915 елда Уфа мөселман кулланучылар җәмгыяте һәм сәүдәгәр Мөхәммәтнәҗип Хәкимов рәислегендә Уфа мөселман иганәчеләр җәмгыяте оеша.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы,*** *тарих фәннәре докторы,*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*Урта гасырлар тарихы бүлеге җитәкчесе,*
*e-mail: zagik63@mail.ru*

*Хәсәнгата Габәши*

## Тәрҗемәи халемнән [*биографиямнән*] гыйльми һәм иҗтимагый хезмәтләремнән беркадәресе

Мин, Хәсәнгата Мөхәммәт угылы Габәши, Татарстан җөмһүрияте, Арча кантоны, Төбъяз [Дөбъяз] волосы, Кече Солабаш авылында крестьян таифәсеннән. Бер кечкенә генә фәкыйрь авылда, фәкыйрь имам булып, күбрәк мәгыйшәтен үз кул көче белән, китап һәм таш (кабер ташы) язу илә алып барган. Заманасының голямасында әз саналган вә берничә әсәрне дә булганга бик вәли Кәлимулла угылы Габәши (3 нче җөзьдә Асарда 139 нчы сәхифәдә зикер [искә алу, әйтеп узу] ителә) хуҗалыгы эчендә аның угылы Мөхәммәт илә Хәлимә Мөхәммәтшәриф кызы арасыннан 1863 нчы елда 11 нче гыйнварда дөньяга килгәнмен.

**Уку һәм истикмаль [төгәлләү, эшләп бетерү] дәверем:** ибтидаи тәгълимне бабам Габәшидән алып, 11 яшемдә Казан мәдрәсәләренең берсенә китерелгәнмен (Әҗем мәхәлләсенә). Анда озак заман (17 ел) калып, шул заман мөселман мәдрәсәләрендә укыла торган фәннәрне укып тәмам иттем (хәтме көтеб [*мәктәпне тәмам итү*] кылдым). Шуның белән бәрабәр мәдрәсәләрдә укылмый торган фәннәрне дә, мәсәлән:

урыс теле, хисап, җәгърафия [*география*], һәндәсә [*геометрия*], табигыять, тарих, тәраҗим [*тәрҗемәләр*] һ.б. Мөмкин булган төрле юллар белән тәхсил итәргә [*гыйлем алырга*] тырыштым[1].

Ул заманның гыйльми фазылы хезмәт гыйльмиясе белән мәшһүр кешеләр – Мәрҗани, Насыйри, Гали Мәхмүди (Сөләңгәр Гали), мөстәшрикъ Иосиф Готвальд, Гаспринский, Шаһбазгәрәй Әхмәрев, профессор Катанов, Баруди һәм башкалар белән дә танышып вә аралашып, алардан гыйльми җәһәттән күп файдаландым.

**Укыту вә бу юлдагы хезмәтләр дәверем:** шул 17 еллык мәдрәсә гомеремдә 12 елны ялгыз үзем уку белән, калган 5 елымда зур шәкертләрне укыту белән шөгыльләндем. 1891–[189]2 нче елларда Казанда бер вакытта шул җәдит [ысулы] белә укытучы ике мөгаллимнең берсе булып (берсе Галимҗан Баруди, хәлфәсе Җиһангир иде). Юнусовлар приютында рәсми мөгаллим булып укыттым.

1893–[189]4 нче елларда авылым Кече Солабашта мәктәп бинасы булмаганлыктан, үз йортымда шул җәдит [ысулы] белә укыта башладым. Беркадәр еллар укытканым соңында Оренбур Әхмәт Хөсәеневтән үтенеп, авылымда зур якты (бу көндә волостьтә беренче санала) мәктәп салдырып, аның хәраҗәтеннән [*исәбеннән*] үк яныма бер мөгаллим алып, янәшә тирә халкының каршы торулары белә көрәшеп, каты һөҗүмнәренә күкрәк киереп утыз елдан артыграк инкыйлабка кадәр дәвам иттердем[2].

Инкыйлабның әүвәл елларында бу мәктәптән шул вакытка яраклы күп кенә (иллегә якын) укытучылар чыкты. Арчада мәгариф шөгъбәсендә Сабирҗан Шульский вә Каюм Мәһдиевләр заманаларында бу мәктәпне ләтыйфә [*мәзәк*] уларак «Солабаш университеты», – дип атыйлар иде.

Кантонда укытучылар җитешмәгәндә: «Солабаш университетына заказ бирергә кирәк», – диешәләр иде. Шушы мәктәптән генә укып чыкканнарның байтагы (унбишкә якын) бу көндә дә совет мәктәпләрендә мөгаллимлек итәләр. Бу мәктәпнең олы хезмәте әнә шуның белән ачык күренәдер ки, ул замандагы балалардан укый-яза белмәгәннәрне калдырмаган. Өммилекне бетерү өчен хисап җыелганда: «Кече Солабашта укый-яза белмәгәннәр юк» дип җавап биргәннәр.

**Хезмәт сөю йорты – «Дом трудолюбия» мәктәбе ачу:** Уфага әүвәл баруымда урамда бик күп тәрбиячесез-эшсез балаларны күреп (гәрчә анда бер приют булса да, ул бик аз гына балаларны эченә ала иде). 1897 нче елда байтак мәшәкатьләр күреп булса да, ахырда, «Уфимский ведомость» мөхәррире Озеров белә бергә, бик фәкыйрь мөселман һәм урыс балаларына уртак Сүтелке күпере төбендә бер портка «Дом трудолюбия» исемендә һөнәр мәктәбе ачып, утыздан артык мөселман – татар балаларын урнаштырып, аларга һөнәр өйрәттердек. Уку-язу да, башка кирәкле гыйлемнәрне укытыр өчен иске Уфада монастырь түбән ягында бер йортка мәктәп ачып, Госмания мөгаллимнәреннән Гариф хәлфәне укытучы итеп билгеләдек.

---

[1] Ата вә бабаларым, сабыйлык вә мәдрәсә дәверемдә язылачак янә беркадәр тәхвил (күчерү, үзгәртү – ред.) бар. Аларны шаять тулы тәрҗемәи хальдә язармын (*автор искәрмәсе*).

[2] Баруди, Хөсәенев, Назиревләр иҗтиһады белән Казан тирәсендә – Чуаш илендә, Яңавылда, Битасанда, Яңа Рәҗәд, Тарышнада, Олы Әтнәдә вә башкаларда шул җәдит мәктәпләре ачылса да, Чуаш иленнән башкалары дәвам итә алмадылар (*автор искәрмәсе*).

(Соңыннан Белгородщинский шәһәренә киткән, диде, бу көндәге хәлне белмим.)

Беркадәр еллардан соң Уфада «Мәдрәсәи Госмания» йортында һөнәр мәктәбе ачуга һәм аның дәвамына инициаторы Гыйсмәтулла Гайнуллинга активный булышлык иттем. Шул ук «Мәдрәсәи Госмания»дә аның бу көндә Казанда булган Габдулла иптәш Шинасиләр катарында рәсми мөгаллимлек иттем.

Уфа «Мәдрәсәи Галия»сенең һәйәте [*комиссия, комитет*] идарәсендә әгъзалык итеп, аның риваҗ вә дәвамына күп булышлык итеп, кайвакытларда аннан дәрес гомумияләр (мәсәлән: хифзы сыйххәт, туберкулез хакларында) укыдым.

**Уфа губерна төрмәсендә мәктәп ачу:** мин искедән үк халыкның иң түбән катлавына әһәмият бирә идем. (Чөнки югары катлаулар үзләре дә башкара алалар иде). Халыкның иң түбән катлавында һәм аларга иң начар күз белән караланнарында, әлбәттә, мәхбүсләр – арестантлар иде. Аларның исемнәре сүгү вакытында гына телгә алына, аларның хәлләренә (старовер карт марҗалардан башка) һичкем игътибар итми иде. Мин искедән алар хәле белән беркадәр таныш булганлыгымнан[1], Уфа төрмәсе мәхбүсләре бик тә якыннан танышу вә аларга кулдан килгән кадәр матди һәм мәгънәви ярдәм итә алуым өчен, төрмәгә манигъсыз кереп йөри аларга хак – права алырга тырыштым һәм алдым. Уфа губерна төрмәсендә ул вакытта 750 мәхбүс бар иде. Шуннан 450 кадәресе башкорт-типтәр һәм татарлар иде. Правам буенча миңа төрмәнең һәр җире ачык булырга тиешле иде. Башлап аларның яту-тору, ашау-эчү, өст-баш шикелле якларын тәфтиш итеп, мөмкин кадәр бу якларының яхшыруына тырыштым. Моннан соң алар белән якын мосахәбә итеп һәммәсенең булмаса да, күбесенең бу төрмәгә эләгүләренең сәбәпләрен сораштым. Билгеле, тышкы сәбәп аларның җинаятләре булып күренсә дә, әмма асыл төп сәбәп аларның наданлыклары, фәкыйрьлекләре вә бу фәкыйрьлекләренә дә сәбәп – гаять тә надан, вәхши дәрәҗәсендә булулары икәне беленде.

Инде боларның бу хәлдән вә алар аркылы килгән бәлаләрдән гаммәи халыкны коткаруның иң баш чарасы: аларны гыйлем нуры белән нурландыру аркасында күзләрен ачу икәне ачык беленде. Шуның өчен мин күп мәшәкатьләр аркылы булса да, төрмәнең бер бинасын бушаттырып, мөселман мәхбүсләре өчен мәктәп ачтырдым. Гыйлемгә дуст дәүләтияләреннән китаплар, язу әсбаплары алдырып, алар хисабыннан ук айга 35 сум өҗрә [*эш хакы, хезмәт хакы*] белә укытучы кушып укыттырдым[2]. Бичаралар! Гыйлемгә сусаганнар икән. «Кайсыларыгыз укырга языласыз?», – дигәч, һәммәсе дә диярлек, хәтта аксакаллары да язылдылар. Мәктәп йорты сыйдыра алмаганнан һәр көн ике мәртәбә иллешәр кеше укытыла иде. Боларның йотып калырдай булып утырулары, хакыйкать [*дөреслек, чынбарлык*] күңелгә әллә нинди тәэсирләр бирәләр иде. Һәр атнага ике мәртәбә үземә барып дәрес гомумиләр укый идем. Төрмәдә сәнәгатьханә була торса да, ләкин мөселман мәхбүсләр аның белә файдаланмаганнар. Һәм аларны бу юлда җитди тәшвикъ итүче [*кызык-*

---

[1] Минем остазым Әҗем мәхәлләсендәге зур төрмәнең рәсми имамы иде. Ул күп вакыт ләвазим эда итәр өчен шул төрмәгә мине җибәрер иде. Мин мәхбүсләр белән таныша, хәлләре белән кызыксына идем.

[2] Уфа мөгалимнәреннән Кәшфи хәлфәне (*автор искәрмәсе*).

*сындыручы, өндәүчу*] дә булмаган. Аларның барганнарына да анда якты йөз бирелмәгән. Мин аларга сәнәгать, һөнәр өйрәнүнең әһәмияте, зарурлыгын [*тиешлеген, кирәклеген*] сүз һәм вакыт кызганмыйча бәян иттем [*аңлаттым, төшендереп бирдем*]. Беркадәресе шул вакыттан ук һөнәр өйрәнергә керештеләр. Һөнәр шөгъбәсе [*тармагы, бүлеге*] штатында чәһрәләрен [*йөзен, кыяфәтен*] үзгәртергә тәнбиһ иттем [кисәттем, зиһененә салдым]. Ул вакытларда безнең халык бу эшкә әһәмият биреп карамасалар да, мин үз гомеремдәге халык хезмәтләремнән зурысы итеп карыйм. Аның өчен мин бу эшне өҗрәсез – вазыйфәсез [*түләүсез*] эшләдем. Һәм хосусиятем өчен һич вәҗһе [*юл, ысул*] белән файдаланмадым. Хәзердә дә татлы хатирәләремнән берсе булып торадыр.

**Уфа губерна земствосында мәгариф бүлегендә хезмәт:** Уфа губерна земствоасы халык мәгарифе эшендә башка губерналарныкына караганда күп яхшы эшли. Казан земствосы шикелле шовинизмга бирелми иде. Мөселман гласныйлары соравы буенча мөселман мәгариф эшләре өчен дә махсус комиссияләр төзеде, съездлар җыйды, мөселман педагоглары чакырды. Шул мәгариф комиссиясенә мине чакырып, алты елдан артыграк актив булып, өҗрәсез хезмәт иттем. Элек тә мөселманнар өчен сирәк кенә русский школалар ачудан узмаган земствога, мөселман мәктәпләренә матди һәм мәгънәви бик күп ярдәмнәр кылынырга, төрек-татар телләрендә бик күп китаплар бастырып таратырга, башкалар белән бергә, сәбәпче булдык. Элек тә комиссия башында башка милләт кешесе иде. Ул гәрчә тәрәкъкыйгә [*алга китүгә, прогресска*] хилаф [*каршы, тискәр*е] кеше түгел иде. Шулай да булса, гайре табигый [*табигый булмаган*] иде. Без аның урынына үз кавемездән бер гыйлем хезмәтчесе утыртып, моның бик мәгариф эшенә янә зур куәт бирдек.

**Аталар җәмгыяте:** угылым Солтанәхмәт Уфа мәдрәсәи Галиясе тәмам итеп, реальный училищега кергән иде. Шул вакытта «Татарлар җәмгыяте» төзелеп, анда мин дә чакырылдым. Аның правлениесенә мөселманнан ялгыз, беравыз итеп, мине дә сайладылар. Укучы мөселман шәкертләрнең хәлләре белән танышып, мохтаҗ булганнарына өст-баш, аяк киемнәре, уку-язу әсбаплары белән дә ярдәм итеп, укуларына тәмам итеп чыгарга булышлык иттем.

**Педагоглар җәмгыятендә:** бу җәмгыять исеменнән үк мәгълүм булганга күрә, тәфсыйленә [*җентекләүгә, аерып-аерып аңлатуга*] керешмим. Ләкин мин дә ул җәмгыяткә чакырылдым һәм озак вакыт әгъзалык иттем. Русча телдән хәбәрдар [*белүче*] башка мөгаллимнәр, мөдәррисләрне дә җәлеп иттем. Төрле мәүзугъләрдан [*тема, проблемалардан*], хосусан, татар-башкорт тарихыннан сорап миннән рефератлар укыталар иде. Бәгъзе вакыт рус интелегентлары белә бик кызу гына полемикаларыбыз да була иде[1].

**Гомум дарелфөнүндә** [*югары уку йорты, университет*] (народный университет): Уфада университет булмау урыс вә татар халкы өчен бик зур уңайсызлык тудыра иде. Уфа халкы сорап йөрүләре буенча, хөкүмәт ул тарафларга бер университет ачарга карар бирсә дә, ләкин, Уфага булмыйча, башка бер шәһәргә ачылырга булган. Һич булмаса университетка китүчеләргә һәм Уфадагы халыкларга гыйльми бер хезмәт булуны мөляхәзә белән [*игътибар белән уйлап, фикер йөртеп*] урыс һәм татар интелли-

[1] Ни мәүзугъларда икәне документ хезмәтне күрә торган повесткаларда язылган (*автор искәрмәсе*).

гентларыннан учредительләр (шулар җөмләсеннән мин дә) чакырылып, народный университет ачарга карар бирделәр. Ачылганнан соң мөселман секциясе дә төзелгән иде. Габделвәли иптәш Шонасилар вә башкалар катарында [*рәтендә, сафында*] народный университет исеменнән төрле мәүзугъларда управа залында күп халык алдында дәрес гомумиләр укый идем[1]. Минем дәресемә интеллигентлар, хәтта присяжный поверенныйлар да килгәлиләр иде. Народный университет исеменнән земствоның илле еллык бәйрәменә җибәрү өчен ике вәкилнең берсе итеп мине билгеләделәр. Ләкин мин шул ук бәйрәмгә өяз земствосы хозурындагы «Кортчылар җәмгыяте» тарафыннан да билгеләнгән идем. Шуңар күрә университет исеменнән бардырырга урыныма икенче кеше күрсәтеп, анда сайландылар.

**Мәскәү авыл хуҗалыгы җәмгыятенең Уфа шөгъбәсе:** Уфа губерна земствосы хозурында Мәскәү авыл хуҗалыгы җәмгыятенең зур гына шөгъбәсе бар иде. Мин Уфада авыл хуҗасы булмасам да, ләкин мөселман авыл хуҗаларының үтенүләре вә дәлаләтләре [*димләү, юл күрсәтү*] буенча шул җәмгыятьтә әгъзалык итә идем. Мин анда иштиракь [*катнашу, бергәләп эшләү*] иткәнче, ул җәмгыять урыс агрономы, авыл хуҗалыгына тиешле китапларны урыс телендә генә бастырып килгән. Мин Уфа виляяте [*өлкәсе, губернасы*] шикелле, урысларына караганда, татар-башкорт күбрәк булган виляятьтә китапларны алар аңламаган телдә генә тарату һич гаделлек түгел икәнен тәфсилләп сөйләгәнем соңында, төрек-татар телендә китаплар таратыла башлады. Мин аның белән генә канәгатьләнмәдем; чөнки бер тарафтан Уфа виляятенең татар-башкорт халкы авыл хуҗалыгы хосусында гаять артта калганына, икенче яктан, халыкның бөтенләй диярлек өмми (*надан*) булуына, шул сәбәпләрдән аларга китаплар тарату гына зур файда бирмәячәгене әйтеп, бәлки аларга татар-башкорт кавеменнән агроном йөртеп юл күрсәтергә тиешлегене дәгъва кылдым. Урыслардан бәгъзеләре хәтта җәмгыять рәисе Базилевка чакыргалап карасалар да, ахырда бу көндә мәркәздә зур урын тоткан Л.Н. Цюрупа, ул вакытта Уфада губерна агрономы иде, аның минем гаризамны куәтле рәвештә яклавы сәбәбеннән, минем гаризам җәмгыять тарафыннан кабул ителде. Ләкин татар-башкорт таифәсеннән агроном табуны миңа йөкләттеләр. Сәйяр [*йөрүче, гизүче, күчмә*] агрономга елга 1800 сум вазыйфә билгеләргә, йөрергә ат вә бер иптәш бирелергә карар чыгардык. Урыс әгъзалары болай булгач, урыслар арасында да шулай ук сәйяр агроном йөртүне кирәксенделәр. Мин дә аны куәтләп, аңар да карар чыгардык. Ул вакытта төрек-татарлардан агрономлар барын белмәсәм дә, ләкин, шаять, табылыр өмете белән кабул иткән идем.

Ләкин, шул Русияне харап иткән империалистлар сугышы башлану сәбәпле, бу эш ярты юлда калган иде. Шөкерләр булсын, безнең шул вакыттагы теләгебезне советлар хөкүмәте тулысы белә мәйданга чыгарырга тырыша.

**Кортчылак вә бакчачылык җәмгыяте:** Уфа өяз земствосы хозурында «Кортчылык (умартачылык), түтәл һәм җимеш бакчачылык җәмгыяте» төзелгән иде. Мин бер җәһәттән, искедән үк болар белән кызыксынганым вә шөгыльләнгәнем сәбәпле, үземнең тәхәссесемне [*белемемне*] арттыру нияте белә булса, икенче тарафтан, шул ук максад – Уфа тирәсендә бик иске формада алып бара торган кортчыларга юллар күрсәтү, түтәл вә җимеш бакчаларының ни идекенендә аз хәбәрле, хәтта

[1] Документ урынында афиша (*автор искәрмәсе*).

бәрәңге, суган шикелле нәрсәләрнең аз үстергән халыкларга бу хосусларда үз телләрендә китаплар тараттырып, инструктор йөртеп булмасмы өмете белән, өченчедән, аңлы мөселман халкының үтенүе белән дә, әгъзалык итә идем. Монда да мин яхшы гына эшли вә үз тәҗрибәләрем белән урталаша вә сүземне дә үткәрә башлаган идем. Бу җәмгыять мине земствоның илле еллык бәйрәменә дә вәкил итеп җибәргәннәр иде. Ләкин шул бәдбәхет империалистлар сугышы бу эшләрнең барысын да туктатты.

**Уфа мөселман җәмгыяте хәйриясе:** Уфа мөселманнарының түбәндә язылачак адресларында күрелгәнчә, мин мөселман җәмгыяте хәйриясендә дә җитди иштиракь иттем. Бу хосуста сүз озынайтуны лязим [*тиеш, кирәк*] күрмим. Фәкать шул кадәресен генә әйтәм: кирәк шул җәмгыяте хәйрия мәҗлесләрендә, кирәк матбугатта һәрвакыт шул искелек вә искелеләр белән көрәшеп тәрәккъый [*алга китү, прогресс*] вә тәҗәддед [*яңа булу, яңару*] вә мәдәният (культура прогрессы вә просвещение) өчен агитация ясап та килдем. Моның һәм биргән фәтваларым [*нинди дә булса бер эшне эшләү*] өчен искеләр вә карт хәзрәтләр тарафыннан, хосусан «Дин [вә] мәгыйшәт» журналында һәрвакыт сүгелеп килдем. Ләкин халык аларга карамыйча, минем сүзләремә, биргән фәтваларыма зур ышаныч белән карыйлар, игътибар итәләр, алар белән гамәл кылалар иде. Моны күреп мин сүгенгәнемә, хурланганыма илтифат итмичә [*игътибар, әһәмият бирмичә*], шөкранә кыла [*күргән яхшылыкка каршы шатлык белдерү билгесе*] вә арттыра гына бара идем.

**Мәгълүмат мәҗәлләсе** [*журнал*]: мин икенче мәртәбә (1908 нче елда) Уфага бардыгымда күптәннән матлуб [*теләнгән, соралган нәрсә*] булган «Мәгълүмат» журналы нәшер итәлә башлаган иде. Ләкин Диния нәзарәте әгъзалары өстләренә алмаганлыктан, аның мөхәррире Этбәк искелеккә маил [*авыш, тартым*], күбрәк «Дин-мәгыйшәт»кә язучы бер кеше билгеләнгән вә аның идарәсендә чыгарыла иде. Әйтелгән журналга мөхәррирлек итү хакында рәиснең тәклифене [*боеруын, әмер итүен*] башка әгъзаларның да языштырулары шарт итеп кабул иттем. Аларга рәсми кыйсем вә фәтва бабларыны биреп, «шәһәр эчтән алыныр» кагыйдәсенчә, үземә киң мәйдан күреп «гайре рәсми» кыйсемне алдым. Анда һәм мәкаләләрем, «ифтитахларым [*башлап җибәрүем*]» белән мөмкин кадәр укучыларның күзен ачарга тырыша идем. Шуның өчен бер яктан, хөкүмәт мәэмүрләре [*чиновниклары*] тарафыннан, гайре рәсми кыйсемдә мөхәрриренә (миңа) һәрвакыт диярлек тәнбиһләр [*кисәтү, искәртү*], хәтта шелтәләр явып тора, икенче яктан, «Дин [вә] мәгыйшәт» мөхәррирләре һәрвакыт диярлек рәддияләр [*кире кагу, юкка чыгару*] язып (әлбәттә, мактап түгел), хәтта минем язганнарымны рәд кылып [*кабул итмичә, кире кагып*], китапларында да язалар иде, өченче яктан, искечеләр вә Ишмөхәммәт хәзрәтләр хатлары белән тутыралар иде. Мәсәлән, Ишмөхәммәт хәзрәт: ترغيب الفوض الابيلا تخلص بالشريعة عن اوهمات اتصاف الادابة [«Шәригатьне бәладән, бозык уйлардан коткару һәм әдәпне сафландыруга өндәү»] китабында унынчы битендә اما الخاتمة ففى الاشارة الا ما كتب هو لقاضى الموت كافن (؟) على تحرير لقسم ثلاث من المعلومات [«Йомгак. «Мәгълүмат»ның өченче санда казый кәфенләү турында язганнарын күрсәтә»] дигән сүзеннән башлап 11, 12, 13 нче битләрендә мине бер бик каты сүгә, хурлый, чура побына ошата. Мәкаләләремне рәхимсез рәдд кыла. Бер урында мескенләрчә: «Һай казыйҗан!.. فبحق الشريعة اطلبوا منك ايها القاضي» [«Шәригатьне без сездән өйрәнергә тиеш, әй казый!»], ди. Казыйдан мораты, әлбәттә, мин. Ахыры вакытларында «Мәгълүмат» бик

күп тарала башлаган иде. Монарх хөкүмәте үзенең чит милләтләрне изүдә урыслаштыру хакындагы нечкә сәясәтне күрер кадәр күзләре ачылмаган вә әйләнә-тирәсендәге әхвальне танымаган саваб [*туры фикер*] гафләттән [*игътибарсызлык, саксызлык*] уянмаган иске фикерлеләрдән бер дә курыкмый иде. Бәлки аның шул нечкә сәясәтне аңлар кадәр, күзе ачык, йокламаганнардан курка иде. Әмма мин «Мәгълүмат»та миңа бәйләнер кадәр аның бу сәясәтенә ачык рәвештә кагылмый идем. Бәлки «һазә»нең һаси хезмәтен күрә идем. (Һа-һай, менә...), ягъни: югарыда әйтелгән нечкә сәясәттән гафләт йокысындагыларны уятырга, күзләре ачылмаганнарның күзләрен ачарга тырыша идем. Безнең халык моңар күп дикъкать итмәсәләр дә, әмма монарх хөкүмәте моны бик яхшы сизенә иде. Эш бу рәвешле барса, Бөтенрусиядәге мөселман руханиларының күзләрен ачар, гафләт йокысыннан уятыр, дип курка иде. Әмма тышкы яктан аның низамларына [*тәртибенә, режимына*] ачык хилаф [*каршы, тискәре*] күрелмәгәнлектән, туп-туры наширне туктатырга уңайсызлана. Бәлки шулай мөхәрриренә тәнбиһләр, шелтәләр белән «Мәгълүмат»ны зарарсызландырырга тырыша иде. (Бу мәсьәләне иптәш Һади Килдебәки яхшы хәтерли торгандыр.) Гакыйбәт [*эшнең соңы, нәтиҗәсе*] бу тәдбирләре [*тиешле чара*] кяр [*йогынты, тәэсир*] кылмагач, идарә рәисенә мөрәҗәгать кылып, куркытуларны аңар юнәлдерде. Ул да бер көн, хәтта миңа үземә дә әйтми-белдерми үк, «Мәгълүмат» нәширене туктаттыгыны хөкүмәткә белдерде.

**Государственный думага кандидатлык мәсьәләсе:** Уфа урыслары тарафыннан мөселманнарына, үзләренә аерым вәкил сайларга тәкъдим ителгән иде. Мөселманнар беренче **күрьядән, ягъни сензалылардан** (бу көндә Казанда булган) дәгъва вәкиле Ибнеәмин Әхтәмевне, икенче күрьяне сензасызлардан мине билгеләгәннәр иде. Берничә күрья өчен сенза Уфада 450 десәтина җире вә яки 5 мең сумлык милек булу кирәк иде. Әмма Әхтәмевнең фактически 450 дисәтина җире булса да, ләкин купчий реест буенча фәкать 446 гына күренгәнлектән, ул берничәдән үтә алмады. Үтсә, фәкать икенче күрьядән үтә алачак иде. Түбән табәка [*катлау, дәрәҗә*] халык никадәр мине теләсәләр дә, ләкин мин үземне үзем дөрес танып, һәрничек тә Г. думада мин присяжный поверенный кадәр хезмәт итә алмаячагымны уйлап, кандидатлыгымнан имтинаг итеп [*баш тартып, үземне тыеп*], урынны Әхтәмевкә калдырдым. Уфада булган болар вә башка (түбәндә язылачак) гыйльми вә иҗтимагый хезмәтләрем хакында уфалы иптәшләрдән Габдулла Шонаси, Һади Килдебәки, Фәрхетдин Әхмәдев вә башкалар, кыйсмән Галимҗан Ибраһимов таныклык бирә алырлар. Сүзнең кыскасы, Уфада мине тулы мәгънәсе белән гыйлем әһеленнән вә халык хезмәтчеләреннән һәм тарих мөтәхассыйс [*белгеч*] саныйлар. Кирәк татар-башкорт, кирәк урыслар арасында нинди генә гыйльми һәйәтләр [*комиссия, комитет*] вә җәмгыятьләр гаммәид халык хезмәтләре булмасын, мине әгъзалыкка чакыралар, хәтта тартып кертәләр диярлек иде. Урыслар минем хазир [*күз алдында булган, шунда булучы*] булуымны гүя бөтен мөселман представительләре хазир булган шикелле хисапларлар иде. Уфадан Казанга кайтачак булгач, Уфа гыйлем ияләре вә гыйлем дуслары угылым Солтанәхмәт белә (чөнки аның да Уфада байтак мәдәни хезмәтләре күренгән иде) икебезгә хөрмәт өчен зур зыяфәт [*кунак итү, хөрмәтләү*] мәҗлесе ясап, минем гыйльми вә иҗтимагый хезмәтләремне яд итеп [*искә төшереп, телгә алып*] «адрес» һәм ядкарь булсын өчен кыйммәтле «өстәл сәгате» бирделәр...

*Дәвамы киләсе санда*

УФК 811.512.145'366

*Ф.Ә. Ганиев*

## ТАТАРНЫҢ ҮЗ ДӘҮЛӘТЕ КАРШЫНДА НИ ГАЕБЕ БАР?

В статье рассматривается состояние усвоения татарского языка в системе учреждений просвещения в Республике Татарстан. В настоящее время проведение осуществления постепенного сокращения изучения татарского языка под разными названиями «национальный компонент», «оптимизация» и т.п. является непоправимым недостатком в жизни общества.

В дореволюционной России, в так называемой «тюрьме народов», в медресе «Мөхәммәдия» (Казань), «Хөсәения» (Оренбург), «Галия» (Уфа) преподавание многих предметов велось на национальном языке, от этом свидетельствуют их учебные программы.

В статье приводятся основные пункты «Европейской хартии региональных языков и языков меньшинств, где говорится о необходимости изучения региональных языков и языков меньшинств на всех ступенях просвещения как дошкольного, так и довузовского.

Ставится вопрос: правомерно ли для татар, сложивших несколько сот тысяч голов своих солдат, наряду с солдатами других национальностей, отстоявших целостность своего государства, право на свой язык и культуру. Достаточно привести подвиг джалиловцев, даже под топором гитлеровских фашистов оставшихся поэтами своего языка. По мнению автора, постепенное, сначала еле заметное умаление национального образования является едкой закваской для развала дружбы народов, в итоге и государства.

Автор сомневается, не имеются ли здесь руки чужих государств, день и ночь мечтающих развалить Россию.

**Ключевые слова:** Совет Европы, хартия, учебная программа, медресе, оптимизация, национальный компонент, дружба народов.

Татар халкы, мәгълүм булганча, инкыйлапка кадәр милли мәгарифне, дәүләттән бер тиен акча алмыйча, үзе тартып барган. Халыкның башлангыч, урта һәм «Галия» кебек гали (югары) мәдрәсәсе (мәктәбе) булган. «Мәдрәсә» дигән сүзне, аның эчтәлеген бүгенгә көнгә кадәрле дини уку йорты дип безнең башка сеңдерә килделәр. Мондый фикер дәреслекләргә дә, башка китапларга да кергән. Чынлыкта исә «мәдрәсә» дигән сүз «дәрес» (укыту) дигән сүзнең бер бабы (формасы) гына.

Миңа инкыйлапка кадәрге ике мәдрәсәнең – Оренбургтагы «Хөсәения» һәм Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәләренең уку-укыту программасы белән танышырга туры килде. «Хөсәения» мәдрәсәсенең ул вакыттагы шәкерте Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына үзе тәмамлаган мәдрәсә турында якынча 150 биттән гыйбарәт язма алып килгән иде.

Аны шул чорда безнең институтның директоры Я.Г. Абдуллин институтка сатып алды. Бу язмага кушымта итеп, әлеге мәдрәсәнең уку-укыту программасы бирелгән иде. Ул кушымта белән танышкач, мәдрәсәнең бөтен асылы белән дөньяви урта мәктәп булуы ачыкланды. Аның уку-укыту программасында, рус гимназияләрендәге кебек, нигездә дөньяви предметлар каралган иде. Анда рус теле дә укытылган. Дөрес, шулар белән беррәттән, ул программада, нәкъ рус гимназияләрендәге «закон Божий» предметы кебек, ислам диненә караган предмет та кертелгәнлеге билгеле булды. Рус гимназияләренең, аерым алганда, Сембердәге гимназиянең программасы ул биргән аттестатта бик ачык күренә иде. Бу аттестат күп кенә дәреслекләрдә китерелде. Анда «закон Божий» предметының укытылуы ап-ачык күренә.

Казан дәүләт университетында «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе турында моннан берничә ел элек җитди һәм төпле диплом эше якланды. Мин, дәүләт аттестация комиссиясе рәисе буларак, ул диплом эше, аңа кушымта итеп бирелгән уку-укыту программасы белән таныштым. Ул программа рус гимназиясенең уку-укыту программасын хәтерләтә. Анда да, рус гимназияләрендәге «закон Божий» кебек, ислам диненә караган предмет та кертелгән. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең дә программасы «Хөсәения» мәдрәсәсенекеннән нигездә аерылмаганлыгы ачыкланды. «Галия» мәдрәсәсендә дә шундый программа булганлыгы билгеле. Күренгәнчә, инкыйлапка кадәр үк (башлангыч мәктәп-мәдрәсәләр турында сөйләп тә тормыйча) татар телендә урта белем бирә торган уку йортлары булган. Татарларның мәгариф эшенә, кагыйдә буларак, «халыкларның төрмәсе» булган патша Россиясе дә тыкшынмаган. Дөрес, аерым мәдрәсәләрне (мәктәпләрне) тегеләйме-болаймы кысарга омтылганнар, әмма, гомумән алганда, мәдрәсәләр, татар телендә дөньяви белем бирә торган уку йортлары буларак, яшәүләрен дәвам иткәннәр.

Хәзерге көндә исә, Россиянең мәгариф җитәкчеләре «милли компонент», «оптимизация» дигән сәяси төшенчә астында халыкларга үз телендә белем бирүгә балта чабарга омтылалар, ягъни патша самодержавиесеннән бик күпкә арттырып җибәрәләр. Демократик Россия дип аталган дәүләтнең учреждениеләре нишләп кеше күзе күрмәгән, колагы ишетмәгән мондый гамәлләр юлына баса? Моны ничек аңларга? Татар халкының Россия алдында нинди гаебе, гөнаһы бар соң? Татарстан үз территориясендә бернинди дә эксцессларга, экстремизмга юл куймый. Салымнарны үз вакытында түләп бара. Ул салымнардан, башка халыкларга бирелгән кебек, татарның мәгарифенә дә тиешле күләмдә акча бүлеп бирелергә тиеш. Татарстан нефтьтән килгән керемнең иң зур өлешен Мәскәүгә җибәрә бара. Монысы бер яктан булса, икенче яктан, татар халкы, аның уллары чит ил басып алучыларына (Наполеонга – «тептярские полки», Гитлерга) каршы сугышта, руслар һәм баш-

ка халыклар белән бергәләп, Россиянең бөтенлеге, бәйсезлеге, байлыгы өчен җанын-тәнен җәлләмичә сугыштылар. Моны Россиянең Бөек Ватан сугышындагы армия җитәкчеләре һәрвакыт ассызыклап әйтә килделәр.

Бу фикерне раслау өчен Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырлыкларын күрсәтеп узу да җитә. Җәлилчеләр телебезне кимсетү, мәдәниятебезне, әдәбиятыбызны һ.б.ны кысу өчен палач балтасы астына керделәрме? Руслар һәм башка халык солдатлары белән беррәттән сугышкан татарлар «милли компонент»ны кыскарту яки бетерү өчен сугыштылармы? Бөек Ватан сугышында гына да җаннарын җәлләмичә, берничә йөз мең татар солдаты башларын салды. Бүгенге көндә нәрсә күрәбез? Ягъни халыклар дуслыгы җиңеп чыккан сугышның уңай нәтиҗәләре кайбер халыкларга ягылмый булып чыга.

«Милли компонент» дигән төшенчә астында татар телендә белем алуны кысу яки тыю халыкара документларга каршы килә. Хельсинкида кабул ителгән Йомгаклау акты, 1990 елдагы Копенгаген киңәшмәсенең документы, Гражданлыкка караган һәм сәяси хокуклар турындагы Халыкара пакт, Кеше хокукларын һәм төп ирекләрне яклау турындагы Европа конвенциясенең эчтәлекләре һәм рухы Россия тарафыннан бөтенләй онытылган булып чыга.

Мәгълүм булганча, шул документларга таянып, Европа Советы региональ телләр һәм азсанлы халыклар телләре турында Европа Хартиясен кабул итә (5 ноябрь, 1992 ел). Бу Хартиягә Россия кул куйган. Димәк, кул куйгач, Россия, нигездә, аның төп принциплары белән риза булган дигән сүз. Ул Хартиядә региональ телләр һәм азсанлы халыклар телләре культура байлыгы дип игълан ителә.

Анда мәгариф (белем бирү) өлкәсендә түбәндәгеләр каралган:

1) региональ телләрдә яки азчылык халыклар телләрендә **мәктәпкәчә белем бирергә** мөмкинлек тудырырга; яки **мәктәпкәчә белем бирүнең шактый өлешенә** тиешле региональ телләрдә һәм азчылык халык телләрендә мөмкинлек тудыруны тәэмин итәргә;

2) региональ телләрдә һәм азчылык халыклар телләрендә **башлангыч белем бирү** өчен мөмкинлек тәэмин итәргә; яки региональ телләрдә һәм азчылык халыклар телләрендә башлангыч белем бирүнең **шактый өлешенә мөмкинлек тәэмин итәргә;**

3) региональ телләрдә һәм азчылык халыклар телләрендә **урта белем бирергә мөмкинлек тәэмин итәргә**; яки региональ һәм азчылык халыклар телләрендә **урта белем бирүнең шактый өлешенә** мөмкинлек тудырырга;

4) региональ телләрдә яки азчылык халыклар телләрендә университет һәм югары белем бирү дисциплиналары сыйфатында **бу телләрне өйрәнү өчен шартлар тудырырга**; яки региональ телләрдә һәм азчылык халыклар телләрендә университет белеме яки югары белем **бирүне хупларга һәм** (яки) **моңа юл куярга** (*тәрҗемә – мәкалә авторыныкы*).

Күренгәнчә, югарыда китерелгән Хартиядә, белем бирүнең

**барлык баскычларында** региональ һәм азчылык халыклар телендә белем бирүне тәэмин итәргә, диелгән. Ничек инде Россия үзе кул куйган документны сызып атарга батырчылык итә? Билгеле булганча, шундый ук хәл Балтыйк буе илләрендә бара. Ул республикаларда азчылык тәшкил иткән рус теленә каршы төрле гамәлләр кылына. Россия моны һич кабул итә алмый һәм, һичшиксез, дөрес эшли. Әмма ул үз илендә шундый телләрне кысу, аларга тиешле ирек бирмәү гамәлләрен куәтли. Шулай итеп, бер үк проблемага карата ике төрле стандарт килеп чыга. Моның белән аек акылы булган кеше, әлбәттә, килешә алмый.

Кайсы яктан карасаң да, «милли компонент» төшенчәсенә төренеп, телне кысуны яки бөтенләй юкка чыгарырга омтылуны бернәрсә белән дә аңлатып булмый. Нишләп ул термин, мәсәлән, татар теленә яки башка региональ телләргә карата гына кулланыла – аңлашылмый. Россияне, аның халыкларын үз итмәгән, яратмаган, Россиянең бөтенлегенә каршы булган әһелләр генә мондый гамәлләр юлына басарга мөмкин.

Уйлап чыгарылган, акылга сыймас «милли компонент», «оптимизация» төшенчәсенә төренеп, гомер-гомергә дус, тату яшәгән Россия халыкларына карата, аларның мәгарифенә, мәдәниятенә, теленә карата алып барылган бу гамәлләр Россияне дәүләт буларак ныгытмый, киресенчә, башта бу хәл артык сизелмәсә дә, аны эчтән җимерүнең **эче оеткысы** гына булып торалар. Бәлки, моңа без белмәгән көчләр сиздермичә катнашадыр? Моны югарыдагы мәгариф җитәкчеләре, ни өчендер, аңлап җиткермиләр кебек.

**Әдәбият**

Совет Европы. Европейская хартия региональных языков и языков меньшинств (ETS №148). (Страсбург, 5 ноября 1992 года).

Татарстан Республикасы телләре турында Татарстан Республикасы Законы. Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы. Казан. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы басмасы, 1996, 41 бит.

***Ганиев Фуат Әшраф улы,*** филология фәннәре докторы,
*Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, профессор,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гомуми лингвистика бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

.

УДК 745

*Л.М.Шкляева*

# XX–XXI ГАСЫРЛАРДА УРТА ИДЕЛ БУЕ АВЫЛЛАРЫНДА ЯШӘҮЧЕ ТАТАРЛАР ЙОРТЫНЫҢ ТЫШКЫ БИЗӘЛЕШЕНДӘ КОШЛАР ОБРАЗЫ
## (2013 елгы экспедиция нәтиҗәләре буенча)

Декоративная отделка фасада дома является традиционным видом народного творчества. Исследуемый вид художественной обработки дерева связан с оформлением наличников окон. В зооморфной группе орнаментальных мотивов рассматривается изображение птиц. Деревянная резьба сельских строений, исполненная татарскими мастерами на рубеже XX–XXI вв., раскрывает в символических образах эстетические идеалы, указывает на преемственность и связь с тюркским (булгарским) культурным наследием.

**Ключевые слова**: татары Среднего Поволжья, резьба по дереву, декор сельских строений, орнитоморфный орнамент, символика богини Умай, образ птицы, песенный фольклор.

Авыл төзелешләрендә агачтан кисеп эшләнгән бизәкләр төшерү элек-электән киң таралган. XX гасырда һәм XXI гасыр башында Урта Идел буйларында ул аеруча киң таралыш ала. Авыл өйләренең фасадын матур итеп бизәү халык иҗатының традицион бер төрен тәшкил итә [Бусыгин...]. Орнаментлар белән бизәү мотивы бик борынгыдан ук килә, һәм ул, һаман камилләшә барып, теге яки бу формада (интерпретациядә) хәзер дә кулланыла. Халык сәнгатенең бу төрен тикшеренүчеләр төрки мәдәниятнең консервативлыгын «позволяющая сохранить неизменности свою основу вплоть до наших дней» дип билгеләп үтәләр [Халит..., с. 46]. Татар авылларындагы корылмаларның пластик сәнгать стиленә нигезләнгән төзелеше һәм аларның композицион элементлары, тышкы бизәлеше XVIII гасырдан ук инде Европа галимнәренең игътибарын җәлеп иткән [Георги, с. 15]. Бу өлкәдә беренче булып комплекслы һәм системалы тикшеренүләрне П.М. Дульский[1] [Дульский, с. 10] белән Ф.Х. Вәлиев[2] [Вәлиев, 1984] һәм тагын кайбер сәнгать белгечләре алып баралар. Алар торак йортларны агачтан кисеп эшләнгән орнаментлар белән бизәүнең күп кенә үзенчәлекле мотивларын – геометрик, зооморф, соляр (кояштан тарала торган нурлар рәвешендәге) бизәкләрнең тотрыклы кулланылуын ачыкладылар. Бу мәкаләдә зооморф төркемнән кошлар сурәте белән бизәкләү игътибар үзәгенә алынды. Орнитоморф (грекчадан: кошсыман) орнаментлар темасын тагын да тирәнәйтү максатыннан, 2013 елда Республикабызның Мамадыш районы авылларына оештырыл-

ган фәнни экспедиция материаллары файдаланылды. Районның 23 авылында булып, XX гасырның икенче яртысында һәм XXI гасырның башларында төзелгән агач биналарның хронологик кысалары билгеләнде. Аларны төзүче-осталар, нигездә, татарлар булуы ачыкланды.

Без, агачны сәнгатьчә эшкәртү төре буларак, тәрәзә-ишек йөзлекләре бизәлешен өйрәндек. Традицион сәнгать үсеше процессларын, алардагы чимал, демографик, дөньяга караш һәм башка фактларга бәйле күренешләрне өйрәнү бу өлкәдә бернинди дә очраклылык элементлары булмавын раслады. Бизәлеш өчен сайланган образларда халыкның тарихи хәтере чагылыш ала. Мамадыш районында яшәүче татар йортларының тәрәзә йөзлекләре өстенә бер-берсенә охшаш стильдәге кош рәсеме төшерү – ул борынгыдан килгән традиция. Чөнки кош ул татарлар аңына борынгыдан кояш һәм яктылык символы булып сеңдерелгән [Валеев..., 2002, с. 84]. Кошлар Идел Болгарстаны төрки кабиләләре тарафыннан изгеләштерелгән, болгарның декоратив-гамәли сәнгать әйберләрен кош рәсеме белән бизәкләү шуннан килгән [Валева, 32–34].

«После принятия ислама булгарами, их языческие традиции удержались в дальнейшем в суевериях и обычаях, которые способствовали сохранению отдельных языческих изображений, особенно птиц, имевших, видимо, значение оберегов» [Валеев, 1969, с. 99].

Төркиләрнең изгеләштерелгән кошында йорт һәм гаиләне саклаучы-яклаучы алиһә Умай[3] гәүдәләнеш ала [Потапов, с. 265]. «Ләйлә белән Мәҗнүн» эпик дастанының татар вариантында ул Һумай дип искә алына. Һәм, Һумай кошның күләгәсе генә төшсә дә, ул кешегә бәхет киләә, дип бәян ителә [Мухаметзянова, с. 285–286]. Тикшеренүчеләр Урта гасыр Болгарстаны символлары татарлар аңында аваздашлык табуын раслыйлар.

Бүгенге авыл осталары, элеккеге традицияләрне дәвам итеп, кошлар сурәтен, шартлы рәвештә генә булса да, тирәлек белән өй эчен тоташтырган урыннарга куялар. Казан арты татарлары йортларындагы тәрәзә йөзлекләре кәрниз асты яссылыгына агачтан кисеп эшләнгән бизәкләр төшерүне өйрәнгән Ф. Вәлиев XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы агач бизәкләрендәге канатларын җәйгән бер яки ике башлы кош фигураларын тасвирлый. Анда орнитоморф мотивның, әкренләп, геометрик орноментка охшый баруына игътибар итә [Валеев, 1969, с. 101].

Мамадыш районындагы агач бизәкләрдә кире процесс күзәтелә, анда Урта Идел буе кошлар дөньясын чагылдырган, реаль прототиплар сыйфатларына ия булган кошлар образлары гәүдәләнеш ала. Тәрәзә йөзлекләренең өстенә урта бер җиргә агачтан кисеп яки уеп ясалган күгәрчен, аккош, сандугач, карлыгач һәм үрдәк рәсемнәре беркетелгән. Бүгенге традицияләргә туры китереп, аларны парлап, бер-берсенә каратып урнаштыралар. Аларны шулай урнаштыру композицион яктан бердәмлекне, үзара бәйләнеше символлаштыра. Йорт

хуҗаларыннан сораштырып белгәнебезчә, авыл кешеләре (социомәдәни тирәлек) кошлар сурәтен үзенә бер әһәмияткә ия булган элемтә, үзара бәйләнеш дип кабул итәләр икән. Аларның мондый символик күзаллаулары, татар фольклор әсәрләрендә чагылыш тапканча, кошлар рухи кичерешләр кебек антропологик сыйфатларга ия, дип инануларыннан килә. Халык җырларында сандугач, аккош, карлыгач, күке һ.б. кошларга еш мөрәҗәгать итү дә шуның белән бәйле булса кирәк. Татар халык җырларын тикшереп өйрәнүче галимнәрдән К.М. Миңнуллин бу хакта болай дип яза: «...что образы птиц могут быть использованы как символы красоты, любви, а также – изобилия и благополучия. Однако другое символическое значение этих образов, равно как и основной мотив песен, в которых они употребляются, все же – печаль, грусть, тоска, и разлука» [Миннуллин, с. 38].

Авыл өйләренең ишек-тәрәзә йөзлекләрендәге сәнгатьчә эшләнгән күгәрченнәр барлык башка бизәлешләргә хас стиль үзенчәлекләрен дә чагылдыра. Алар, кагыйдә буларак, ак төстә, тәрәзә йөзлегенең өске өлешенә бер-берсенә каратып (профильдә) төп контурга ябыштырып урнаштырылган. Кошның канатлары нәфис итеп, челтәрсыман тишекләр белән киселгән, ул чынлап та очып китәр сыман. Күгәрчен сурәтен гәүдәләндерүдә һәр авылның үз стиле бар. Мәсәлән, керәшеннәр яши торган Владимир авылында аларны абстракт рәвештәге геометрик формада өзек-өзек сызыклар ярдәмендә эшләгәннәр. Төсләре яшел булып, ак фонга урнаштырылган. Аларның күгәрченнәр булуын силуэтларыннан гына төшенәсең, чөнки томшык һәм тәпиләре ачык итеп ясалмаган. Югары Кыерлы (Берсут) йортларында зәңгәр йөзлекләргә пар ак күгәрченнәр төшерелгән. Шартлы рәвештә генә ясалган башлары бер-берсенә орынып тора. Гомумиләштерелгән силуэтта аяклары, күпереп торган койрыклары аерымлана. Челтәрләп кисү техникасы осталары кошларның канатларына уртасы ноктaлы түгәрәк уйганнар, бусы инде халыкта онытылып бара торган галәм символын тасвирлауны аңлата. Мондый тамгалар Биләр[4] археологик казылмалары табылдыклары бизәлешендә еш очрый [Хузин, с. 3]. Д.К. Вәлиева язуынча, уртасында нокталы түгәрәк рәсеме төшерү ул игенчеләр һәм терлекчеләр кулланган тамга буларак мәгълүм [Валеева, с. 10].

Кече Сон авылында күгәрченнәрнең бирелешен башка вариантта очраттык. Ак фонга төшерелгән күк төсле эре күгәрченнәр гөрләшеп яшәүче парны хәтерләтәләр. Алар бер-берсенә якын урнаштырылган, ә башлары төрле якка борылган. Өч ярымтүгәрәк эченә урнаштырылган тәпиләре, күпереп торган койрыклары чалымланып торган пар күгәрченнәрнең бизәкләргә бай силуэты аеруча матур булып күренә. Һәр кошның тәнендәге каурыйларына хәтле беленеп тора, алар челтәрсыман кисү техникасы буенча эшләнгән.

Тәрәзә йөзлекләре бизәлешендә кулланылган күгәрчен

силуэты Яке авылында башкача урнаштырылган: анда симметрия белән куелган кошлар берберсен үбеп торалар. Йөзлекнең өстендәге кошларның канатлары җыелган, тыныч хәлдә. Аларның силуэты дулкынсыман, сызыклары бераз бөгелгән, койрыклары озын һәм өскә таба күтәрелебрәк тора, канатлары челтәрсыман ярымтүгәрәкләр булып горизонталь урнашкан. Йортның сары төстәге фасадына беркетелгән караңгы яшел йөзлектә ак күгәрченнәр бик матур күренә, оста аларны челтәрсыман киселгән бураны хәтерләтә торган кыса эченә урнаштырган (Яке авылының Ленин урамындагы 5 нче йорт).

Күкчишмә авылы осталары күгәрченнәрне гәүдәләндерүнең үзенә бер сәнгати ысулын тапканнар. Зәңгәрсу күк төсендәге йөзлеккә кошларның гәүдәләрен, контурлап кисү техникасы буенча, түгәрәкләп эшләгәннәр, койрыклары декоратив кайманы хәтерләтеп, бөгелеп тора. Томшык һәм тәпиләре бөтенләй төсмерләнми.

Менделеев районының Старое Гришкино авылында яшәүче керәшеннәрдә дә тәрәзә йөзлекләрен кош сурәтләре белән бизиләр. Алар күгәрченнәрне тактадан тоташ кына кисеп алып беркеткәннәр. Ачык зәңгәр төстәге өслектә ак чәчәкләр һәм очышта сурәтләнгән күгәрченнәр язгы бакча күренеше фрагментын хәтерләтәләр. Ир белән хатын татулыгы аларда, күгәрченнәрдән тыш, башка кошлар сурәтләре белән дә символлаштырыла.

Мамадыш районының Баскан авылында гаиләдә үзара тугрылык, татар халык җырларындагыча, аккошлар образында гәүдәләндерелә. Авылда торак йортларны, су стихиясе, йә булмаса болын киңлекләре төсләре гаммасына туры китереп, зәңгәр, фирәзә сыман һәм яшел төсләргә буярга яраталар. Бу төсләр фонында өйнең кәрниз асты өлешендәге һәм тәрәзә йөзлекләренең өстендәге ак кошлар ап-ачык булып аерылып торалар. Ягъни бу авылга хас стиль шунда ук күзгә ташлана. Аккошлар, симметрияне төгәл саклап, парлап, башлары үзәккә карап урнаштырылган. Силуэт ян белән (профильдә) бирелгән. Аккошлар әз генә калкып торган канатларына нәфис муенnарын түгәрәкләп иелә төшкән халәттә сурәтләнгән. Томшыклары күренми, әйтерсең аларны каурыйлары арасына яшергәннәр. Койрыкларының очы йөзлек бизәгенә тоташып китә. Баскан авылында фасад төзелешендә башка төсләр дә кулланыла (мәсәлән, Җиңү урамының 13 нче йортында), әмма кошларны сурәтләү стиле үзгәрми. Тактадан лобзик ярдәмендә кисеп алып, тәрәзә йөзлегенең өстенә урнаштырылган пар аккош өйнең фасадын бизәп кенә калмый, өйдә яшәүче ир белән хатынга тигез мәхәббәт, үзара тугрылык, дус-тату тормыш теләүче символ булып та санала. «Согласно древней тюркской легенде, лебедь олицетворяет богиню Умай, которая стала одним из участников сотворения мира. Фигуры лебедей украшают подкарнизные бордюры султанской юрты на рисунке XVI в. и золотоордынские зеркала XIV в.» [Халит..., с. 57].

Гаилә бәхетенә юнәлгән тагын бер символ – сандугач сурәтен гәүдәләндерүне Яке авылында очратасың. Тышкы яктан зәңгәр төскә буялган бер йортның фасадындагы өч тәрәзә дә яшел йөзлек белән уратып алынган. Аларның һәркайсының кырыйларына, парлап сандугач рәсемнәре төшерелгән. Алар, көзгедән чагылгандай, симметрия белән бер-берсенә карап урнашканнар. Тәрәзә йөзлекләре эшләүче оста, кошларны кисеп алганда, аларның томшыкларын да, йөзлеккә тиеп торган тәпиләрен дә күренерлек итеп эшләгән. Сандугачлар әйтерсең, кешеләр әйткәнчә, чут-чут сайрап, үзләренең язгы мәхәббәт җырларын башкаралар. «Соловей воспевается как задушевный друг влюбленных пар и как постоянный спутник одиноких, тоскующих людей» [Миннуллин, с. 37].

Еш кына татар авылларының тәрәзә йөзлекләре бизәлешендә каз башы рәсемнәрен дә очратырга туры килә, алар тәрәзәнең як-ягында һәм төгәл симметрия белән уртага таба каратып урнаштырылганнар. Кайбер галимнәр фикеренчә, каз болгарлар культурасында, исламны кабул иткәнче үк (VIII–IX гасырларда), нәселне саклаучы символны аңлаткан. Каз образы Алтын Урда чоры металл һәм керамика эшләнмәләрендә дә очрый, алар – болгарда анималистик сәнгать үсешен дәлилләүче фактлар [Валеев..., с. 27].

Хәзерге вакытта кош сурәтен гәүдәләндерүдә үткәннәр семантикасының кайтавазы да чагылуын билгеләп үтәргә кирәк. Мамадыш районының керәшеннәр яши торган Никифорово авылы кешесе Н.В. Михайлов тәрәзә йөзлекләренең өске өлешенә куела торган орнаментларның мәгънәви төшенчәсен үзенчә болай дип аңлатты: «Түгәрәкнең уртасындагы бизәк – хатыным белән мин һәм безнең янда яши торган улыбыз. Йөзлекнең ике ягына урнаштырылган каз башлары – безнең башка балаларыбыз, алар, өйдән китсәләр дә, туган йортларын онытмыйлар, аның ягына карап торалар, каз башларының як-яктан түгәрәккә таба юнәлүе шуны аңлата. Боларны миңа бабам аңлатты». Кош башларын символлаштырган фигуралар көчле стильләштерелгән һәм алар сузылып торган тамчы фигурасын хәтерләтәләр. Халык сәнгатенең сынлы чаралары «телен» аңлау өчен ата-аналар белән балалар арасында хөкем сөргән традиион тәртипләрне чагылдырган символларны «укый» белергә кирәк.

Төзелешләрнең тышкы бизәлешендәге әйтеп үтелгән орнитоморф орнамент үрнәкләре, респондентлар сүзләренә караганда, гаиләгә бәхет китерүче символлар булып саналалар. Кошлар образының торган саен киңрәк кулланылуы сәбәпле, гаиләне саклаучы алиһә Умайны гәүдәләндерү халыкта онытыла бара. Шул ук вакытта геометрик формадагы бизәлеш техникасын куллану дәвам итә. Мамадыш районы территориясендә тәрәзә йөзлекләренә пар кошлар кисеп беркетү техникасы киң таралган; аларны эшләүнең сәнгати алымнары башкаручы осталарның үз

фантазияләреннән чыгып кына аерыла. Тагын шуны билгеләп үтәргә кирәк: татар авылларында төзелешләрнең экстерьерын бизәүдә ислам тәгълиматы йогынтысы да сизелә. XX гасыр –XXI гасыр башында Урта Идел буенда яшәүче татарларның декоратив-гамәли сәнгатендә бизәкләрне агачтан кисеп алып эшләү төре аеруча үсеш ала, аларда әле хәзер дә халык арасында сакланып килгән символик тел һәм семантика өстенлек итә.

**Әдәбият**

*Бусыгин Е.П., Зорин Н.В., Токсубаева Л.С.* Декоративное оформление сельского жилища в казанском Поволжье. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 127 с.

*Валеев Ф.Х.* Народное декоративное искусство Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 188 с.

*Валеев Ф.Х.* Орнамент казанских татар. Казань: Татар. кн. изд-во, 1969. 203 с.

*Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Древнее искусство Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. 104 с.

*Валеева Д.К.* Искусство волжских булгар (X–XIII вв.). Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. 132 с.

*Георги И.Г.* О народах татарского племени // Описание всех обитающих в Российском государстве народов: их житейских обрядов, обыкновений, одежд, жилищ, упражнений, забав, вероисповеданий и других достопримечательностей. Т. 2. СПб., 1776. С. 14–15.

*Дульский П.М.* Искусство казанских татар. Москва: Центральное издательство народов СССР *(сохранена орфография издания),* 1925. 58 с.

*Миннуллин К.М.* Жанр песни в татарской поэзии: дис …. канд. филол. наук. Казань, 1996. 157 с.

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос. Книжные дастаны. Казань: ИЯЛИ им. Ибрагимова АН РТ, 2014. 380 с.

*Потапов Л.П.* Умай – божество древних тюрков в свете этнографических данных // Тюркологический сборник 1972 г. М.: Наука, 1973.

*Халит Н. Х., Альменова-Халит Н. Н.* Стили и формы средневековой архитектуры Казани: историко-архитектурное исследование. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. 351 с.

*Хузин Ф.Ш.* Культура Биляра. М.: Наука, 1985. 215 с.

**Искәрмәләр**

[1] Дульский Петр Максимович (1879–1956) – күренекле рәссам һәм музей белгече, сәнгать белгече.

[2] Вәлиев Фуад Хөсәен улы (1921–1984) – танылган тарихчы, этнограф, сәнгать белгече, тарих фәннәре кандидаты, сәнгать фәннәре докторы.

[3] Умай – борынгы төркиләр алиһәсе.

[4] Биләр шәһәрлеге – урта гасырлар эпохасының иң зур һәйкәле, X–XIII гасырлар Идел Болгарстаны башкаласының археологик калдыклары.

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 76:94(47).084.8

*С.Е. Новикова*

# ХАРИС ЯКУПОВНЫҢ ФРОНТ ГРАФИКАСЫ

Статья посвящена фронтовой графике народного художника РСФСР и СССР Хариса Якупова (1919–2010), прошедшего практически всю Великую Отечественную войну. Анализируются произведения собрания Государственного музея изобразительных искусств РТ, выставленных в галерее «Хазинэ», и коллекции семьи художника.

**Ключевые слова:** Харис Якупов, фронтовая графика, графический портрет, рисунок карандашом, акварель.

Быел май аенда Россия Бөек Җиңүнең 70 еллыгын билгеләп үтте. Җиңелү һәм җиңүләр белән узган дүртьеллык авыр сугыш чоры ераклашканнан-ераклаша бара. Әмма бу сугыш афәте һич кенә дә онытылмый. Аның турында яңа фильмнар төшерелә, китаплар чыга, компьютер уеннары иҗат ителә. Бөек Ватан сугышында һәлак булган солдатларның якыннары, туганнары, оныклары аларның инде саргаеп өлгергән фотоларын кабат-кабат кулларына алалар, алар турында нинди дә булса өстәмә мәгълүматлар алу өчен архивларга мөрәҗәгать итәләр, интернет-сайтлардан эзлиләр. Замандашларыбыз Бөек Җиңүнең дөньякүләм әһәмиятен тирәнрәк төшенергә омтылалар.

Ул сугышны күрмәгән буын өчен Харис Абдрахман улы Якуповның фронт эпизодларын мәңгеләштергән рәсемнәре бүгенге көндә шул чорның мөһим документаль шаһиты булып санала. Рәссамның сугыш елларын чагылдырган 150 дән артык рәсеме, плакат эскизлары, китап һәм журнал тышлыклары һәм хәрби тема буенча иҗат ителәчәк рәсемнәре өчен караламалары бар. Ул хезмәтләрнең күбесе рәссамның гаиләсендә саклана, ә бер өлеше Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музеена куелган.

Ихластан һәм зур төгәллек белән эшләнгән фронт күренешләре, һичшиксез, сәнгатьтә уникаль әсәрләрдән саналалар. Алар безгә үткәннәрне – авыр сугыш елларын, фронт тормышын, кораллы бәрелешләр киеренкелеген, уңышлар һәм зур җиңүләрне – бөтен тулылыгы белән күзалларга мөмкинлек бирүче тылсымлы көчкә ия. Ул рәсемнәр, сынлы сәнгать әсәрләре генә булып калмыйча, вакыйгаларны төгәл чагылдырган, аларга авторның шәхси мөнәсәбәтен дәлилләгән, замандашларының тәҗрибәсен һәм субъектив карашларын гәүдәләндергән тарихи документ буларак та безгә кадерле. Рәссам

үзенең полкташларының, командирларының, тыл хезмәтчәннәренең, әсирләрнең – җиңүчеләр һәм җиңелүчеләрнең портретларыннан торган тулы бер галерея иҗат итә.

Әле иҗат дөньясына аяк кына баскан Казан сәнгать училищесы студенты Харис Якуповка Бөек Җиңүгә юл бик озын була... 1940 елның гыйнварында ул Казан Армия сафларына чакырыла, һәм шуннан ул фәкать 1945 ел ахырында гына Казанга, өенә әйләнеп кайта. Сержант Якуповның сугыш юлы өч меңләп чакрымга сузыла: Көньяк-Көнбатыш фронт, Брянск, Үзәк һәм 1943 елның октябреннән 1 нче Украина фронтлары. «Хәрби хезмәтләре өчен» медале, Кызыл Йолдыз һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә. Сугыш еллары турында Харис Абдрахман улы «Фронтовые зарисовки. Записи художника» дигән китабында түбәндәге юлларны яза: «Я воевал четыре года. У меня сохранилось три походных альбома с рисунками. Они были выполнены “для себя” в трудных условиях фронтовой жизни, в дни затишья между боями, главным образом ночью при коптилке из гильзы артиллерийского снаряда. Рисунки эти являются наглядными свидетельствами виденного и пережитого на дорогах войны. В них образы моих друзей, погибших и оставшихся в живых. В них трагические дни лета 1941 года, радость наших побед, тысячи километров боевого солдатского пути, пройденного от Могилева до Ельца в дни отступления, и от Ельца до столицы Чехословакии – Праги» [Якупов, 1981, с. 10].

Рәссамның үзе ясаган поход альбомындагы беренче рәсемнәре 1941 елның декабре белән даталанган. Чөнки сугышның беренче айларында дошман белән каты бәрелешләр була, безнең сугышчылар Брянск урманнары аша чолганыштан чыга, Совет армиясе солдатлары тәҗрибә туплау чоры кичерә. 1941 елның 9 декабрендә Елец шәһәре немецлар оккупациясеннән азат ителә. Бу беренче локаль җиңү була, шуннан башлап, Совет гаскәрләре Көньяк-Көнбатыш фронтта һөҗүмгә күчәләр һәм Көнбатышка юл алалар. Башка сугышчылар белән бергә шушы җиңүдән рухланган Харис Якупов кулына кәгазь, карандаш ала һәм сугышның соңгы көннәренә кадәр үзе күргәннәрне рәсемгә төшерүдән туктамый. Шул вакытта эшләгән «Елец. После уличных боев» дигән беренче рәсеме буенча, 25 елдан соң, «Елец 9 декабря 1941 года» картинасын иҗат итә. Ул картина хәзер Елец шәһәренең Крайны өйрәнү музеена куелган.

Альбом битләре авторның үз күргәннәреннән тиз-тиз ашыгып ясалган яки эшләнеп бетмәгән рәсемнәре белән тулган. Шунысы гаҗәп: Х. Якуповның беренче портретлары – әсир төшкән алман солдатлары. Яшь рәссам, күрәсең, башта иптәшләреннән, аларның көлеп карауларыннан оялган. Әмма полкташлары Бориснең (алар Харисны шулай атаганнар) шөгыленә зур хөрмәт белән караганнар. Һәм яшь рәссам, әкренләп, аларның пор-

третларын да ясый башлый. Сугышчылар исә үзләренең Харис ясаган портретларын, фотография урынына, өйләренә якыннарына җибәрә торган булганнар.

Рәсемнәрнең күбесе гади карандаш белән эшләнгән, тушь яки күмер, сирәк кенә акварель ярдәмендә ясалганнары да бар. Тора-бара аның альбом битләрендә булачак картиналарының әзер эскизлары – тоташ композицияләр дә урын ала башлый. Рәссам аларда төсне, яктылык төшкән якны, җил юнәлешен, торак пунктлар урнашу тәртибен, җирлек исемнәрен дә билгели барган. Харис Якуповның сугыш чоры иҗатында аның характер сыйфатлары (эшкә җитди карашы, кешеләргә игелеклелеге, көчле кызыксынучанлыгы) һәм Дивизия штабы, ә 1943 елдан 15 нче Укчылар корпусы штабы төзегән оператив карталар эшләү вакытында туплаган тәҗрибәсе уңышлы чагылыш таба. Үзенә йөкләнгән бурычны үтәү йөзеннән рәссамга, еш кына, алгы позицияләрдә булырга туры килә: мәгълүмат туплау өчен разведкага бара, хәрби операцияләрдә катнаша. 1943 елның 22 сентябрендә 148 нче Черниговск укчылар дивизиясе штабы башлыгы, подполковник Н.Г. Васин тарафыннан имзаланган Бүләкләү кәгазендә (Наградной лист) шундый юллар язылган: «Старшина Якупов к работе относится исключительно добросовестно, своевременно оформляет оперативную документацию и вовремя доводит ее до подчиненных штабов для исполнения, весьма энергичный и инициативный товарищ. В оборонительных и наступательных боях проявил себя смелым и решительным командиром. <…> В период боев за город Чернигов, проявляя инициативу и находчивость, своей самоотверженной работой способствовал успешному форсированию частями реки Десна и выполнению боевой задачи по овладению города. Достоин правительственной награды орденом Красная Звезда» [Приказ...].

1941–1945 елларда Харис Якупов, сугышчы гына түгел, ә фронт рәссамы буларак та зур тәҗрибә туплый. Рәсемнәренең эчтәлеге байый, альбом битләренең читендә командир приказларын тагын да төгәлләштергән һәм, хәтта, аларга хикәяләү рәвешендә ачыклыклар кертелгән язмалар өстәлә. Шулай ук анда тыныч тормыш, рәссам булырга хыяллануы турындагы фикерләрен дә терки бара.

1 нче Украина фронты сугышчылары җиңү маршы белән Польша, Германия, Чехословакияне үтәләр. Харис Якупов та, көрәштәш дуслары белән бергәләп, Краков, Катовице, Ратибор (1945 елда – Германиянеке; хәзер – Рацибуж, Польшага кера) һәм, ниһаять, Прагага килеп җитә. Харис Якупов 1945 елның 9 маен – Җиңү көнен – шушы чехлар башкаласында каршылый.

Харис Якупов, сугыштан соң Чехословакия белән Германиядә берничә ай хезмәт итә, ел ахырында гына демобилизацияләнә. 1945 елда эшләгән автопортретында «На Родину! Прощай, Германия! Чужая земля никогда еще

не становились для солдат матерью...» дигән юллар язылган.

Харис Абдрахман улы үзенең «Легко ли стать художником» дигән китабында болай дип яза: «Этих путевых рисунков накопилось довольно много. Они являются наглядным свидетельством увиденного и пережитого мною на дорогах войны. Я никогда не думал, что эти зарисовки когда-нибудь появятся на выставках, в печати и впоследствии они помогут мне создать ряд крупных полотен о былых сражениях» [Якупов, 2004, с. 39]. Һәм ул ничек ялгышкан! Казанда аны, гаиләсе һәм дуслары гына түгел, яраткан эше дә көткән. Сугыштан соңгы елларда рәссам тарафыннан төрле жанрларда (рәсем сәнгате, графика, плакат, китап һәм журнал иллюстрацияләре) йөзләгән әсәрләр иҗат ителә.

Х.А. Якуповның фронт елларында ясалган рәсемнәре, беренче мәртәбә, Җиңүнең берьеллыгына (1946) багышланган күргәзмәдә урын ала. Күренекле сәнгать белгече П.М. Дульский алар турында болай дип яза: «Экспрессивно выполнены рисунки молодого художника Х.А. Якупова: «Наши войска вступают 9 мая 1945 г. в город Прагу», «Штурм Тарнополя» и «Пленные немцы». Некоторые его рисунки подсвечены акварелью, что придает им жизненный характер» [Каталог...].

Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музееның «Хәзинә» Милли сәнгать галереясы күргәзмәләр залында Харис Якуповның шәхси галереясы да урын алган, анда рәссамның сугыш графикасы үзе бер аерым залны били.

Бөек Җиңүгә илткән авыр сугыш еллары хатирәләрен сынлы сәнгатьтә мәңгеләштерүче, тарихыбызны тудыручы шәхесләребез, әкренләп, арабыздан китә бара. Әмма аларның иҗат җимешләре Бөек Ватан сугышының һәлакәтен чагылдырган бәяләп бетергесез кыйммәткә ия документлар, шаһитләр һәм көндәлекләр булып сакланалар.

**Әдәбият**

Каталог выставки картин к годовщине «Дня Победы» Союз Советских художников ТАССР и Кооп. Т-во «Татхудожник» / Вст. ст. П.М. Дульского. Казань, 1946.

Приказ подразделения № 86/н от: 30.09.1943 Издан: 148 сд Центрального фронта // Архив ЦАМО, ф. 33, оп. 686044, ед.хр. 3571, № записи 20747167.

*Якупов Х.А.* Легко ли стать художником. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004.

*Якупов Х.А.* Фронтовые зарисовки. Записки художника. Казань: Татар. кн. изд-во, 1981.

***Новикова Светлана Евгеньевна,***
*Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 78:94(47).084.8

*З.Н. Сәйдәшева*

# ФӘРИТ ЯРУЛЛИН – КОМПОЗИТОР ҺӘМ СУГЫШЧЫ

Статья посвящена короткой, но весьма яркой творческой жизни композитора Фарита Яруллина, погибшего во время Великой Отечественной войны.

**Ключевые слова:** Фарит Яруллин, татарский балет, балет «Шурале», фронтовые концерты.

Татар композиторы Фәрит Заһидулла улы Яруллинның (1914–1943) иҗади эшчәнлеге фәкать 7 ел гына дәвам итә. Шушы кыска гына вакыт эчендә ул үзен гаҗәеп талант иясе итеп танытты.

Татар музыкаль сәнгатендә халык җырларын, вокаль музыка әсәрләрен (романслар, җырлар), инструменталь миниатюраларны эшкәртү жанры, фортепьяно һәм виолончель өчен соната жанры, кыллы квартет, симфония (кызганычка каршы, төгәлләнмәгән) һәм, иң мөһиме, татар балеты барлыкка килүне без аның исеме белән бәйлибез.

Яңалыкка омтылучан композиторның киң кырлы иҗади эшчәнлеге татар музыка белгечләренең игътибарын җәлеп итми кала алмый. Ч. Бәхтиярованың 1960, 1986 елларда Ф. Яруллин турындагы истәлекләре дөнья күрә, 1987 елда А. Алмазованың «Фәрит Яруллин и татарский балет» китабы, 1990 елда Р. Низамиевның «Фәрит Яруллин» дигән роман-хроникасы нәшер ителә.

Музыка дөньясы Фәрит өчен кечкенәдән таныш була. Әтисе Заһидулла Яруллин – тумышы белән үк табигый сәләткә ия музыкант – бик оста итеп мандолинада, скрипкада, гармунда, фортепианода уйный. Инструменталь ансамбльләр составында ул даими рәвештә клубларда, театрларда, ресторан, кинотеатрларда чыгышлар ясый, ә гражданнар сугышы елларында кызыл армиячеләр каршында концертлар бирә. Һәм З. Яруллин андый чараларга, еш кына, улын да ияртеп йөри.

1923 елда Яруллиннар гаиләсе Уфага күчеп килә. Булачак композитор анда, шулай ук киләчәкнең күренекле театр белгече Хәсән Гобәйдуллин белән бергә, татар-башкорт мәктәбендә укый. Х. Гобәйдуллин ул мәктәптә белем бирүнең бик югары дәрәҗәдә булуын, рус теленә яхшы өйрәтүләрен, ә инде татар теле һәм әдәбиятын танылган язучы, драматург Н. Исәнбәт укытуын искә ала. Анда нота грамотасына өйрәткән музыка дәресләренә бик теләп йөрүләре, Фәритнең инде ул чакта ук бу өлкәдәге белеме шактый югары булуы турында ул үзенең «Фәрит Яруллин Уфада»

дигән китабында да язып калдыра [Гобәйдуллин, б. 20]. Басмада шулай ук Ф. Яруллин белән Х. Гобәйдуллинның Уфада еш чыгыш ясаган Сагайдачный җитәкчелегендәге оперетта театры спектакльләренә йөрүләре, Фәритнең анда ишеткән көйләрне, бик тиз отып алып, импровизацияләве хакында да кызыклы гына эпизодлар бәян ителгән.

1930 елда Яруллиннар гаиләсе Казанга әйләнеп кайта. Фәритнең әти-әнисе, үзара килешә алмыйча, аерылалар. Заһидулла Яруллин улын музыка техникумына бирә, ә үзе туган ягына – башта Мамадышка, аннан Кече Сон авылына кайтып, икенче мәртәбә өйләнә. Кайбер мәгълүматларга караганда, әнисе дә кияүгә чыга. Шулай итеп, 16 яшьлек үсмер егет мөстәкыйль яши башлый. Техникумда уку елларында Фәрит Яруллин Казанның «Школьная» тыкрыгындагы тулай торакта яши. Ул анда скрипкачы Заһид Хәбибуллин һәм гобойчы Мөбарәк Батталов белән бер бүлмәдә яши. Алар да үз истәлекләрендә Фәритнең шул елларда ук инде фортепианода бик оста уйнавын язалар. Ф. Яруллин импровизацияләрен тыңлаган белгечләр аның мажор-минор аккордикасының гаять бай арсеналыннан файдалануын билгеләп үтәләр. Музыка белгече, педагог Ю.В. Виноградов Ф. Яруллин турында болай дип искә ала: «Однажды я услышал как певцу аккомпанировал симпатичный молодой человек. Я сразу обратил внимание на то, что он применял нетрадиционные гармонии. Его исполнение отличалось импровизионностью, и пентатоника сочеталась с импрессионалистской гармонией» [Алмазова, с. 32].

1933 елда Ф. Яруллин Мәскәүгә китеп, Мәскәү консерваториясе каршындагы эшчеләр факультетының икенче курсыннан Б.С. Шехтер композициясе классында укый башлый. Нәкъ менә шушы чорда ул, үзенең педагогы, 20 нче елларда хәрби темага язылган җырлар һәм «1905 ел» операсы авторы йогынтысында, берничә камера-инструмендаль әсәр, җырлар иҗат итә. Гомумән, композитор Ф. Яруллин иҗатында хәрби тематика аерым урын алып тора. Әйтик, шагыйрь М. Сөндекле сүзләренә язылган фашизмга каршы әсәр «Тельман маршы», гражданнар сугышы батырларына багышлап иҗат ителгән «Егерменче елларда» һәм Ә. Ерикәй сүзләрен көйгә салган «Комсомолка – партизанка» шундыйлардан санала. Совет хакимияте өчен көрәш елларында язылганлыктан бу җырлар романтик планда чагылдырыла, ә героик тема лирик чигенешләр белән бирелә.

«Егерменче елларда» җырының тексты Дм. Покрассның М. Исаковский сүзләренә язылган «Прощание» («Дан приказ ему на запад») әсәре рухы белән сугарылган. Анда комсомолларның походка китүе, егетләрнең берсенең, аерылганда, сөйгән кызы белән диалогы бәян ителә. Аккомпанементның дәртле, кискен тактлардан, төгәл, өзек-өзек аккордлардан торуы яңгырашка катгыйлык һәм ныклык өсти.

«Комсомолка-партизанка» җыры 30 нчы елларда рус совет җырларында көчле чагылыш тапкан гражданнар сугышы ге-

ройлары (М. Блантерның «Партизан Железняк», В. Белыйның «Орленок» һ.б.) тематикасының лирик-драматик юнәлешен дәвам итә. Ф. Яруллин, революцион маршларның кискен яңгырашын тудыра белүе һәм фортепианода аларны киеренкелек өстәүче аккордлар белән баетып бирә алуы нәтиҗәсендә, ачыктан-ачык драматизм белән сугарылган әсәрләр иҗат итүгә ирешә.

Әйтергә кирәк, бу күренекле композитор җырларында фортепиано партиясенең тәэсирлелек функциясе күпкә көчле һәм бай. Аккомпанемент көйне чагылдырып кына калмый, ә җырның эчтәлеген тирәнрәк ачарга ярдәм итә.

Мәгълүм булганча, ХХ гасырның 30 нчы еллары илдә социализм төзү, хезмәт энтузиазмы, кыю батырлыкларга омтылыш заманы иде. Шуңа күрә Ф. Яруллин иҗатында Төньяк полюс аша Америкага очкан совет очучылары (Ә. Ерикәй сүзләренә «Очучылар» җыры) һәм крепостнойлыктан азат ителгән татар хатын-кызының мактаулы хезмәте (Ә. Ерикәй сүзләренә язылган «Комсомолка уңган кыз») киң чагылыш таба. Аның Җ. Тәрҗеманов сүзләренә иҗат иткән «Чәчәк атабыз» һәм М. Сөндекленең «Юл бирегез, ул килә» шигыренә язылган җырлары популярлык казана. Халык җыр иҗатында иң күп таралган мәхәббәт темасы да Ф. Яруллин әсәрләрендә киң урын алып тора. Мәсәлән: «Лирик җыр», «Йөрәк җыры» (Ә. Ерикәй сүзләре), «Колхоз кызына» (М. Җәлил сүзләре), «Урман кызы» (Һ. Такташ сүзләре) һ.б.

1934 елда Мәскәү консерваториясе каршында татар опера студиясе ачыла, Ф. Яруллин укуын профессор Г.И. Литинский классында дәвам итә.

ХХ гасырның 30 нчы еллары тарихта милли музыкаль сәнгатьнең тизләтелгән үсеш еллары буларак мәгълүм. Республика җитәкчелеге, театр, музыка сәнгатенең, «музыкаль драмалар» белән чагыштырганда, югарырак классик үрнәге саналган опера жанрын тудыруга зур игътибар бирә башлый. Студиядә укучы композиторлар (М. Мозаффаров, Н. Җиһанов, Ф. Яруллин) хакимиятнең көчле басымы астында опера иҗат итүгә җәлеп ителәләр. Әмма яшь композиторлар югары классик үрнәктәге әсәрләр тудырырга әзер булмый. Аларга әле симфоник үсеш (реминисценцияләр, лейтмотивлар, интонацион «арка»ларны да кертеп), драматик үсеш логикасы, вокаль, ансамбль, хор һәм оркестр язмалары кебек күп кенә чараларны үзләштерергә кирәк була. Опера иҗат итүнең катлаулылыгы тагын шунда, анда оркестр музыкасы белән вокалның сәхнәдә үзара гармоник яңгырашына ирешү мөһим. Шуңа күрә яшь композиторлар халык җырлары һәм «халык җыры»на көйләү алымнары кулланып, рус опералары драматургиясенең форма һәм принципларын «татарлаштырырга» мәҗбүр булалар.

Зур күләмле музыкаль сәхнә әсәрләренең һәм симфоник жанрларның үсеш процессы, югарыдагылар басымы белән түгел, ә табигый юл белән барырга тиешлеге рус һәм чит ил музыкаль

культурасы үсеше тарихында күптән расланган хакыйкать. Талантлы композитор Ф. Яруллин моны шул чорда ук аңлаган күрәсең, ул, юкка гына, «Зөлхәбирә» операсы өстендә эшләвен туктатып, «Шүрәле» балетын иҗат итәргә тотынмагандыр.

Моны нигезләү өчен рус балетына нигез салучы П. Чайковский иҗатына кечкенә бер экскурс ясап алу урынлы булыр. Монда аңа М. Глинка иҗаты юл күрсәтә, әлбәттә, П. Чайковскийның үзенең бию жанрларын үзләштерү өлкәсендәге киеренке эшчәнлеге дә зур роль уйный. Ул аны өч юнәлештә алып бара: 1) фортепиано миниатюраларында бию формасын куллану; 2) опера өчен биюләр уйлап табу; 3) симфоник әсәрләрдә бию формалары куллану. Нәкъ менә соңгы ике юнәлештә биюләргә **симфоник метод үсеше үтеп керү** процессы кебек мөһим фактор барлыкка килә, ул балет музыкасына яңа, үзенә бер мәгънәви төсмер өсти.

Ф. Яруллинның биючәнлекне даими үзләштерергә мөмкинлеге булмый. Ул вакытта татар музыкасында биюләр белән бизәлгән ике генә әсәр – ул да булса, С. Сәйдәшев иҗатында Т. Гыйззәтнең «Наемщик» драмасындагы «Вальс» һәм Ф. Бурнашның «Таһир белән Зөһрә»сендәге «Шәрык биюе» генә була. Ф. Яруллинның үзенең иҗатында әлеге жанрны үзләштерүгә этәрерлек әсәрләре булмый. Әмма ул композиторның симфоник алымнарга нигезләп **татар балеты** иҗат итүенә һәм шуның белән татар халкын бөтен дөньяга танытуына комачауламый.

Укуын тәмамлап, Казанга әйләнеп кайтканнан соң Ф. Яруллин бөтен көчен «Шүрәле» балеты өстендә эшләүгә сарыф итә. 1941 елның язында инде бу әсәрне сәхнәләштерү эше башлана, аны алдагы көздә Мәскәүдә уздырылачак татар сәнгате декадасында күрсәтергә тиеш булалар. Моның өчен Казанга Ленинград шәһәренең Киров исемендәге театрыннан әсәрне сәхнәгә куючы Л. Якобсон, балетмейстер-репетитор П. Гусев һәм балет артистларының зур төркеме килә. Аларның барысын да «Совет» кунакханәсенә урнаштыралар һәм кызу эш башлана. Мехчылар клубы сәхнәсендә, һәр көн диярлек, репитицияләр уздырыла. Аеруча композитор Ф. Яруллинның үзенә күп тырышырга туры килә (ул да шул ук кунакханәдә яши).

Л. Якобсон, үз сценариесе буенча, аны музыкасын үзгәртергә, яңа бию номерлары өстәргә мәҗбүр итә. Былтыр партиясен башкарачак Г. Кумысников бу иҗади процесс турында җылы итеп искә ала. Л. Якобсон тиешле вакытка балетны сәхнәләштерергә өлгерү өчен, кайчакта композиторны, аңа эшләргә башкалар комачауламасын дип, хәтта кунакханә номерында өстеннән бикләп калдыра торган була. Г. Кумысников андый вакытларда авторның балет музыкасыннан өзекләр уйнаганын кунакханә коридорында хезмәткәрләрнең һәм анда торучыларның хозурланып тыңлап торулары хакында да сөйли. Ф. Яруллин янына аның элекке педагогы Г. Литинскийның да еш килүе

мәгълүм. Ниһаять, Ф. Яруллин 20 июньгә балет өстендә эшләүне (клавирда) тәмамлый. Шушы көнне Декадага тәкъдим ителгән әсәрләрне кабул итәргә Мәскәүдән комиссия килә. 20 июньдә алар Н. Җиһановның «Алтын чәч»ен, 21 июньдә драма театрының «Хуҗа Насретдин» спектакленә Җ. Фәйзи язган музыканы тыңлыйлар. 22 июньдә чират Ф. Яруллинның «Шүрәле» балетына була. Әмма, һәркемгә мәгълүм булганча, бу каһәрле көн бөтен планнарны өзә...

Сугышның беренче көннәрендә үк Ф. Яруллин М. Җәлилнең халкыбызны Ватан азатлыгы өчен көрәшкә чакырган «Соңгы көрәшкә» дигән шигыренә, яңа бер рух өстәп, дәртле, рухландыргыч темпта көй яза. Бу патриот-композиторның соңгы «аккош» җыры була. 1941 елның 13 июлендә ул «Кызыл Татарстан» газетасында басылып та чыга.

24 июльдә композитор хәрби комиссариаттан чакыру-повестка ала. Язучы Р. Низамиев үзенең Фәрит Яруллинга багышланган роман-хроникасында шундый сорау күтәрә: ни өчен кордебалетта, оркестрда, массовкаларда катнашкан артистлар бронь белән калдырылган, ә балетның авторы, ТАССР Композиторлар берлеге әгъзасы Ф. Яруллинга бу бронь бирелмәгән? Ф. Яруллин турында аның дусларының хатирәләрен, композиторның үзенең хатларын укыгач, күңелдә ирексездән башка сораулар да туа.

Беренчедән, Фәрит Яруллин, кунакханәдә теркәлсә дә, аннан китеп, Галактионов урамында коммуналкада яшәүче законлы рәвештә язылышмаган хатыны Галина Сачек янында яши. (Өстәвенә, сугышның беренче атналарында ук Казанга, күпләп, эвакуацияләнүчеләрне китерәләр.) Аның хәрби билеты да булмый. Ләкин кемдер аңа чакыру-повестканы Галактионов урамына китертү турында «кайгырта».

Икенчедән, опера һәм балет театры сугыш елларында актив эшчәнлеген дәвам итә. 1941 елның 24 июнендә Н. Җиһановның «Алтын чәч» операсы премьерасы була. Ә сентябрьгә «Шүрәле» балеты премьерасы планлаштырыла. Шулай булгач, ни өчен соң театр директоры (И. Әүхәдиев) белән театрның художество җитәкчесе (Н. Җиһанов) авторның фронтка җибәрелүенә юл куйганнар? Димәк, аларны балетның сәхнәгә чыгуы кызыксындырмаган.

Өченчедән, Ф. Яруллин белән бер үк вакытта фронтка композитор З. Хәбибуллин да чакырыла. Ф. Яруллинны өйрәнү курсларына Ульяновскига, ә З. Хәбибуллинны Мари АССРга җибәрәләр. Әмма берничә айдан аны кире чакырып кайтаралар. Ә Ф. Яруллинны ни өчен чакырып алмыйлар?

3 сентябрьдә Ульяновскидан хатынына язган хатында композитор балетның премьерасы белән кызыксына. Күрәсең, премьераның 20 сентябрьдә куелачагы турында ул җавап алгандыр, 7 сендә язылган хатында балет премьерасының рецензиясен җибәрүен сорый. 3 октябрь хатыннан исә премьераның булмавы ачыклана. Монда тагын бер аңлашылмаучанлык килеп

туа. Композитор, II пәрдәдә шундый күңелсезлек килеп чыкканга мин бик борчылдым, дип яза.

1941 елның 15 октябрендә Ф. Яруллин хатын инде фронттан яза. Ә бер елдан соң, 1942 елның 5 ноябрендә ул тиф белән авыруын, дүрт ай буе Куйбышев шәһәре госпиталендә ятуын хәбәр итә. Шул ук хатында Ленинградтан эвакуацияләнеп килгән балетмейстер П. Гусевны очратуы, хәрби часть командованиесе тарафыннан бирелгән ике көнлек ялында, үзенең яраткан профессоры Г. Литинский белән очрашу өчен, Саратов шәһәренә баруы (анда Мәскәү консерваториясе эвакуацияләнеп килгән була) турында яза. Г. Литинский да бу очрашу турында җылы итеп искә ала. Тагын шунысы бик мөһим, профессор шунда ук Мәскәү консерваториясе хәрби факультеты җитәкчесе, комбриг А. Гуторга шалтыратып, Ф. Яруллинны фронт хәрби частеннан чакыртып алырга ярдәм итүен үтенә. Г. Литинский истәлекләреннән мәгълүм булганча, А. Гутор тиз арада Ф. Яруллин хезмәт иткән хәрби часть командованиесе белән элемтәгә керә һәм Ф. Яруллинны Консерваториянең хәрби факультетына күчерүгә ризалык ала. Кәгазь-документация эшләре ике атнага сузыла. Бу вакыт аралыгында Ф. Яруллин фронтның алгы сызыгына җибәрелә. Композитор-сугышчының полкташы Дмитрий Соколов хатирәләреннән аңлашылганча, 1943 елның җәендә алар Курск янындагы көчле бәрелешләрдә катнашалар. Курскины азат иткәннән соң, Ф. Яруллин белән Д. Соколовның юллары аерылыша. Безнең корпусны эшелон белән көньякка – Ново-Фоминскига җибәрәләр, дип яза Д. Соколов. Ул анда яралана, аның бер кулын кисәләр һәм тылга озаталар. Аның истәлекләреннән Ф. Яруллинның 16 нчы танк корпусы составында көнбатышка китүе аңлашыла. Ф. Яруллин анда ике айдан соң һәлак була.

Техник фәннәр докторы, Мәскәү институтларының берсендә кафедра мөдире Д.С. Соколов 1984 елда Ф. Яруллинның туына 70 ел тулу тантанасына Казанга килә. Ул үзенең чыгышын Ф. Яруллин белән 1943 елның мартында очрашуыннан башлый. Ул минем күңелемдә эчкерсез һәм взводның бик кыю командиры булып саклана, ди галим. Шул ук вакытта аның зыялылыгы белән башка сугышчылардан аерылып торуына да басым ясый. Бервакыт ул Ф. Яруллинны бер агач төбенә утырып, икенче төп өстендә бармаклары белән клавишаларга кагылгандай хәрәкәтләр ясап торуын күрә. Полкташының, бу нәрсәне аңлата, дигән соравына: «Мин музыкант», – дип җавап бирә. Ул чакта безнең өчен «музыкант» «гармунчы» төшенчәсен генә аңлатканга, без аңа гармун табып китердек, ди Д. Соколов. Ә Ф. Яруллин, елмаеп, башын чайкап куя да, үзенең композитор булуын әйтә.

Бервакыт 1950 елда мин Мәскәүдә композитор Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты куелачагы хакында Зур Театр афишасын күрдем, дип дәвам итә

Д. Соколов сүзен. Шунда ул үзе командалык иткән ротаның кече лейтенатын күз алдына китерүе, әмма аны каршындагы афишада язылган композиторның адашы дип кенә уйлавы (чөнки ул полкташының 1943 елда һәлак булуын белгән була инде) турында бик тәфсилләп сөйли. Шушындый күренекле әсәр иҗат иткән авторны фронтка җибәрүләрен күз алдына да китерә алмавын белдерә.

Әле дә яхшы хәтеремдә, Дмитрий Сергеевич чыгышы вакытында президиумга борылды да көчле ачыну белән: «Как вы могли отправить на фронт такого гениального композитора», – дип, үкенү катыш сораулы караш ташлады.

Шунысы гаҗәп, татар композиторы фронтта да иҗатыннан аерылмаган. Г. Литинский, Ф. Яруллин белән очрашкач, аның симфоник оркестр өчен язган сюитасыннан, хәтер буенча, фрагментлар, Бөек Җиңүгә багышлап иҗат иткән әсәреннән кантаталар уйнап күрсәтүен, скрипка, виолончель өчен инструменталь концертлар, кызы Наилә өчен балалар җырлары... иҗат итәргә планлаштыруын искә ала.

Йомгак ясап шуны әйтәсе килә, фашизм кече лейтенант Ф. Яруллиннан башка да җиңелгән булыр иде, ә менә татар музыкаль сәнгате бу көчле талантка ия композиторны саклый алмавы белән зур югалтуларга дучар ителде.

**Әдәбият**

*Алмазова А.* Фарид Яруллин и татарский балет. Казань, 1986.

*Гобәйдуллин Х.* Фәрит Яруллин Уфада // Фәрит Яруллин турында истәлекләр. Казан, 1986.

***Сәйдәшева Земфира Нурмөхәммәт кызы,*** *сәнгать фәннәре докторы, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең татар музыкасы һәм этномузыкология кафедрасы профессоры*

## «Бармак белән каткан җирне казып булмый, Әлифбасыз (алфавитсыз) язып булмый» (Г. Тукай)

(Сальникова А.А., Галиуллина Д.М. Татарская «Алифба»: национальный букварь в мультикультурном пространстве (конец XIX – начало XX вв.))

Кешене мавыктыргыч белем дөньясына алып керүче иң беренче китап – ул әлифба. Иң катлаулы, фәнни, зур ачышларга багышланган китаплардан да өстен аның урыны. Чөнки һәр кешенең ирешкән уңышларында әлифбаның да роле зур.

Татар әлифбасының күп гасырлык тарихы бар. Төрле чорларны күргән, тарихи вакыйгаларда катнашкан, ничәмә-ничә буын татар кешесен тәрбияләгән, зур үзгәрешләр кичерә-кичерә, бүгенге көннәргә килеп җиткән әлеге басма, чын мәгънәсендә милләтебезнең мәдәни-тарихи байлыгын тәшкил итә. Чөнки, кайсы чорларга гына карамасын, ул, беренче чиратта, татар баласына милли тәрбия һәм белем бирү, мәгърифәтчелек чыганагы булып хезмәт итә. Әлифба, бигрәк тә XX–XXI гасырлар әлифбасы – тормыш көзгесе дә. Анда илдәге сәяси вазгыять, тормыш чынбарлыгы белән беррәттән, җәмгыятьтәге идеаллар, өстенлекле фикер-идеяләр дә чагылыш таба. 90 нчы еллардан соң дөнья күргән әсбапларда милли традицияләргә зур игътибар бирелә. «Милләтнең идеаллары турында аның әлифбаларына карап фикер йөртергә мөмкин», – дип бик хаклы рәвештә язалар Казан федераль университеты галимнәре А.А. Сальникова һәм Д.М. Галиуллина татар әлифбасына багышланган монографиядә [Сальникова..., с. 19]. Әлеге гаять бай эчтәлекле китапта милли әлифба мәдәни-тарихи феномен буларак өйрәнелә.

Китапның, анда күтәрелгән проблеманың әһәмиятен ассызыклап, басманың редакторы В.Г. Безрогов болай дип яза: «Әлифбаның төп максаты – бала өчен гадәти булган вак ташны алтын коелмасына, ә пыяла ватыкларын эшкәртелгән зөбәрҗәт ташка әверелдерүче танып-белү күзлеге ул» [Сальникова..., с. 6]. Монографиядә шушы гаять әһәмиятле корал, дөресрәге, зур тарихлы татар милли әлифбасы дөнья фәне дәрәҗәсенә күтәрелеп һәм үз урынын алырлык итеп тәкъдим ителә, аның асылы заман фәне күзлегеннән чыгып тасвирлана.

Хезмәттә дини мәктәпләрдән алып, совет чоры, СССР таркалганнан соңгы чорда Татарстанда, Идел буе төбәкләрендә һәм чит өлкәләрдә мәдәниятара бәйләнешләр булдыруда мөһим роль уйнаган татар әлифбасының үсеше, тарихы, эчтәлеге, төп концептуаль аермалары һәм охшашлыклары бик җентекле һәм тулы өйрәнелгән. Авторларның бик хаклы раславынча, татар әлифбасы татар халкының сәяси һәм иҗтимагый-мәдәни тарихын өйрәнүдә шактый зур мәгълүмати чыганак була ала. Чөнки татар

әлифбасында, бигрәк тә XX–XXI гасырларда дөнья күргән әсбапларда, җәмгыятьтәге сәясәт нык чагылыш тапкан. «Әлифбаның концепциясен шул чорның сәяси фикере билгеләгән, ә әлифба үзе әлеге сәясәт чагылышының күплеген һәм сыгылмалыгын күрсәтүче үрнәк булып торган» [Сальникова..., с. 20].

Шул ук вакытта татар әлифбасы, милләт үсеше белән бергә, катлаулы юл үткән, татар милләте формалашуга шактый зур йогынты ясаган.

Баланың зәвыгын үстерүдә, аның кызыксынуларына җавап бирүдә, мавыктыргыч дөнья белән таныштыруда да әлифбаларның роле зур. Нәкъ менә шуның өчен дә аның эчтәлегенең заманча яңгырашлы булуы зарури.

Китап авторлары билгеләп үткәнчә, Идел буе Болгар дәүләтендә, Алтын Урдада һәм Казан ханлыгында мәктәпләрдә әлифбалар кулланылган. Әмма алар, кызганычка каршы, сакланмаган. Русларны татар теленә өйрәтү өчен беренче татар әлифбасы (аның авторы С. Хәлфин) 1778 елда Мәскәү университеты типографиясендә басыла. Шуннан соң дөнья күргән әлифбалар гарәп, фарсы, татар теленә өйрәтү максатыннан төзелә (Г. Ваһапов, М. Бикчурин һ.б. авторлыгында). Хезмәттә шулай ук Н. Ильминскийның керәшен татарлары өчен әлифбалар төзү эшчәнлеге яктыртыла, аларга анализ ясала. Мөселман татарлар өчен басма әлифбалар XIX гасыр башында гына дөнья күрә башлый. Әлеге әлифбалар, аларның авторлыгын ачыклау (мәсәлән, «Әлифба иман шарты белән») мәсьәләләре, үзенчәлекләре, төрле галимнәрнең фикерләре – болар барысы да монографиядә чагылыш таба.

Китапта җәдит мәктәпләре өчен язылган әсбапларга, И. Гаспралы, Һ. Максуди, К. Насыйри, Ш. Таһири, М. Корбангалиев һәм инкыйлаптан соңгы чорда язылган әлифбаларга тирәнтен анализ ясала. Шунысы да игътибарга лаек – авторлар татар әлифбаларын өйрәнүдә чорның йогынтысын ачыклауга зур әһәмият бирәләр. Мәсәлән, инкыйлапка кадәр язылган әлифбаларда татар дөньясы автоном, ябык дөнья буларак сурәтләнә һәм анда башкаларга урын юклыгы ассызыклана; Ватан темасы күтәрелми, әлифба геройлары илдәге иҗтимагый-сәяси вазгыятьтән бик ерак тора. Миллилек тә, нигездә, дини мотивлар аша гына бирелә, чөнки әлифба авторлары милли мәдәниятне саклауда төп фактор буларак динне күрәләр. Бу кызыклы феноменга монография авторлары шактый тәфсилле тукталалар.

Октябрь инкыйлабыннан соңгы чорда дөнья күргән әлифбалар, аларның эчтәлеге, методик яктан эшләнеше, татар мәктәбендә кулланылышы кебек мәсьәләләргә дә җентекле анализ ясала. Болар – совет мәктәбе өчен язылган әсбаплар, һәм аларда совет кешесе тәрбияләү, иҗтимагый-сәяси материал төп урынны алып тора. Зурлар өчен (ликбез мәктәпләре) язылган махсус әлифбалар, аларның төрләре, метод һәм ысуллары, эчтә-

леге, күтәрелгән темалар – бу һәм әлеге чор әлифбаларына кагылышлы башка бик күп мәсьәләләр хезмәттә чагылыш таба.

Хезмәтнең дүртенче бүлеге СССР таркалганнан соңгы вакытлардан алып, бүгенге көннәргә кадәр дөнья күргән әлифбаларга багышланган. Бу чор – мәгариф үсешендә гаять әһәмиятле, эзләнүләр чоры. Милли мәгарифнең эзлекле, тулы системасын торгызу, мәктәпкәчә яшьтәге тәрбия оешмаларыннан алып, югары белем бирү йортларына кадәр туган телдә белем һәм тәрбия бирү, күпсанлы татар мәктәпләре һәм гимназияләре ачу, яңа мәктәпләр өчен дәреслекләр, уку-укыту әсбаплары булдыру кебек юнәлешләр әлеге дәвернең эчтәлеген билгелиләр. Совет дәреслекләре яңа шартларда инде берничек тә канәгатьләндерә алмый, аларның эчтәлеге дә, формасы да тамырдан үзгәрергә тиеш була. Бу таләп, иң беренче чиратта, әлифбаларга кагыла.

Әлифбаларга, иң беренче дәреслек буларак, яңа сәяси вазгыятьне – Татарстан Республикасының яңа статусын нәни гражданнарның аңында ныгыту бурычы йөкләнә. Шуңа күрә ул эчтәлеге белән дә, рәсемнәре белән дә яңа шартларны истә тотып төзелергә тиеш. Шуның белән бергә, 90 нчы елларда татар теленең дәүләт теле статусын алуы, барлык төр мәктәпләрдә һәм барлык милләт вәкилләренә дә өйрәтелергә тиешлеге мәсьәләсе куела.

Икенчедән, моңа кадәр дистә еллар дәвамында мәктәпләрдә файдаланылган әлифбаның (С.Г. Вагыйзов һәм Р.Г. Вәлитова авторлыгында) эчтәлеге бик нык искергәнлеге һәркемгә мәгълүм (50 нче елларга караган рәсемнәр, артык җитди кыяфәтле балалар һәм олылар, текстларда социалистик җәмгыятькә дан җырлау һ.б.). Идеаллар һәм тормышка караш нык үзгәргән заманда аларны куллану мөмкин түгел. Шәһәрләрдә дә татар мәктәпләре ачылу сәбәпле, авыл варианты буларак яшәп килгән традицион әлифбаны («зәңгәр» әлифба), эчтәлеген үзгәртми торып, шәһәр балаларына белем бирүдә файдалану максатка ярашлы булмый. 4 еллык башлангыч мәктәп системасына күчү дә яңа әлифба таләп итте. 6 яшьлекләр өчен төзелгән әлифба (халыкта «кызыл» (кызыл тышлы) әлифба буларак билгеле), бу яктан, алга бер адым буларак кабул ителде. Авторларның бик дөрес билгеләүләренчә, әлеге искиткеч матур әлифбада текстлар гына түгел (октябрятлар һ.б. турындагы текстлар юк; башкала, Ватан төшенчәләре заманга яраклаштырылган – Казан, Татарстан һ.б.), рәсемнәр дә, алдагы әлифбадан аермалы буларак, заман балаларының кызыксынуларына туры килерлек – әкияти-фольклор мотивларына бай, сурәтләнгән нәниләрнең йөзләре һәм хәрәкәтләре тәэсирле, киемнәре заманча, шул ук вакытта милли компонентларга бай. Китапның башка геройлары – әниләр, әтиләр, әби-бабайлар да, миллилекне саклаган хәлдә, бик заманча күренәләр. Әлифбаны төзүчеләр

«балалык дөньясы» дигән сихри һәм тылсымлы дөньяны тулысы белән чагылдырырга омтылганнар. Бу бик дөрес караш, чөнки әлифба баланы хыял диңгезе аша белем иленә алып керергә тиеш.

Тагын бер үзенчәлек – 90 нчы елларда, татар язуын кабат латин графикасына күчерү мәсьәләсе күтәрелгәннән соң, яңа экспериментал әлифбалар язылды. Бу чорда аерым этник төркемнәрнең (мәсәлән, себер татарларының) үз әлифбаларын булдыру омтылышлары да [Насибуллина] күренгәли. А. Сальникова белән Д. Галиуллина үз хезмәтләрендә А. Насибуллинаның «Әлиппа»сына бәя биреп, себер татарларының тел үзенчәлекләрен ассызыклаган хәлдә, аның һәм башка шундый әлифбаларның татар «дөньясына» һәм мәдәниятенә караганлыкларын дәлилләүче әсбап булуын раслыйлар [Сальникова..., с. 235].

Гомумән алганда, китапта татар язуы реформалары, XX гасырда мәгариф өлкәсендәге үзгәрешләр һәм аларның әлифбаларда чагылышы, төрле чорларда татар әлифбаларының эчтәлеге, «балалык дөньясының» әлифбаларда бирелеше һәм башка бик күп мәсьәләләр шактый тулы һәм җентекле яктыртылган. Чыганаклар һәм әдәбият исемлеге бай, алар проблеманы тулы колачларлык мәгълүмат алу мөмкинлеге тудыралар. Китапның ахырында бирелгән рәсемнәр өйрәнелгән чорда татар мәгарифе үсешенең күп кенә сәхифәләрен, татар әлифбаларының форма һәм эчтәлек ягыннан үсешен күзалларга мөмкинлек бирә. Әлеге татар мәгарифе, уку-укытуга һәм турыдан-туры татар әлифбасына караган искиткеч бай иллюстрацион материал арасында (китапта барлыгы 81 иллюстрация бирелгән), инде дөнья күргән рәсемнәр белән беррәттән (аларның чыганаклары төгәл күрсәтелгән), моңарчы билгеле булмаган, фәнни әйләнешкә кермәгәннәре дә шактый. Басма авторларының шәхси архивларыннан, Буа районы мәктәп музейларыннан алынган фотоматериаллар (мәсәлән, төрле чорларда татар укытучылары һәм укучыларының рәсемнәре, хатлар, белем турында таныклыклар һ.б.), XX гасырда дөнья күргән әлифбаларның тышлыклары һәм аерым битләре – болар барысы да хезмәтне кулына алган һәркемдә кызыксыну уятырлык итеп урнаштырылган. Китапның шушы рәвешле эшләнеше, әлбәттә, аның кыйммәтен бермә-бер арттыра, эчтәлеген кабул итүне беркадәр җиңеләйтә.

Татар әлифбасы – халкыбыз үткән төрле тарихи чорларны өйрәнү өчен кыйммәтле чыганак булып тора, чөнки анда шул чорларга хас төп үзенчәлекләр чагылыш таба. Шул ук вакытта ул – татарларда мәгариф тарихын, педагогик фикер үсешен өйрәнүдә дә кыйммәтле әсбап. Әлифба битләрендә татар мәгарифенең үсеш үзенчәлекләре шактый тулы сиземләнә. Татар әлифбасы тарихын өйрәнү шул заман педагогларын, аларның карашларын

билгеләүгә һәм өйрәнүгә дә беркадәр яктылык кертә. А.А. Сальникова һәм Д.М. Галиуллинаның «Татарская „Алифба"...» китабын хаклы рәвештә тарихи һәм, бер үк вакытта, татар педагогик фикере үсешен өйрәнүгә зур өлеш керткән зур фәнни-тикшеренү хезмәте дияргә мөмкин. Китапның фәнни-нәзари һәм гамәли әһәмияте искиткеч зур. Заман таләпләре буенча язылган бу китап татар тарихы, татар мәгарифе үсеше, татар язуы мәсьәләләре белән кызыксынучылар, галимнәр, педагоглар өчен халкыбызның бай рухи-мәдәни мирасын өйрәнүдә кыйммәтле фәнни-методик хезмәт булыр дип ышанасы килә.

**Әдәбият**

*Сальникова А.А., Галиуллина Д.М.* Татарская «Алифба»: национальный букварь в мультикультурном пространстве (конец XIX – начало XXI вв.). М.: НПБ им. К.Д . Ушинского, 2014. 260 с.

*Насибуллина А.Х.* Әлиппа. Төмән, 2000.

***Мортазина Ләлә Рәис кызы**, педагогика фәннәре кандидаты,*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.*
*lyalyamur@mail.ru*

## Арсланов М.Г. Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә

Татар театры сәнгате үзенең 110 еллыгын каршыларга җыена. Шушы вакыт эчендә бу төр сәнгатьне үстерүдә меңләгән шәхеснең көче кергән. Спектакльне тудыруда төрле иҗат кешеләре – автордан башлап, актерлар, режиссерлар, драматурглар, рәссамнар катнаша.

М.Г. Арслановның «Татар театры. Энциклопедик сүзлек-белешмә» дигән хезмәтендә татар халкының мәдәни байлыгы җыйналган, системалаштырылган, үз гомерләрен театрга, яңадан-яңа образлар гәүдәләндерүгә багышлаган актерлар барланган, аларның иҗат юллары, милли-мәдәни тарихыбыздагы урыннары билгеләнгән. Шулай ук татар театры эшчәнлегенә мөнәсәбәтле шәхесләрнең, җитәкчеләрнең эшчәнлеге тулы чагылдырылган.

М.Г. Арслановның бу сүзлек-белешмәсе XX гасыр татар театр сәнгатенең тарихын иҗат итүчеләрнең, ягъни актерларның, режиссерларның, драматургларның, композиторларның, рәссамнарның тормышы һәм эшчәнлегенә багышланган. Хезмәтнең шактый күләмле мәкаләләрендә милли театраль процессының үсешенә зур өлеш кертүче режиссерларның (Г. Кариев, К. Тинчурин, С. Вәлиев-Сульва, Г. Девишев, Г. Исмәгыйлев, Ш. Сарымсаков, М. Сәлимҗанов, П. Исәнбәт, Г. Йосыпов, Ф. Бикчәнтәев һ.б.), артистларның (С. Гыйззәтуллина-Волжская, Г. Болгарская, Ф. Ильская, Н. Таҗдарова, Н. Арапова, Г. Булатова, Г. Ибраһимова, Н. Ихсанова, Н. Гәрәева, Г. Исәнгулова, А. Гайнуллина һ.б.), сәхнә бизәүчеләрнең (С. Яхшыбаев, Н. Беньков, П. Сперанский, М. Сутюшев, Ә. Тумашев, С. Скоморохов һ.б.) нәтиҗәле эшчәнлекләре яктыртылган. Хезмәтнең авторы, архив фондларыннан һәм музейлардан, вакытлы матбугаттан алынган материалларга нигезләнеп, бай биографик һәм библиографик материалны системага салган һәм милли татар сәхнә сәнгате мастерларының тормышын һәм эшчәнлеген ышандырырлык итеп тасвирлаган.

Сүзлек-белешмәне төзүгә бай тарихи материал җәлеп ителгән, шулай ук авторның драматурглар, режиссерлар, артистлар, рәссамнар белән бай эчтәлекле әңгәмәләре, мөһим фактлар һәм мәгълүматлар, әлегә кадәр кулланылмаган рецензияләр, мәкаләләр текстлары да кертелгән.

Китапта Г. Камал, К. Тинчурин, Ф. Амирхан, Н. Исәнбәт, Т. Гыйззәт, Х. Вахит, А Гыйләҗев, Д. Вәлиев, Т. Миңнуллин, Ш. Хөсәенов, Р. Батулла кебек драматурглар пьесаларының куелыш тарихлары турында шактый кызыклы мәгълүматлар бирелгән, театраль терминнар, сәхнә төзелеше турында аңлатмалар да урын алган.

Мәгълүм булганча, татар театрының туган көне булып 1906 елның 22 декабре санала. Бүгенге Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры тулы канлы профессиональ иҗат коллективы булып 1922 елда гына оеша. Фәнни хезмәттә төп тикшерү

объекты итеп 1926 елда – «академия» атамасы, 1939 елда Галиәсгар Камал исеме бирелгән әнә шул театр коллективы алынган.

Басмада Татарстанда һәм аннан читтә эшләп килгән театрлар турында да кайбер мәгълүматлар, Октябрьгә кадәр төзелгән «Сәйяр», «Нур», «Ширкәт» труппаларының актерлары, режиссерлары турындагы материаллар да урын алган.

Язу стиленә килсәк, китапның исеменә үк куелган «энциклопедик сүзлек-белешмә» жанры текстның җыйнак һәм төгәл язылуын таләп иткәнчә, автор аны нигездә уңышлы үтәгән. Сәнгать әһелләре турында бернинди эпитетларсыз язу авыр булганга күрә, кайбер очракларда очерк, иҗат портреты стиле дә кулланылган.

Татар театр сәнгате хакында әлеге типтагы хезмәтнең, театр фәнендә беренче булуын да исәпкә алсак, сәхнә сәнгатебезнең үсеш тарихын күзаллауда әһәмияте чиксез.

М.Г. Арслановның «Татар театры. Энциклопедик сүзлек-белешмә» китабы актерлар, режиссерлар, сәнгать белгечләре, театр сөючеләр өчен дә файдалы булачак.

***Фәрдиева Динара Радий кызы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре*

**Яңа Кырлайда Тукай укулары.** 15 апрельдә, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге җитәкчесе Р. Солтанова инициативасы белән, сәнгать белгечләре һәм рәссамнар Арча районы Яңа Кырлай урта мәктәбе укучылары белән иҗади очрашу уздырдылар.

«Тукай образы һәм сәнгать әсәрләрендә аның әдәби персонажлары» Республика сәнгать дөньясында тоташ бер циклны тәшкил итә. Сәнгать фәннәре кандидаты Р. Солтанова, Н. Фешин исемендәге Сәнгать училищесы укытучысы, шулай ук сәнгать фәннәре кандидаты Т. Кривошеева, ТӘҺСИнең өлкән фәнни хезмәткәре Л. Шкляева, филология фәннәре кандидаты Л. Кариева укучылар алдында Россия һәм Татарстанның мәдәни юнәлешләре, соңгы гасырда иҗат ителгән скульптура әсәрләре, Милли яңарыш дәверендә Г. Тукайның роле турында чыгышлар ясадылар, мәктәп китапханәсенә китаплар һәм рәссамнарның Г. Тукайга багышланган әсәрләре репродукциясеннән тупланган альбом бүләк иттеләр.

Укучылар кунакларга үзләренең хезмәт укытучысы И. Солтанов җитәкчелегендә агачтан кисеп ясалган эшләнмәләрен күрсәттеләр.

* * *

**20 апрельдә** Казан театр көллияте студентлары Яңа Кырлайда авыл халкына Г. Тукайның тормышы турында театральләштерелгән тамаша күрсәттеләр. Соңыннан булачак актерлар Яңа Кырлай кешеләре белән күренекле скульптор Илдар Ханов тарафыннан Г. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышлап иҗат ителгән «Шигърият агачы» композициясе янында фотога төштеләр.

**2015 елның 28 апрелендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм Казан (Идел буе) федераль университеты галимнәре, татарстан Республикасы Язучылар берлеге вәкилләре катнашында «Татар әдәбиятында Бөек Ватан сугышы» дигән темага конференция уздырылды. Ул Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланып, Россиядә игълан ителгән Әдәбият елы кысаларында үткәрелде.

Конференциядә бүгенге чор татар әдәбиятында Бөек Ватан сугышы темасы, аны яңача бәяләү мәсьәләләре турында фикер алыштылар.

**12–13 майда** Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге «Урта Идел мультифольклор пространствосы: ареаль тикшеренү методологиясе» дигән темага семинар оештырды. Анда кыр фольклористикасы, Пермь татарларының традицион мәдәнияте, этномәдәни мирасны по-

популярлаштыру турында тарих фәннәре докторы, Пермь дәүләт гуманитар-педагогик университеты профессоры А.В. Черных лекцияләр белән чыгыш ясады. Семинар кысаларында «Татар гөсләсе» мультимедия проектын презентацияләү дә уздырылды.

Семинарда Пермь крае, Удмуртия, Татарстан галимнәре, аспирантлар һәм студентлар катнашты.

http://www.tatfolk.ru/test/index.php?content=podr&id=583

**20–21 майда** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты «Россия һәм Татарстан тарихы: энциклопедик эзләнүләрнең нәтиҗәләре һәм перспективалар»ына багышланган фәнни-гамәли конференция оештырды.

Конференция кысаларында түбәндәге мәсьәләләр каралды: Татарстан һәм татар халкының тарихы һәм мәдәнияте, татар энциклопедистикасының актуаль мәсьәләләре; фән белеме өлкәсендә яңа тенденцияләр; татар диаспораларын өйрәнүдә тарихи-мәдәни аспект; Татарстан Республикасында гаилә һәм демография мәсьәләләре; Татарстан халыклары хәтерендә – Бөек Ватан сугышы фаҗигаләре.

http://www.ite.antat.ru/news/index.shtml

**28–29 майда** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оешуның 75 еллыгына багышлап, «Фәнни-тикшеренү институтының гуманитар белем үстерүдә тоткан урыны» темасына халыкара форум уздырды.

Аның кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән төрки дәүләтләр һәм Россия Федерациясе академик институтлары, фәннәр академияләре, гуманитар институтлары арасында гыйльми хезмәттәшлек үсеше проблемаларына багышланган Түгәрәк өстәл үткәрелде. Анда ТӘһСИ галимнәре тарафыннан әзерләнеп дөнья күргән «Татар теленең этимологик сүзлеге» һәм Гаяз Исхакый әсәрләренең 15 томлыгы да тәкъдим ителде.

Форумда Халыкара Төрки академия президенты Кыдырали Дархан Куандыкулы, Төркиянең Фәннәр академиясе президенты Әхмәд Җәвад Аджар, Төркиянең Тел җәмгыяте (Turk Dil Kurumu) президенты Мостафа С. Качалин, төрки дәүләтләр (Азәрбайҗан, Кыргызстан) һәм Россия Федерациясе субъектлары (Башкортстан, Чуваш, Удмуртия, Марий Эл, Коми, Тува, Хакас республикалары, Новосибирск өлкәсе) академик институтлары, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең фәнни-тикшеренү институтлары, Казан (Идел буе) федераль университеты галимнәре катнашты.